# «Кабердә биреләчәк өч сорау»ның аңлатмасы

**Шәйх Хәйсәм бин Мөхәммәд Джәмил Сәрхән**

Пәйгамбәребез мәчете каршындагы институтта укытучы булып эшләгән

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Шәфкатьле һәм Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән**

Аллаһ Тәгаләгә барлык мактаулар булсын, Аннан гына ярдәм һәм гөнаһларны гафу итүен сорыйбыз. Үзебезнең яманлыкларыбыздан һәм гамәлләребезнең начарлыгыннан Аллаһка сыенабыз. Аллаһ Тәгалә туры юлга күндергән кешене беркем дә туры юлдан яздыра алмас, Аллаһ юлдан яздырган кешене исә беркем дә туры юлга күндерә алмас. Бердәнбер, тиңе булмаган Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һичбер башка иләһ юклыгына һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм Аның колы һәм пәйгамбәре икәнлегенә шаһитлык бирәм.

# Кереш сүз

**Ни өчен без Тәүхидне өйрәнәбез?**

- Аллаһ Тәгалә Тәүхидтән башка бер гамәлне дә кабул итми
- Аллаһ Тәгалә безне Тәүхид өчен барлыкка китергән
- Тәүхид изге гамәлләрнең артуына сәбәп була
- Тәүхид әһеленнән башка беркем дә җәннәткә керми
- Тәүхид һидәят юлына басуга һәм иминлек урнашуына сәбәп була
- Тәүхид гөнаһларыбызның гафу ителеүнә сәбәп була
- Тәүхид Пәйгамбәребезнең (Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) шәфәгатен алуга сәбәп була
- Тәүхид тынычлыкка сәбәп була

## Гыйлем алу юлының башында шушы китапны сайлауның сәбәбе

Бу мөбарәк китапка әһле сөннәт галимнәре, изге һәм яхшы гамәл кылып яшәгән үткән буын кешеләре бик зур әһәмият биргәннәр. Чөнки бу китапта бик зур файдалар һәм гыйлем алучы кешегә динебездә төп асыл гыйлемне аңларга ярдәм итә торган кагыйдәләр тупланган. Без гыйлем алуда алар үрнәгендә, шушы юлдан барабыз. Барча халык та, иманнары нык һәм калебләре төрле шик-шөһбәләрдән имин булсын өчен, әлеге китап битләрендә бәян ителгән динебезнең асылы хакындагы гыйлемгә мохтаҗдыр.

## Әлеге китап нәрсәсе белән аерылып тора соң?

| | | | |
|---|---|---|---|
| Алга таба аңлатма бирү максатыннан, сораулар, мәсьәләләр берләштерелгән, структуралаштыры лган | Китапны укучылар һәм тыңлаучылар өчен бик күп догалар китерелгән | Мәсьәләләр дәлилләр белән ныгытылган | Җиңел кабул ителә һәм аңлаешлы |

## “Өч асыл”ның билгеләмәсе

**“Өч асыл”** - кыскача әйткәндә, кабердә биреләчәк өч сорау:

| | | |
|---|---|---|
| Раббың кем? | Динең нинди? | Пәйгамбәрең кем? |

## Ә “Өч асыл”ны өйрәнү нинди файдалар бирә безгә?

Әгәр “Өч асылны” өйрәнеп, аңлап, шуның белән гамәл кылсаң, аннары аңа башкаларны да дәгъват итсәң (чакырсаң) һәм шушы гыйлем, гамәл, дәгъват юлында сабыр булсаң, *Аллаh теләсә*, кабердәге сорауларга да җавап бирәчәксең.

## «Өч асыл» китабының эчтәлеге

*Әлеге китап биш өлештән тора*

1. Дүрт мәсьәлә *(“Әл-Гаср» сүрәсе)*
2. Өч мәсьәлә *(Тәүхид төрләре)*
3. Тәүхидне өйрәнүнең әһәмияте
4. Өч асыл *(Кабердә безгә биреләчәк сораулар)*
5. Йомгак

## 1. Дурт мәсьәлә

1. Гыйлем
2. Шушы гыйлем нигезендә гамәл кылу.
3. Дәгъват кылу (чакыру).
4. Шушы юлда сабыр булу.

## 2. Өч мәсьәлә

1. Аллаһның Раббылыкта бердәнбер булуы. Аллаһны исем-сыйфатларында берләү.
2. Гыйбәдәтләрнең барысын да бары Аллаһка гына багышлау.
3. Ширектән һәм ширек кылучылардан ерак булу.

## 3.Тәүхидне өйрәнүнең әһәмияте

Әлеге бүлектә **«Тәүхидне ни өчен өйрәнәбез?»** дигән сорауга җавап бирелә

## 4. Өч асыл

**“Өч асыл”,** кыскача әйткәндә, кабердә безгә биреләчәк өч сорау:

- Раббың кем?
- Пәйгамбәрең кем?
- Динең нинди?

## 5. Йомгак

Авторның (Аллаһ аңа рәхимле булсын):
“Кешеләр үлгәннән соң яңадан кубарылачаклар”, - дигән сүзләреннән алып китапның ахырына кадәр.

# 1. Дүрт мәсьәлә

**(1)Шәфкатьле һәм Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән**

(2) Бел (Аллаһ сиңа рәхимле булсын): без дүрт мәсьәләне өйрәнергә, белергә тиешбез:
Беренчесе: Гыйлем
Ә ул: Аллаһ турында белү, аның Расүле ﷺ турында белү, һәм Ислам динен дәлилләр нигезендә белү.
Икенчесе: Шушы алган гыйлем нигезендә гамәл кылу (3).

## (1) Авторның “Бисмилләһ” белән башлавының сәбәпләре шулар:

1. Аллаһның Китабына һәм Пәйгамбәр ләргә ияреп (алардан үрнәк алып)
2. Алдагы буын галимнәргә ияреп. Гадәттә, алар китапларын “бисмилләһ” белән башлый торган булганнар
3. Аллаһның исеме белән башланган эш бәрәкәтле булачак

(2) Гадәте буенча автор сүзен гыйлем алучыга дога белән башлый, Аллаһтан аның өчен рәхимлелек сорый һәм бу гамәл менә нәрсәләргә ишарәли:

1. Әһле сөннәт галимнәре шәкертләренә карата мәрхәмәтле
2. Асылда, Ислам дине рәхимлелеккә нигезләнә

- **Гыйлем – ул хаклыкны дәлилләр нигезендә тану (өйрәнү), ә аның капма-каршысы наданлык булып тора.**

**(3)** Гыйлем белән гамәлнең бәйләнеше хакында: “Гыйлем гамәлне чакыра (гамәл кылырга чакыра), әгәр кеше гамәл кылмаса, гыйлем китә (алган гыйлемен онытачак)”, - диләр. Гамәл кылынмаган гыйлемдә һичнинди файда юк. Әгәр кеше гыйлем алса, ул әлеге гыйлеме нигезендә гамәл кылырга тиеш. Гамәл кылмаса, ул яһүдләргә охшаган була, чөнки аларда гыйлем бар, әмма гамәл юк: ***“Алар (Мөхәммәдне) үз балаларын таныган кебек таныйлар”(2:146).*** Җәһәннәмгә иң беренчеләрдән булып өч төрле кешене кертәчәкләр. Шуларның берсе – гыйлем өйрәтеп тә үзе шул гыйлеме белән гамәл кылмаган кеше. *“Үзенең гыйлеме нигезендә гамәл кылмаучы гыйлем иясе кеше потларга табынучыларга караганда да беренчерәк газапка тартылачак”.*

**Дәгъват кылуның үзенең шартлары, кагыйдәләре бар. Дәгъват кылучы да шуларга нигезләнергә тиеш. Әлеге кагыйдәләрнең иң әһәмиятлеләре шулар:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Дәгъват ихластан, Аллаh ризалыгы өчен булырга тиеш. | 2. Дәгъват шәригать гыйлеменә нигезләнергә тиеш | 3. Дәгъват хикмәт һәм сабырлык белән булырга тиеш | 4. Дәгъват кылына торган кешенең хәленә карә белу дә әһәмиятле |

Өченчесе:

Дәгъват кылу.

**Шушы шартларга дәлил:**

Аллаh Тәгалә әйтә : {Әйт: « Бу юл минем юлымдыр, мин шул юл белән, күреп-белеп, кешеләрне Аллаһка чакырамын, һәм миңа иярген мөэминнәр дә шул юл белән Аллаһка чакыралар, вә Аллаһ Тәгалә һәр кимчелектән пакь, һәм мин мөшрикләрдән түгелмен»} **(12:108).**

{Әйт: «Бу юл минем юлымдыр»} - Бу Пәйгамбәребез ﷺ алып килгән шәригать хөкемнәре.

{кешеләрне Аллаһка чакырамын} – Ихластан Аллаһка чакыручы, кешеләрне Аллаһка илтүче

{күреп-белеп кешеләрне Аллаһка чакырамын}, белү – гыйлем дигәнне аңлата, биредә гыйлем сүзе үз эченә менә нәрсәләрне ала:

1. Шәригатьне.
2. Дәгъват кылына торган кешенең хәлен белү.
3. Максатка илтә торган юлны.

Гүя автор безгә әйтә кебек: “Әгәр белсәң, аннары белгәнең нигезендә гамәл кылсаң, син Пәйгамбәребез ﷺ һәм аның сәхәбәләре юлыннан барырга тиешсең, Аллаһ Тәгалә дә шул хакта әйтә: {Әйт: « бу юл минем юлымдыр, мин шул юл нигезендә күреп-белеп кешеләрне Аллаһка чакырамын һәм миңа иярген мөэминнәр дә шул юл белән Аллаһка чакыралар »}. Шуңа күрә без дә Аллаһ юлына чакырырга тиешбез.

Дүртенчесе: Сабырлык.
Бу юлда очраган мәшәкатьләрдә сабыр булу (1).
Моңа Аллаһның сүзләре дәлил:

Гасыр белән ант итәмен. Дөреслектә, адәм баласы хәсрәттәдер. Мәгәр, иман китереп изге гамәлләр кылып, бер-берсен хаклыкка өндәгәннәр, төрле авырлыкларга, сабыр булучы мөэминнәр генә хәсрәттә булмаслар (103:1-3) (2).

(1) Дәгъваттан соң автор сабырлыкны искә алган. Гүя ул безгә: чынлыкта, бу юлдан баручылар, Пәйгамбәрләр һәм Расүлләр кебек, төрле сынауларга дучар булалар. Шуңа күрә сабыр булырга кирәк, - дип искәртә.

**Сабырлык**

**Тел ягыннан:**
Тыелу (тотып калу)

**Шәригать ягыннан:**
Нәфесне икенче халәткә күчүдән саклап калу.

**Имам Ибн Каийм (رحمه الله) сабырлыкны өч төргә бүлгән:**

1. Аллаһка итагать итүдә сабыр булу
2. Аллаһның тыйганнарыннан ерак булуда сабыр итү
3. Аллаһның тәкьдиренә (Аллаһтан килгән төрле сынауларга) сабыр булу

(2) Автор, дүрт мәсьәләне язганнан соң, шуларга Коръәннән “әл-Гаср” сүрәсен дәлил итеп китергән. Ни өчен автор һәрбер мәсьәләдән соң дәлил китерә соң?

1. Укучыларны сукырларча түгел, ә дәлилгә иярергә тәрбияли.
2. Ялгыш фикерле башка кешегә аңлатканда, укучының дәлиле булсын өчен
3. Укучы шәригать хөкемнәрен дөрес итеп чыгара алсын өчен.

Имам әш-Шәфигый رحمه الله әйткән: «Әгәр Аллаһ кешеләргә әлеге сүрәдән башка бүтән дәлилләр индермәгән булса, бу сүрә аларга житкән булыр иде». (1)

Имам әл-Бухари رحمه الله Сахих хәдисләр жыентыгының бер бүлеген болай дип атаган : «Әйтер һәм эшләр алдыннан гыйлем булырга тиеш».

Моңа Аллаһның сүзләре дәлил: **{Бел, Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы иләһи зат юк, һәм үзеңнең гөнаһың өчен гафу сора} 47:19**

Сүзгә һәм гамәлгә кадәр иң беренче гыйлем кирәк, димәк.(2).

(1) Имам әш-Шәфигый رَحِمَهُ اللَّهُ сүзләренең мәгънәсе шул: кешеләргә гыйлем алуны, гамәл кылуны, дәгъват кылуны һәм сабыр булуны дәлилләү өчен шул бер сүрә дә житә.

Ә Корънәннең калган сүрәләренә килгәндә, Корън үзе тулаем дәлил булып тора.

(2) Хәдисләр буенча мөэминнәрнең әмире булган Имам әл-Бухари رحمه الله үзенең китабының (“Сахих әл-Бухари” хәдисләр жыентыгы) бер бүлеген «Әйтер һәм эшләр алдыннан гыйлем булырга тиеш» дип атаган һәм дәлил китергән. Берәр сүз әйткәнчегә һәм гамәл кылганчыга кадәр иң беренче гыйлем булырга тиеш. Гыйлемсез гамәл кылу дөрес булмаячак, әгәр шулай эшләсәң, насараларга охшаган буласың.

# 2. Өч мәсьәлә

Бел (Аллаһ сиңа рәхимле булсын): һәрбер мөселман булган ир-ат һәм хатын-кыз шушы өч мәсьәләне белергә, ә аннан соң шулар нигезендә гамәл кылырга тиеш. (1)

(1) Автор رحمه الله китапның бу өлешен укучыга дога белән башлаган.

Автор رحمه الله ***"Өч асыл"*** китабында өч жирдә укучыга дога кыла:

-*"Дүрт мәсьәлә"* башланган өлештә;

- шушы жирдә – *"Өч мәсьәлә"* башланган урында;

- "Бел (Аллаһ сине Аңа итагать итә торган туры юлга күндерсен), дөреслектә, әл-хәнифиия (юлы) Ибраһим диненнән", - дигән урында.

## Өч мәсьәләне аңлатканчы кереш сүз

### Тәүхид

**Тел ягыннан:** әлеге сүз "үәххәдә" тамырыннан алынган. Бердәнбер, бер итү, бер генә дигәнне аңлата ул.

**Шәригать ягыннан:** Аллаһны Аның Үзенә генә хас булган Раббылыкта, иләһлектә һәм исем-сыйфатларында бер итү ул.

### Тәүхид өч төркемгә бүленә:

**Тәүхид әр-Рубубийәһ**

Аллаһны Аның гамәлләрендә бер итү. Икенче төрле әйткәндә, Аллаһ кына бу дөнья белән идарә итә, Ул гына барлыкка китерүче, Ул – бу дөньяның Патшасы.

**Тәүхид әл-Үлүһийәһ**

Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу.

**Тәүхид әл-Әсмәә үә әс-Сыйфат**

Аллаһны, Үзенең Китабында Үзен-Үзе тасвирлаган һәм Аның Рәсүле ﷺ Аны тасвирлаган исемнәр һәм сыйфатлар белән, бу барлык сыйфатларны раслап һәм аларга капма-каршы булган барча нәрсәне инкяр итеп, кире какмыйча, "Ничек?" дигән сорау бирмичә, нәрсәгә дә булса охшатмыйча тасвирлау.

*Аллаһның исем-сыйфатлары мәсьәләләре тәүкыйфия (әлеге сүзнең мәгънәсе “тукталу” дигәнне аңлата) төренә керә. Ягъни Коръәндә һәм Сөннәттә ничек килгән, шулай (үзгәртмичә) кабул итәргә кирәк:

- Исбатлау мәсьәләсе. Аллаһ Сүбхәнәһү вә Тәгалә Китабында Үзен ничек исбатлаган һәм Расүлебез ﷺ Аны ничек исбатлаган, без дә шулай исбатларга тиешбез.

- Инкяр иту мәсьәләсенә килгәндә дә нәкъ шулай: Аллаһ Сүбхәнәһү вә Тәгалә Китабында Үзе хакында нәрсәләрне инкяр иткән һәм Расүлебез ﷺ Аның хакында нәрсәләрне инкяр иткән, без дә шуларны инкяр итәргә тиеш. Мисал: {Аны ару, талу һәм йокы тотмас}2:255 яки {Безгә мәшәкать, вә авырлык ирешмәде} 50:38 Исем-сыйфатларның мәгънәсен үзгәртмичә, кире какмыйча, нәрсәгә дә булса охшатмыйча, “Ничек?” дигән сорау бирмичә аларны кабул итәргә тиешбез.

Беренчесе: Аллаһ безне барлыкка китергән, яшәр өчен безгә ризыклар биргән һәм үзебезне үзебезгә генә калдырмаган, ә безгә Рәсүл җибәргән, кем аңа буйсына, ул Җәннәткә керәчәк, ә кем буйсынмый, ул Җәһәннәмгә эләгәчәк.

Моңа Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил: {Тәхкыйк, Без сезгә рәсүл җибәрдек, хакны кабул итүегезгә яки кабул итмәвегезгә шаһитлык кылып, Фиргаунга рәсүл җибәргән кебек. Фиргаун рәсүлгә карышты, дошман булды, Без аны каты тотып һәлак иттек.
} 73:15-16(1)

## Кыскача “Өч мәсьәлә”

1. Тәүхид әр-Рубубийәһ һәм Тәүхид әл-Әсмәә уә әс-Сыйфат

2. Тәүхид әл-Үлүһиййәһ

3. Ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булу

(1) Беренче мәсьәләдә автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ Тәүхид әр-Рубубийәһ һәм Тәүхид әл-Әсмәә уә әс-Сыйфатны исбатлый. ***(Аллаһ безне барлыкка китергән)*** Ул – бар итүче. ***(Безгә ризыклар биргән)*** – Ризыкландыручы. ***(Үзебезне үзебезгә генә калдырмаган )*** - бернинди әмерләрсез һәм бернинди тыюларсыз безне буш калдырмаган ***(безгә Рәсүл җибәргән).***

## Аллаһның Пәйгамбәрләр عليهم السلام җибәрүенең максаты:

1. Кешеләргә дәлил ирешсен өчен:

{Пәйгамбәр җибәреп, шәригать хөкемнәрен өйрәтмичә, һичбер кавемне газап итәчәк түгелбез} (17:15).

2. Рәхмәт йөзеннән:

{Без сине мәгәр галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек} (21:107).

Икенчесе: Аллаһ гыйбадәттә Үзенә кемне дә булса (Аңа якын фәрештәме ул яки җибәрелгән Пәйгамбәрме) тиңдәшлек (ширек) кылганнарына һич риза түгел. Моңа дәлил: {Тәхкыйк, мәчетләр Аллаһка гыйбадәт кылу өчендер, шулай булгач, Аллаһ белән беррәтән башка нәрсәләргә дога кылмагыз} (72:12).

## Икенче мәсьәлә – Тәүхид әл-Үлүһиййәһне исбатлау

Автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ әйтә: (*Аллаһ гыйбадәттә Үзенә кемне дә булса тиңдәшлек (ширек) кылганнарына һич риза түгел*): “Һич кемне дә” гыйбарәсе билгесез булганга күрә бар нәрсәне дә үз эченә ала: пәйгамбәр, әүлия, җен, фәрештә, изге кеше һ.б. Кем генә булмасын, берсенә дә гыйбадәт кылу һич ярамый. Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре моңа дәлил: {Тәхкыйк, мәчетләр Аллаһка гыйбадәт кылу өчендер, шулай булгач, Аллаһ белән беррәтән башка нәрсәләргә дога кылмагыз} (72:12).

**Әлеге аятьтәге «Мәчетләр» сүзенең өч мәгънәсе бар, аларның өчесе дә дөрес:**

| | | |
|---|---|---|
| Мәчетләр бары Аллаһка гына гыйбадәт кылу өчен төзелгән | Кешенең сәҗдә кыла торган әгъзалары. | Җир: «**һәрбер җир чиста һәм миңа гыйбадәт кылу урыны**» |

{Тәхкыйк, мәчетләр Аллаһка гыйбадәт кылу өчендер, шулай булгач, Аллаһ белән беррәтән һичкемгә дога кылмагыз (72:12)}. “Һичкемгә” – сүзе әлеге контекстта билгесез затны белдереп килгән, һәм ул Аллаһтан башка бар нәрсәне дә үз эченә ала. Шуңа күрә автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ икенче мәсьәләнең башында әйтә: (*Аллаһ гыйбадәттә кемне дә булса Аңа тиңдәшлек (ширек) кылганнарына риза түгел*), ягъни ул зат кем генә һәм нәрсә генә булуына карамастан, Пәйгамбәрме ул, әүлияме, җенме, фәрештәме, изге кешеме яки башка затмы, Аллаһ бу гамәлгә һич риза түгел.

Өченче мәсьәләдә автор رَحِمَهُ اللهُ ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булырга кирәклеге турында аңлата.

**Ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булырга кирәк:**

**1. Калеб белән;**

**2. Тел белән;**

**3. Тән әгъзалары белән.**

1- Калеб белән, ягъни күңелдән мөшрикләрне, аларның бәйрәмнәрен, ә бигрәк тә ширек гамәлләрен, бидгатьләрен яратмаска, сөймәскә кирәк.

2- Тел белән: “Мин сез гыйбадәт итә торган сыннарыгыздан бизүчемен”. (43:26)

Әйт: «Ий, сез иман китермәгән кешеләр! Сез гыйбадәт кыла торган сыннарга мин гыйбадәт кылмыймын. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылмыйсыз. Һәм мин сезнең гыйбадәт кыла торган сыннарыгызга гыйбадәт кылучы түгелмен. Һәм сез мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылучы түгелсез. Сезнең үз динегез, минем үз динем!

( 109:1-6)

3 - Тән әгъзалары белән. Бу аларның бәйрәмнәрендә катнашмау, йолаларын үтәмәү, аларның игътикадлары буенча аларга хас булган киемнәрне кимәү дигәнне аңлата.

Өченчесе: Кем Рәсүлгә буйсынды һәм Аллаһны гыйбадәттә бер итте, Аллаһка һәм Аның Рәсүленә дошманлык күрсәткән кешене яратырга тиеш түгел, хәтта ул кеше иң якын кешеләрдән булса да. Әлеге сүзләргә Аллаһ Тәгаләнең аяте дәлил:

“Аллаһка һәм кыямәт көненә иман китергән хак мөэминнәр, Аллаһка һәм Аның рәсүленә дошман булучыларны дус итмәсләр, үзләренең аталары булсалар да, яки балалары булсалар да, яки туганнары булсалар да. Хак мөэминнәрнең күңеленә Аллаһ иманны ныклап беркетте, һәм аларны Үзеннән булган рухи куәт белән куәтләде, аларны асларыннан татлы елгалар агучы бакчаларга кертер, һәм алар анда мәңге калырлар, Аллаһ алардан разыйдыр, һәм алар да Аллаһтан разыйлардыр, алар Аллаһ төркеменнән, тәхкыйк, Аллаһ төркеме газаптан котылып уңышка ирешүчеләрдер.”( 58:22)

# 3. Тәүхидне өйрәнүнең әһәмияте

Бел (Аллаh сине Үзенә итагатъ итә торган туры юлга күндерсен): дөреслектә, Әл-Хәнифийя – ул Ибраһим (гәләйһи сәләм) юлы. Әлеге юл – диндә ихлас булып, Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу юлы. Аллаh Тәгалә барлык кешеләргә дә шуны әмер иткән һәм аларны бары шуның өчен генә барлыкка китергән. Аллаh Тәгалә әйтә: **{Мин кешеләрне һәм җеннәрне Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен барлыкка китердем}(51:56).** "Гыйбадәт кылсыннар өчен" сүзләренең мәгънәсе: бер Аллаһка гына гыйбадәт кылу дигәнне аңлата.(1)

Аллаһның иң бөек әмерләренең берсе – ул Тәүхид, ә Тәүхид ул - Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу (2). Иң бөек тыюларның берсе – Ширек. Ә Ширек ул – Аллаh белән беррәттән бүтән затларга, бүтән нәрсәләргә гыйбадәт кылу.

## Әл-Хәнифийя

**Тел ягыннан:**

"әл-хәнф"дигән тамырдан алынган, аның мәгънәсе: омтылу, омтылыш.

**Шәригать ягыннан:**

Ширектән ерагаеп, ихластан тәүхидкә, иманга омтылу.

**«Аллаhка итагатьле һәм батылдан хакка омтылучы иде» (16:120)**

Ягъни, Аллаhка ширек кылмыйча, Аллаhка гына гыйбадәт кылып яшәргә омтылу.

Әл-Хәнийф һәр вакытта да тәүхидкә кайтучы, ширектән ерак булган кеше.

(2) Ни өчен без тәүхидне өйрәнәбез – биредә автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ шул хакта аңлата, ә аның әһәмияте турында без инде алдарак язган идек.

**Кереш өлештә аңлатып киткәнчә,**
## Тәүхиднең билгеләмәсе шуннан гыйбарәт:

**Тел ягыннан:** "үәххәдә" тамырыннан алына, бердәнбер, бер итү, бер генә дигәнне аңлата.

**Шәригать ягыннан:** Аллаһны Үзенә генә хас булган Раббылыкта, иләһлектә һәм исем-сыйфатларында бер итү.

(1)Автор: "Гыйбадәт кылсыннар өчен" сүзләренең мәгънәсе: бер Аллаhка гына гыйбадәт кылу", - ди. Ибн Гәббәс رضي الله عنهما дә әйткән: «Дөреслектә, Коръәндә килгән һәрбер *гыйбадәт* дигән сүз ул Тәүхидне аңлата (ягъни һәрбер гыйбадәт Аллаh ризалыгы һәм Аның өчен генә булырга тиеш)». **{Аллаhка гыйбадәт кылыгыз}**: Бер Аллаhка гына. **{Ий кешеләр, Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз}**: бары тик бер Раббыгызга гына.

# 4. Өч асыл

(1) Автор сүзен өч асылны - кабердә биреләчәк өч сорауны искә алудан башлаган. Укучының яки тыңлаучының игътибарын җәлеп итү өчен бу мөһим мәсьәләне аңлату сорау-җавап рәвешендә бара.

(2) Автор беренче асылның эчтәлеген: “Дөреслектә, Раббыбыз – Аллаһ һәм бары Ул гына гыйбадәткә лаеклы”, - дип аңлата. Һәм әлеге аңлатмага дәлил дә китерә: **{Барча мактаулар галәмнәрнең Раббысы (Хуҗасы) Аллаһка гына}**. *Раббы* - ул гыйбадәт кылына торган зат.

Әгәр синнән: “Һәр кеше белергә тиешле өч асыл нindиләр алар? – дип сорасалар,
син әйт:
“Һәр кеше Раббысын, Динен һәм Пәйгамбәрен Мөхәммәдне (صلى الله عليه وسلم) танып белергә тиешле” (1).
Әгәр синнән: *“Раббың кем дип*?” – сорасалар, син әйт: *“Мине һәм Галәмнәрне нигъмәтләп, тәрбияләп торучы Раббым Аллаһ, Ул минем Раббым, Аңа гына гыйбадәт кылам, Аннан башка бүтән нәрсәләргә гыйбадәт кылмыйм”*. Аллаһ Тәгаләнең түбәндәге аяте моңа дәлил булып тора: **{Барлык мактау (хәмед-сәнәләр) – галәмнәрне тәрбияләп торучы Аллаһка} (1:2)**(2).
Аллаһтан башка һәрбер нәрсә бар ителгән – барча галәм һәм мин дә шуларның берсе (3).

**{Барча мактаулар галәмнәрнең Раббысы (Хуҗасы) Аллаһка гына}**.Бу аять тәүхиднең өч төрен үз эченә алган:

**{Мактаулар}**

Бу сүзнең эчендә Тәүхид әл-Әсмәә үә әс-Сыйфаттны исбатлау

**{Аллаһка гына}**

Бу сүзләр үз эченә Тәүхид әл-Үлүһиййәhне исбатлауны алган

**{Раббысы}** Бу сүзнең эчендә Тәүхид әр-Рубубийәhне исбатлау ята.

(3) Аллаһтан башка һәр нәрсә дә бар ителгән, син бар ителгән мәхлукъ булгач, үзеңне Бар Итүчегә, Ул биргән нигъмәтләр өчен шөкер итәргә тиешсең.

Әгәр синнән: “Раббыңны ничек танып белдең?” - дип сорасалар,
син: “Аның галәмәтләре (билгеләре), Ул бар иткән нәрсәләр аша”, - дип җавапла. Аның галәмәтләре ул - көн белән төн алмашуы, кояш белән ай; бар иткән нәрсәләре исә – җиде күк һәм җиде җир аралыгы һәм анда, алар арасында булган барлык нәрсәләр.
Моңа Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил булып тора: {Төннең һәм көннең яратылышы, кояш һәм айның төзелеше һәм хәрәкәтләре Аллаһның кодрәтенә, һәм берлегенә дәләләт итә торган галәмәтләрдәндер, ий, кешеләр, кояшка һәм айга сәҗдә кылмагыз, чөнки алар да сезнең кебек мәхлукләрдер, бәлки барча нәрсәне халык кылучы Аллаһка сәҗдә кылыгыз, әгәр сез Аллаһка гына гыйбадәт кыла торган булсагыз}.(41:37)
Шулай ук Аның сүзләреннән: {Тәхкыйк, Раббыгыз — Аллаһ, алты көн эчендә Җирне вә Күкләрне төзеде, соңра боерыгы Гарешкә карарланды. Аллаһ Тәгалә төн караңгысы белән көнне каплар, ул төн көнне ашыгып өстәр, ягъни туктамыйча бер-бер артлы килеп торырлар, Кояш, Ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр, Халык кылмак, һәр эшкә әмер бирмәк Аллаһ эше түгелме бу? Барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ бәрәкәт иясе булды}(7:54) (1)
*Раббы* – ул гыйбадәт кылына торган зат, һәм моңа дәлил: {Ий, кешеләр! Сезне һәм сездән элек булган кешеләрләрне халык кылучы Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Аллаһ газабыннан куркучы булу өчен. Сезне халык кылучы Аллаһ сезгә җирне түшәк кылды, өстегезгә күкне бина кылды, күктән яңгыр иңдереп, сезгә ризык булсын өчен, төрле җимешләр, игеннәр үстерде. Аллаһка һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш, охшаш кылмагыз! Үзегез дә беләсез, Аның тиңдәше юклыгын!}(2:21-22) (2) аятьләре.
Ибн Кәсир رحمه الله әйткән : «Шушы барлык нәрсәләрне барлыкка китерүче Ул гына гыйбадәткә лаеклы». (3)

(1) Автор Аның барлыгын дәлилли торган Коръән аятьләре китерә, һәм бу аятьләр Аннан башка Тәрбияләп торучы да, Барлыкка китерүче дә, Аннан башка Гыйбадәт кылырга лаеклы бүтән бернинди дә зат юклыгын дәллили, исбатлый.

* Һәм һәрбер мәхлук Аллаһның барлыгына галәмәт булып тора. Ләкин автор галәмәтләрне һәм мәхлукларны раслый торган аятьләрне аерган. Галәмәтләр үзгәрә, мисал өчен: көн белән төн. Ә үзгәрә торган нәрсәләр, үзгәрми торганнарына караганда, үз эчендә тагын да көчлерәк дәлилләрне ала.

(2) “Әл-Бакара” сүрәсенең әлеге аятьләре хакында кайбер галимнәр: “Коръәндәге иң беренче мөрәҗәгать: ***{Ий, кешеләр!}***, Коръәндәге иң беренче әмер: «бер Үзенә генә» ***{гыйбадәт кылыгыз}*** һәм Коръәндәге иң беренче тыю – Аллаһка гыйбадәттә тиңдәшлек кылуны тыю {Аллаһка һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш, охшаш кылмагыз!} - шушы аятьләрдән башлана”, - диделәр.

(3) Аллаһ Тәгаләне Раббылыкта (Бу дөнья белән идарә итүче, Тәрбияләп торучы дип) танысаң, Аллаһны гыйбадәттә дә бер (ягъни Ул гына гыйбадәткә лаеклы) итеп танырга кирәк.

Ибн Кәсир сүзләреннән соң автор кайбер гыйбадәт төрләрен санап китә, калеб белән һәм тән әгъзалары белән кылына торган һәрбер гамәлгә Коръәннән дәлилләр китерә.

**Дога**

**ике төрле була:**

**Сорау догасы:**

Доганың бу төре сүзләр аша кылына:

Йә Раббым, мине гафу итсәң иде, миңа Рәхимле булсаң иде.

**Гыйбадәт догасы:**

Доганың бу төре гамәлләр аша кылына:

Намаз, Ураза, Хаҗ.

Моның хөкемен ачыклап китү кирәктер һәм ул ике төргә бүленә. Соңрак әле бу хакта аңлатып язарбыз

Әлеге гамәлләрне Аллаһтан башка бүтән нәрсәгә багышлау зур ширек була.

Аллаһ безгә әмер иткән гыйбадәт төрләре (1) мисалы: ислам, иман һәм ихсан. Шулай ук: дога, курку (хәвеф), өмет (рәжа), ышаныч (тәвәккүл), теләү (рагъбә), курку (раһбә), басынкылык (хошуг), курку (хашия), тәүбә-үкенү (инәбә), ярдәм сорау (истиганә), сыену (истигазә), авыр чакта ярдәм сорау (истигасә), корбан чалу (зәбех), нәзер һәм башка Аллаһ кушкан гыйбадәтләр, алар барысы да бер Аллаһка гына багышланырга тиеш. Һәм моның дәлиле булып Аллаһ Тәгаләнең сүзләре тора: **{**«Чынлыкта, мәчетләр (яки сәҗдә урыннары) - Аллаһ өчен, шуңа күрә Аның белән беррәттән беркемгә ялвармагыз (гыйбадәт кылмагыз)!**} (72:18)**

Берәү Аллаһтан башка бүтән нәрсәләргә, затларга әлеге гыйбадәт төрләрен кылса, мондый кеше мөшрик була. Аллаһның сүзләре моңа дәлил: **{**Берәү Аллаһ белән бергә башка нәрсәгә гыйбадәт кылса, аның бу эшкә һич дәлиле юктыр, аның хөкем ителеше фәкать Раббысы хозурындадыр. Имансызлар Аллаһ газабыннан котыла алмаслар бит**}(23:117)**.

Һәм хәдистә килә: «Дога – гыйбадәтнең үзәге».

Аллаһның сүзләре моңа дәлил: **{**Раббыгыз әйтте: «Миңа дога кылыгыз, Мин җавап бирермен». Әмма, Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр хур булган хәлдә җәһәннәм утына керерләр.**}**
**(40:60)**

**Сорау догасы ике төргә бүленә**

**Аллаһ кына булдыра торган нәрсәләрне башка берәүдән сорау –**

зур ширек була

**Кеше эшли ала торган нәрсәләрне кешеләрдән сорау**

кайбер шартлар белән рөхсәт ителгән

- Хаҗәтләребез белән мөрәҗәгать иткән кеше бары тик сәбәпче генә булуына ышанырга кирәк.

  Ул үзе генә, Аллаһның рөхсәтеннән башка, берни дә эшли алмый.

- Без мөрәҗәгать иткән кешенең сораган нәрсәне эшли алырлык кодрәте, көче булырга тиеш.

  Кодрәте житмәсә, аннан сорау файдасыз икәнлеге аңлашыла инде, һәм болай эшләү ярамый да.

- Без мөрәҗәгать иткән кеше биредә, синең янында булырга тиеш.

  Моннан янында булмаган кешедән сорау ярамаганлыгы хакында аңлашыла

- Мөрәҗәгать иткән кешебез исән булырга тиеш.

  Шуның белән үле (мәет) булган кешедән сорау ярамаганлыгы ачыклана.

Әмма игътикад (ышану) мәсьәләләренә килгәндә, әгәр берәү мөрәҗәгать иткән кешесен яшерен яки үзеннән генә галәм белән идарә итә, файда яки зыян китерә ала, дип ышана икән, бу – ширек була (Әлеге мәхлүкне Аллаһ белән тиңләгән була).

***Искәрмә***: Без гамәлнең хөкемен өйрәнәбез, әмма эшләүче кешегә хөкем кылу өчен аңа дәлил ирештерү һәм шикләрен бетерү кирәк. Һәм кеше хакында, аның мөселман яки кәфер булуы хакында бары тик галимнәр генә хөкем чыгара ала.

## Игътикадта сәбәп мәсьәләсендә кешеләр өч төркемгә бүленәләр:

Аллаһ Тәгалә сәбәпне сәбәп итеп кылучы дип ышанучылар.

Һәм бу дөрес юнәлеш

Аллаһ Тәгалә сәбәпне сәбәп итеп кылмаган дип санаучылар.

Бу исә кече ширек була.

Сәбәп үзе генә гамәлгә тәэсир итә, һәм шушы сәбәп кенә файда яки зыян китерә ала дип инану.

Бу инде зур ширек була.

Шәргый сәбәпләр

Өшкерү "әр-Рукйя". Аллаһ Тәгалә чирләрдән дәвалану өчен өшкерүне шәргый хөкем итеп кылган.

Матди (физик) сәбәп

Мәсәлән, дару эчү. Аллаһ Тәгалә даруны дәваланырга сәбәп итеп кылган.

«Дога – гыйбадәтнең үзәге» дигән хәдис зәгыйфь хөкемендә. Ә Пәйгәмбәребезнең ﷺ әлеге сүзләре сахих хәдисләрдән: **"Дога ул - гыйбадәт".**

## Дога ничек гыйбадәт була ала?

Моңа әлеге аять дәлил булып тора: **{**Раббыгыз әйтте: «Миңа дога кылыгыз, Мин җавап бирермен». Әмма Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр, хур булган хәлдә, җәһәннәм утына керерләр**}** **(40:60).**

Аллаһ Тәгаләнең **{**Миңа гыйбадәт**}** сүзе доганың гыйбадәт булуын дәлилли.

Хәвеф-куркуның гыйбадәт икәнлегенә дәлил булып Аллаһ Тәгаләнең сүзләре тора: {Әгәр мөэминнәрдән булсагыз, алардан курыкмагыз, Миннән генә куркыгыз!} (1).

Өметнең (раджә) гыйбадәт булуына дәлил – Аллаһның сүзләре:

{Әгәр берәү Раббысы белән очрашырга өмет итсә, ул кеше изге гамәлләр кылсын, Раббысына гына тиешле булган гыйбадәтенә һичкемне тиңдәш кылмасын!} (2).

(2) Өмет: ул кешенең ниндидер җиңеллеккә ирешергә яки үзе өчен кыен булган нәрсәләрнең җиңелгә әверелүен теләве.

Басынкылык һәм буйсынучанлыкка нигезләнгән өмет бары тик Аллаһка гына багланырга тиеш. Аллаһтан башка бүтән нәрсәләргә өмет баглау – зур ширек була.

Аллаһның әҗеренә өмет итеп, Аңа буйсынган яки тәүбәләре кабул булуына өмет итеп, гөнаһларында тәүбә итүче бәндәләрнең генә өметләре мактаулы.

Ә изгелекләр башкармыйча гына Аллаһның рәхмәтенә өмет баглау исә үз-үзеңне алдау, буш юаныч һәм бу шелтәләнә торган гамәл.

(1) Курку: ул зыян, зарар яки хәвеф-хәтәргә очрауга шомланып борчылу.

Аллаһ Тәгалә безне шәйтанның иптәшләреннән куркудан тыйды һәм бер Үзеннән генә куркырга әмер итте.

**Курку өч төргә бүленә:**

**Тыелган курку**

Мондый курку Аллаһның рәхмәтенә өметне югалтуга илтә яки кешеләргә гөнаһлы гамәлләрдә буйсынып, Аллаһның тыюларын бозуга китерә.

**Табигый курку (гадәти курку)**

Кеше, мәсәлән, уттан, дошманыннан, ерткыч хайваннан курка. Бу рөхсәт ителгән курку.

**Гыйбадәт булган курку, яшерен һәм олылап курку.**

Куркуның бу төре кол тарафыннан иләһесенә карата түбәнсенеп, буйсынып, Аны олылап башкарыла. Һәм кешегә бу куркуны үтәү фарыз. Ә аның Аллаһтан кала башкаларга сарыф ителүе зур ширек булып санала.

## (1)Тәвәккәлнең билгеләмәсе

**Шәригать ягыннан:**

(Кеше) Ихластан Аллаһка ышанып, Аңа таяна һәм рөхсәт ителгән сәбәпләрен кыла.

**Тел ягыннан:**

Нәрсәгә дә булса таяну, ышану

## Тәвәккәл өч мәҗбүри өлештән тора

**Рөхсәт ителгән сәбәпләргә керешү**

(ягъни сәбәпләрен кыласың)

**Ышану**

Аллаһ Тәгаләгә Аның вәгъдәләрен бозмаганлы гына ышанасың

**Ихластан** Аллаһ Тәгаләгә таянасың

Тәвәккәлнең гыйбадәт булуына Аллаһның аяте дәлил: **{Аллаһка гына тәвәккәл кылыгыз, әгәр мөэминнәрдән булсагыз}(5:23).**

Шулай ук : **{Кем Аллаһка тәвәккәлләсә, Аллаһ аңа җитәдер}(65:3)** (1).

Рагъбә (теләү), раһбә (курку) һәм хошугның (басынкылык, тыйнаклык) гыйбадәт буларына дәлил: «Чынлыкта, алар яхшы эшләр эшләргә ашыга һәм Безгә өмет (рагъбә), курку (раһбә) белән ялвара иделәр, һәм безнең алда алар тыйнак, буйсынучан булдылар». (21:90) (2).

(2) Рагъбә (теләү): яраткан теләгеңә омтылу.

Раһбә (курку): бу төр курку, курыккан нәрсәдән ерагайта торган курку һәм ул гамәл белән бәйле (ягъни куркып кына калмыйсың, ә инде берәр гамәл дә эшләргә мәҗбүрсең).

Хошуг (басынкылык, тыйнаклык): яшәештә дә, диндә дә Аллаһ Тәгаләнең бөеклеген тоеп, Аңа карата тыйнаклык белән Аның әмерләренә буйсыну.

Аллаһ ризалыгын алырга омтылган кеше күңелендә куркуны һәм өметне булдырырга тиеш, әмма шуларның берәрсе өстен чыкса, бу кеше һәлак булачак.

Шуңа күрә кешедә өмет белән курку хисләре, кошның канатлары кебек, бертигез дәрәҗәдә булырга тиеш.

Хашиянең (курку) гыйбадәт булуына дәлил:
«Алардан курыкмагыз, Миннән генә куркыгыз» (2:150) (1).

Инәбәнең (тәүбә-үкенү) гыйбадәт булуына дәлил: «..Раббыгызга (тәүбә-үкенү) белән юнәлегез һәм Аңа тәслим кылыгыз (буйсыныгыз)» (39:54) (2).
Истиганә - ярдәм сорауның гыйбадәт булуына Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил: «Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз» (1:5) Хәдистә әйтелә: «Әгәр ярдәм сорасаң, Аллаһыдан сора» (3).
Истигазәнең (саклау, сыену) гыйбадәт булуына Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре дәлил булып тора: «Әйт: "Таң Раббысына (Аллаһыга) сыенамын", - диген» (113:1). «Әйт: "Кешеләрнең Раббысына сыенамын", - диген» (114:1)(4).
Истигасә - авыр чакта ярдәм сорауның гыйбадәт булуына әлеге аять дәлил: «Сез Раббыгызга ярдәм сорап ялвардыгыз, һәм Аллаһ сезнең догагызга җавап бирде» (8:9) (5).
Зәбех - корбан чалуның гыйбадәт булуына Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре дәлил булып тора: «Әйт: "Чынлыкта, минем намазым, корбаным, тормышым вә үлемем - барысы да галәмнәрнең Раббысы - Аллаһ өчендер. Аның тиңдәше юктыр. Бу миңа әмер ителде, һәм мин - мөселманнарның беренчесе" (6:162-163). Хәдистә әйтелә: «Аллаһтан башкага корбан чалучыны Аллаһ ләгънәт кылды» (6).

(1)Хашия (курку): курку гыйлемгә нигезләнгән булырга тиеш, бары шул очракта гына Аның олугълыгын, көч-кодрәтен белеп куркасың.

(2) Инәбә **(тәүбә-үкенү):** Аллаһка итагать итеп һәм гөнаһлы гамәлләрне калдырып, гөнаһлардан ерак булып Аңа кайту – **{юнәлегез}. {Аңа тәслим кылыгыз}** – Аллаһ кушкан әмерләргә буйсыныгыз, чөнки без Аның коллары, ә кол үзенең Хуҗасына буйсынырга тиеш, Хуҗа ул – Аллаһ, Пәйгамбәребез дә ﷺ әйтте: *"Хуҗа – ул Аллаһ"*.

(3) Истиганә (ярдәм сорау): ярдәм сорау. «Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз». Бу аятьтә ахырда киләсе Сиңа/Синнән алмашлыгы аять башында килгән, гарәп телендә исә мондый алым чикләүне күрсәтә. Ягъни Синнән башка беркемгә дә гыйбадәт кылмыйбыз, һәм Синнән башка беркемнән дә ярдәм сорамыйбыз.

(4) Истигазә (саклау, сыену): саклау сорау. Начарлыктан саклау, сыену сорау **{сыенамын}**, ягъни саклауны, яклауны сорыйм.

(5) Истигасә (авыр чакта ярдәм сорау): бәла-казадан һәм һәлакәттән котылуны сорау.

Истиганә, Истигазә, Истигасә һәм шәфәгатьне мәхлуктан таләп итү түбәндәге шартлар үтәлгәндә генә рөхсәт ителә: бу затның ул гамәлгә көче җитәргә тиеш, безнең күңелдә аның бары тик сәбәпче генә булуына инану булырга, ул үзе биредә булырга һәм исән булырга тиеш.

(6) Корбан чалу : (Хайванның) махсус юл белән канын агызып, җанын чыгару.

## Корбан чалу өч төргә бүленә:

**Мөбәх булган**

Ашарга, кунакларга яки сату өчен чалынган корбан.

**Аллаһтан башка бүтән нәрсәләрне яратып, олуглап аларга корбан чалу**

Женнәргә яки каберләргә багышлап чалынган корбан, бу зур ширек була.

**Аллаһ ризалыгы өчен чалу**

Корбан гәетендә, Хажда, сәдака йөзеннән чалынган корбаннар.

Нәзернең гыйбадәт булуына дәлил: «Алар нәзерләрен үтиләр һәм зыяны таралучы шул көннән (Кыямәт көненнән) куркалар» (76:7) (1).

## (1) Нәзернең билгеләмәсе

**Шәригать ягыннан:** фарыз булмаган нәрсәне үз өстенә йөкләү.

**Тел ягыннан:** вәгъдә һәм мәҗбүр итү

## Нәзернең төрләре

- Аллаһ ризалыгы өчен нәзер әйтү
- Аллаһтан башка бүтән нәрсәгә нәзер әйтү

❖ Автор биредә кайбер гыйбадәт төрләрен зикер иткән, мисал итеп китергән, әмма гыйбадәт бу төрләр белән генә чикләнми, биредә саналганнар мисал өчен генә. Монда әйтелмәсә дә, бүтән гыйбадәт төрләре дә бар. Әмма шуны истә тоту кирәк: шушы һәм башка төр гыйбадәтләрне Аллаһтан башка бүтән затларга, нәрсәләргә багышласаң, бу ширек була.

**Икенче асыл :**

Ислам динен дәлилләр нигезендә өйрәнү.

Ислам - ул Аллаһ Тәгаләгә бирелү, Аңа гына буйсыну, итагать итү, Аңа ширек кылудан һәм аның әһелләреннән (ширек кылучылардан) ерак булу.

Һәм аның өч дәрәҗәсе, баскычы бар: ислам, иман һәм ихсан. Һәрбер баскычның эркәннәре (нигезләре, терәкләре) бар.

**Беренче баскыч :** Ислам. (1)

Исламның биш эркәне, тераге бар: Шәһәдәт кәлимәсе: «Лә иләһә иллә-Ллаһ, (2) Мөхәммәд расүлү-Ллаһ», намаз уку, зәкәт сәдакасын түләү, Рамазан аенда ураза тоту һәм Аллаһ йортына хаж кылу.

(1) Автор икенче асылга күчә. Ул – Ислам динен өйрәнү. Ул, беренче эш итеп, безне Ислам аңлатмасы белән таныштыра:

**Беренче баскыч: Ислам**

Ислам - ул Аллаһ Тәгаләгә бирелү, Аңа гына буйсыну, итагать итү, Аңа ширек кылудан һәм аның әһелләреннән (ширек кылучылардан) ерак булу.

Бу – Исламның билгеләмәсе: син Аллаһ кушкан әмерләргә буйсынасың, чөнки син Аның колы, ә кол үзенең Хуҗасына буйсынырга тиеш, Хуҗа ул –Аллаһ, Пәйгамбәр ﷺ шулай диде: *“Хуҗа – ул Аллаһ”*.

**Аннан соң Динне өч дәрәҗәгә бүлгән:**

| Ислам | Иман | Ихсан |
| --- | --- | --- |

(2) Ислам эркәннәре бишәү иң беренчесе :

**Шәһәдәт бирү.**

Автор رحمه الله шәһәдәт кәлимәсенә дәлил китерә һәм аның мәгънәсен аңлатуга туктала:

Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер иләһи зат юк.

Шәһәдәт кәлимәсе үз эченә менә нәрсәләрне алырга тиеш:

| Инкяр иту | Исбатлау |
|---|---|

***«Лә иләһә»*** сүзендә - Инкяр иту

***«иллә-Ллаһ»*** сүзендә – Исбатлау.

Бу форма үз эченә чикләүне һәм исбатлауны ала. Ул, Аллаһка гына дип, гыйбадәтне чикли һәм Аллаһтан башкага гыйбадәт кылуны тыя һәм исбат итә.

Шуңа күрә автор: “Бу сүзләрне аңлатучы тәфсир булып Аллаһ Тәгалә сүзләре тора”, - дигән:

«Менә Ибраһим әтисенә һәм кавеменә әйтте: "Чынлыкта, мине барлыкка китерүчедән (Аллаһтан) башка, сез гыйбадәт кылган барлык нәрсәләрдән мин бизүчемен, һәм Ул мине туры юлга күндерер!".

“Сез гыйбадәт кылган барлык нәрсәләрдән мин бизүчемен” – менә бу инде “Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер иләһи зат юк” дигән сүзләрнең мәгънәседер.

Шәһәдәткә Аллаһы Тәгалә сүзләре дәлил:

«Аллаһ Тәгалә Аның үзеннән башка һичбер иләһ (гыйбадәткә лаеклы зат) юклыгына шәһәдәт бирде. Һәм шулай ук фәрештәләр һәм гыйлем ияләре моңа шәһадәт китерделәр. Ул гаделлекне саклый. Аннан башка иләһ юк, Ул - Газиз-куәтле, кодрәтле, Хәким-зирәк, хикмәтле» (3:18).

Шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсе - Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы иләһи зат юк.

***«Лә иләһә»*** ("Иләһ юк") сүзе Аллаһтан башка бөтен гыйбадәт кыла торган иләһләрне инкарь итә.

***«иллә-Ллаһ»*** ("Аллаһтан башка") сүзе Аллаһның хакимлектә тиңдәше булмаган кебек, Аңа гыйбадәттә дә тиңдәшләр китермичә, фәкать Аның үзенә генә гыйбадәт кылырга кирәклекне раслый.

Бу сүзләрне аңлатучы тәфсир булып Аллаһ Тәгаләнең сүзләре тора:

«Менә Ибраһим әтисенә һәм кавеменә әйтте: "Чынлыкта, мине барлыкка китерүчедән (Аллаһтан) башка, сез гыйбадәт кылган барлык нәрсәләрдән мин бизүчемен, һәм Ул мине туры юлга күндерер!". Һәм ул (Ибраһим) әлеге кәлимәне үзеннән соң киләчәк буыннарга, алар туры юлга кайтсыннар өчен васыять итеп калдырды» (43:26-28). (2)

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтә: **«Әйт: "Ий, китап әһелләре! Безнең өчен дә, сезнең өчен дә уртак булган сүзгә килик: без Аллаһтан башка беркем, бернәрсәгә дә гыйбадәт кылмаячакбыз, Аңа бернинди дә тиңдәшләр китермәячәкбез һәм беребез дә Аллаһтан башканы раббы итеп алмаячак". Әгәр дә алар йөз чөерсәләр (кире каксалар), әйтегез аларга: "Безнең мөселман булуыбызга шаһитлык бирегез", дип» (3:64)** (1).

❖ Әгәр берәү: "Лә иләһә иллә-Аллаһ" шәһәдәт кәлимәсе сүзләренең мәгънәсе "Аллаһтан башка иләһ юк", дигәнне аңлата", – дисә?

Без бу сүзләр дөрес түгел дибез, чөнки әлеге сүзләр белән Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган нәрсәләрне дөрескә санаган булабыз. Әмма әгәр ул <u>*гыйбадәткә лаеклы*</u> дип өстәп әйтсә, бу вакытта Аллаһтан башка гыйбадәт кылына торган затларның дөрес булмаганлыгы һәм бары Аллаһ кына хакыйки гыйбадәткә лаеклы иләһ икәнлеге аңлашыла.

❖ Әгәр дә берәү: "Лә иләһә иллә-Аллаһ" шәһәдәт кәлимәсе сүзләренең мәгънәсе ул – "Аллаһтан башка Раббыбыз юк", - дип әйтсә?

Безнең җавап шул: бу сүзләр дөрес, ләкин алар "Лә иләһә иллә-Аллаһ" кәлимәсенең мәгънәсен аңлатмый, бу тәухид әр-рубубия, моны Мәккә мөшрикләре дә инкяр итмәде, әмма алар Исламга кермәде.

(1) **{«Әйт: "Ий, китап әһелләре! Безнең өчен дә, сезнең өчен дә уртак булган сүзгә килик"}** әлеге аять диннәрне берләштерүнең дөрес булмаганлыгына дәлил булып тора.

(1)Автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ бу аятьне шәһадәт кәлимәсенең «Мөхәммәд - Аллаһның илчесе» дигән өлешенә дәлил итеп китергән. Һәм әлеге аятьтә Аллаһ Тәгалә шәһадәтнең бу өлешен өч нәрсә: Үзенең анты, “ләм” (اللام) хәрефе һәм “кад” (قَد) кисәкчәсе ярдәмендә куәтләгән.

(2) Автор رَحِمَهُ ٱللَّهُ шәһадәт кәлимәсенең «Мөхәммәд - Аллаһның илчесе» сүзләренең мәгънәсен аңлата һәм һәрбер мөселман кешесенә аны тормышка ашырырга куша:

- Аның (рәсүлнең) әмерләренә буйсынырга;

- Ул хәбәр иткән нәрсәләрне хак дип танырга;

- Ул тыйган һәм кисәткән нәрсәләрдән тыелырга;

- Аллаһка ул күрсәткәнчә генә гыйбадәт кылырга.

«Мөхәммәд - Аллаһның илчесе» дигән шәһадәткә Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил булып тора: «Хактыр ки, сезгә үз арагыздан булган рәсүл (илче) килде. Сез бәлага юлыксагыз, ул хәсрәтләнә. Ул сезнең өчен тырыша. Мөэминнәргә карата ул шәфкатьле, мәрхәмәтле» (9:128) (1).

«Мөхәммәд - Аллаһның илчесе» дигән шәһадәтнең мәгънәсе - аның (рәсүлнең) әмерләренә буйсыну, ул хәбәр иткән нәрсәләрне хак дип тану, ул тыйган һәм кисәткән нәрсәләрдән тыелу һәм Аллаһка ул күрсәткәнчә генә гыйбадәт кылу. (2).

**Шәһадәт кәлимәсенең «Мөхәммәд - Аллаһның илчесе» сүзләренең мәгънәсе – ул кол һәм аңа гыйбадәт кылмыйлар, һәм Рәсүл беркайчан да ялганламый дигәнне аңлата. Һәм без:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аллаһка Пәйгәмбәре без ﷺ күрсәткәнчә генә гыйбадәт кылабыз.<br><br>Дингә яңалык кертүчеләргә каршы аргумент бу. | Ул тыйган һәм кисәткән нәрсәләрдән тыелабыз.<br><br>Пәйгәмбәр ебез ﷺ тыйган нәрсәләр бер якта калсын, син икенче якта бул. | Ул хәбәр иткән нәрсәләрне хак дип таныйбыз.<br><br>Һәм ул бары тик дөресен генә сөйләүче. | Аның барлык әмерләренә дә буйсынабыз.<br><br>Чөнки ул Аллаһ Тәгалә тарафыннан ирештерүче. |

Намаз уку, зәкәт түләүнең кирәклегенә дәлил булып һәм шулай ук тәүхиднең тәфсире булып Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре тора: «Аларга Аллаһыга ихлас рәвештә, хәниф буларак, гыйбадәт кылырга, намаз укырга һәм зәкәт түләргә генә әмер ителде. Һәм бу - дөрес, хак дин!» (98:4) (1).

Ураза тотуның кирәклегенә дәлил – әлеге аять: "Ий, иман китерүчеләр! Сездән алда килеп-киткәннәргә фарыз ителгән кебек, сезгә дә ураза тоту фарыз ителде. Бәлки сез тәкъвалыкка ирешерсез" (2:183) (2).

Хаҗ кылуның кирәклегенә дәлил булып торучы Аллаһның сүзләре: «Кешеләрнең Аллаһ каршындагы бурычы - Йортка (Кәгъбәгә) хаҗ кылу. Бу - шул юлны узарга хәлләреннән килүчеләргә. Әгәр кем дә булса көферлек кылса (инкяр итсә), чынлыкта, Аллаһ - бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел» (3:97) (3).

## (1) Икенче әркән: Намаз

Бу Аллаһка кылына торган гыйбадәт, махсус сүзләр һәм гамәлләр. Ул тәкбир белән башлана һәм тәслим белән тәмамлана. Намаз диннең тереге булып тора, Пәйгамбәребез ﷺ күккә күтәрелгәч, Аллаһ Тәгаләдән аңа ﷺ фарыз ителгән.

## Өченче әркән: Зәкәт

Тел ягыннан арту һәм чистарыну дигәнне аңлата.

Һәм ул ике төргә бүленә: тән сәдакасы, мал сәдакасы.

## (2) Дүртенче әркән: Ураза

Тел ягыннан мәгънәсе – тыелу.

Шәригать ягыннан мәгънәсе: Аллаһ ризалыгы өчен ният кылып, таң беленгәннән алып кояш баеганчыга хәтле, Уразаны боза торган гамәлләрдән (ашау, эчү һ.б.) тыелып торудан гыйбарәт булган гыйбадәт. Ураза – гыйбадәтләрнең иң фазыйләтлесе, чөнки анда сабырлыкның өч төре дә бар. Шулай ук Аллаһ Тәгалә Ураза тотучыга әҗер-савапны үзем бирәчәкмен, ди.

## (3) Бишенче әркән: Хаж

Тел ягыннан омтылыш, юнәлеш дигән мәгънәдә.

Шәригать ягыннан исә Пәйгәмбәребез ﷺ өйрәтеп калдырганча, билгеле йолаларны үтәп, Аллаһ ризалыгы өчен кылына торган гыйбадәт дигәнне аңлата.

Һәм бу гамәлне гомерендә бер тапкыр кылу һәр мөселман кешесенә фарыз булып тора.

## Икенче баскыч: Иман

Тел ягыннан мәгънәсе: икърар итү, тану.

Шәригать ягыннан мәгънәсе исә: тел белән әйтү, калеб белән ышану, тән әгъзалары белән гамәл кылу. Аллаһка итагать арткан саен иман арта һәм, киресенчә, гөнаһ кылган саен иман зәгыйфьләнә.

Шәригать ягыннан караганда, үз эченә Иман биш нәрсәне алырга тиеш. Әмма шуларның хәтта берсе генә булмаса да, әхле сөннәт әһелләрендә бу иман дип саналмый.

Бу биш нәрсәгә нинди дәлил бар соң?

Пәйгамбәребезнең ﷺ әлеге сүзе: ***“Аның (иманның) иң бөек дәрәҗәсе - «Лә иләһә илләЛлаһ» шәһәдәсен әйтү”.*** Хәдиснең бу өлеше “тел белән әйтү”гә дәлил булып тора.

***“иң түбәне - юлда комачаулап ятучы нәрсәне алып ташлау”.*** Бу өлеше исә “тән әгъзалары белән гамәл кылу”га дәлил.

***“һәм оялчанлык - шулай ук иманның бер дәрәҗәсе***”. Бу сүзләр “калеб гамәле”нә дәлил.

Икенче баскыч: Иман.
Ул житмештән артык өлешкә бүленә. Аның иң бөек дәрәҗәсе - «Лә иләһә илләЛлаһ» шәһәдәсен әйтү, ә иң түбәне - юлда комачаулап ятучы нәрсәне алып ташлау. Шулай ук оялчанлык та - иманның бер дәрәҗәсе.
Иманның алты әркәне бар: Аллаһка иман китерү, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Кыямәт (Ахирәт) көненә һәм тәкъдиргә (яхшылык та, яманлык та Аллаһ Тәгалә тәкъдиреннән булуына) иман китерү, ышану.
Бу әркәннәргә Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре дәлил: «Йөзегезне көнчыгыш яки көнбатышка таба карату гына игелек кылу түгел, игелек ул - кешенең Аллаһка, Ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга, пәйгамбәрләргә иман китерүе, инануы» (2:177).

Тәкъдиргә иман китерергә тиешлекнең дәлиле: «Чынлыкта, Без һәрбер нәрсәне үз тәкъдире белән яралттык» (54:49).

һәм Аллаһ Тәгаләнең: {кайсыгызның иманын арттырыр} **(9:124)** сүзләре “иманның артуы”на дәлил булып тора. Димәк, әгәр иман арта икән, ул кими дә ала, һәм моңа Пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләре ачык дәлил: «сездән башка **динендә һәм акылында кимчелек булган** беркемне дә **күрмәдем …**»
Дин кимергә дә мөмкин, димәк.

# Иманның алты әркәне

- Аллаһка иман китерү
- Фәрештәләргә иман китерү
- Китапларына иман китерү
- Пәйгамбәрләргә иман китерү
- Кыямәт көненә иман китерү
- Тәкъдиргә иман китерү

## 1. Иманның беренче әркәне – Аллаһка иман китерү, ул 4 нәрсәне үз эченә ала:

- Аллаһ Тәгаләнең барлыгына ышану һәм ул дүрт нәрсә белән раслана:
- “Тәүхид әр-Рубубийяһ”ка иман китерү
- “Тәүхид әл-Үлүһийяһ”кә иман китерү
- “Тәүхид әл-Әсмәә вә әс-Сыйфат”ка иман китерү

### Акыл белән

Безнең акылыбыз бу дөньядагы барлык нәрсәләрнең ясаучысы юк, дип һич күзаллый алмый, ә киресенчә: “Әллә алар һичнәрсәсез халык ителделәрме, ягъни аларны халык кылган Аллаһ юкмы, әллә алар үзләре халык кылучыларммы” (52:35)

### Хис-тойгылар белән

Берәр кайгы-хәсрәткә юллыксаң, ирексездән кулларыңны күккә күтәрәсең һәм Аллаһтан сорыйсың.

Йә Раббым, дип ялварасың, һәм, теләсә, бу кайгыдан Ул сине арындыра.

### Фитра (тумыштын килгән сыйфат) белән

**“Һәр сабый фитра белән (ислам динендә) туа, һәм ата-анасы аны йәһүд, насара яки мәҗүси итә”.**

### Шәригать

Ибн әл-Каийм (Аллаһ аңа рәхимле булсын) әйтә:

“Коръәндә тәүхидкә дәлил булмаган бер генә аять тә юк”.

## Икенче әркән: Фәрештәләргә иман

Фәрештәләр – яшерен галәм дөньясыннан, Аллаһ Тәгалә аларны нурдан яраткан. Алар Аллаһка гел гыйбадәт кылып торалар һәм бер дә гөнаһ кылмыйлар. Фәрештәләрнең рухлары да (“Изге Рух” (Җәбраил) (2:87)), тәннәре дә (“Ул фәрештәләрне пәйгамбәрләргә илче итеп җибәрүчедер, ул фәрештәләр икешәр, өчәр, дүртәр канатлылардыр. Үзе халык кылган мәхлукларыннан теләгәнен артыграк” (35:1), шулай ук акыллары һәм калебләре дә (“күңелләреннән курку җибәрелгәч, әйтерләр: «Раббыгыз нәрсә әйтте?”(34:23)) бар. Без фәрештәләрнең барлыгына (Аллаһ Тәгалә аларның кайбер исемнәрен дә безгә хәбәр итте: Джибрил, Микаил һәм Исрафил), аларның сыйфатларына (“Алар үзләренә булган боерыкларда Аллаһка һич хилафлык кылмыйлар, Аллаһтан нинди боерык булса—шуны эшлиләр.” (66:6), аларның гамәлләренә (гәршне йөртүчеләр) һәм алар турында килгән барлык хәбәрләргә дә ышанабыз.

## Өченче әркән: Китапларга иман

Китаплар читләтеп әйтелгән сүзләр генә түгел, хаклыкта, алар барысы да Аллаһ сүзләре. Алар уйланып чыгарылган түгел, ә Аллаһ тарафыннан иңдерелгән сүзләр икәнлегенә без ышанырга тиешбез. Аллаһ Тәгалә һәрбер Рәсүл белән китап та иңдергән. Без анда хәбәр ителгән кыйссаларга, хөкемнәргә, Аллаһ исемнәренә ышанабыз. Һәм Коръән үзенә кадәр булган китапларны гамәлдән чыгарганлыгына ышанабыз, мәсәлән: Тәүрат, Инҗил, Зәбүр, Сухуф Ибраһим һәм Муса عليهم السلام (бу китаплар белән инде гамәл кылынмый).

## Дүртенче әркән: Пәйгамбәрләргә иман

Аларның гадәти кешеләр булганлыгына һәм хакимлектә (Раббылыкта) бер нинди өстенлекләре булмаганлыгына без ышанырга тиешбез. Алар да Аллаһ Тәгаләнең коллары булган, аларга гыйбадәт кылынмый. Аллаһ Тәгалә аларны халыкларга динне ирештерүче буларак җибәргән һәм аларга уахий иңдергән, могҗизалар белән ныгыткан. Пәйгамбәрләр үзләренә әманәт итеп йөкләтелгән васыятьне халыкларга ирештерделәр, Аллаһ юлында ихластан көрәштеләр. Һәм без Аллаһ Тәгалә алар турында, аларның исемнәре, сыйфатлары турында ирештергән хәбәрләрнең барысына да ышанабыз. Иң беренче Пәйгамбәр Адәм عليهم السلام булган, иң беренче Рәсүл Нух عليهم السلام булган, һәм иң соңгы Рәсүл һәм Пәйгамбәр – Мөхәммәд ﷺ. Мөхәммәд ﷺ шәригате аңа кадәр булган шәригатьләрне гамәлдән чыгара (алар белән гамәл кылынмый). Пәйгамбәрләрнең иң карарлылары бишәү һәм алар “Шура” һәм “Әхзәб” сүрәләрендә зикер ителгән: Мөхәммәд ﷺ, Нух عليهم السلام , Ибраһим عليهم السلام, Муса عليهم السلام , Гайсә عليهم السلام.

## Бишенче әркән: Кыямәт (Ахирәт) көненә иман

Пәйгәмбәребез ﷺ безгә кеше үлгәннән соң аның белән була торган вакыйгалар хакында бәян итте. Без әлеге вакыйгаларга иман китерергә тиешбез, мәсәлән: кабер газабы, сурга өрү, кабердән кире кубарылу, гамәлләрне үлчәү, гамәл дәфтәрләрен тапшыру, сират күперен чыгу, хәвез (сулык), шәфәгать кылу, җәннәт һәм җәһәннәм, мөэминнәрнең җәннәттә һәм Кыямәт көнендә Раббыларын күрүләре һәм башка яшерен гамәлләр.

## Алтынчы әркән: тәкъдиргә, ягъни яхшылык та, яманлык та Аллаһ Тәгалә тәкъдиреннән булуына иман китерү. Бу иман үз эченә дүрт нәрсәне ала:

| Гыйлем | Язу | Ихтыяр (Теләү) | Бар итүче |
| --- | --- | --- | --- |
| Аллаһ Тәгалә һәрбер нәрсәне белүче, Аның барлык нәрсәне дә белеп торуына ышану. | Аллаһ Тәгаләнең кыямәт көненә кадәр булган һәрбер нәрсәнең микъдарын язып куйганлыгына ышанырга тиешбез. | Аллаһ Тәгалә нәрсә тели шул була, нәрсәне теләми, ул булмый. Кешеләрнең дә үз ихтыярлары бар, әмма ул Аллаһ Тәгаләнең ихтыяры астына кергән. Әнә шуларга без иман китерергә тиешбез. | Кеше – ул мәхлук (бар ителгән). һәм аның гамәлләре дә барлык нәрсәләр кебек үк бар ителгән булуына инану. **{һәрнәрсәне бар кылучы фәкать Аллаһдыр} (13:16).** **{Үзегезне дә, һәм сезнең гамәлләрегезне дә Аллаһ бар кылды}(37:9).** |

**Өченче баскыч: Ихсан**
Бу Диннең иң бөек дәрәҗәсе, аның бер әркәне бар, һәм ул ике төргә бүленә

**Күреп торуын сизеп гыйбадәт кылу**

Гыйбадәт кылганда Аллаh Тәгаләдән, Аның җәзасыннан курку халәте. Һәм бу төр һәр мөселман кешесендә дә булырга тиешле.

**Һәрдаим күзәтчелек итеп торуын сизеп гыйбадәт кылу**

Аллаһ Тәгаләне яратып, Ул әзерләгән җәннәткә омтылып, теләп, яратып кылына торган гыйбадәт. Пәйгамбәрләр һәм Рәсүлләр عليهم السلام гыйбадәтләрен шул рәвешле кыла торган булганнар, әмма бу дәрәҗәгә бүтәннәр дә ирешә ала.

Өченче баскыч – ихсан.

Ихсанның бер рөкене бар һәм ул - Аллаhыга Аны күргән кебек гыйбадәт кылу, чөнки син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә.

Моңа Аллаh Тәгаләнең сүзләре дәлил:

«Чынлыкта, Аллаh тәкъва булучылар һәм игелек кылучылар белән» (16:128).

«Кодрәтле һәм мәрхәмәтле булучыга (Аллаhка) сыен. Ул сине син намазда басып торганда һәм сәҗдә кылучылар арасында булганда күреп тора. Чынлыкта, Ул - ишетүче, белеп торучы» ( 26:217-220).

«Нинди генә эштә булсаң да, Коръәннән нәрсә укысаң да һәм сез нәрсә генә эшләсәгез дә, Без сезнең өстегездә шаhит булып (күзәтеп) торырбыз» (10:61).

Искәрмә: Әлеге дәрәҗәгә ирешкән кешенең күңелендә Аллаhка мәхәббәте генә булып, Аннан курку хисе юк дигәнне аңлатмый бу. Әмма мондый кешене гыйбадәткә күбрәк Аллаh Тәгаләгә булган мәхәббәте этәрә. Пәйгамбәребез дә ﷺ әйткән бит: “**Әллә миңа рәхмәтле кол булырга кирәкмиме?” – дип.**

Сөннәттән дәлил булып Җәбраил хакындагы хәдис тора. Гомәр ибнел-Хәттаб (Аллаһ аннан разый булсын) сөйли: «Бервакыт без Пәйгамбәр янында утырганда, көтмәгәндә безнең янга күз явын алырдай ак киемле, кап-кара чәчле кеше килде. Аның кыяфәтенә караганда, мосафир дип әйтеп булмый иде, ләкин без беребез дә аны танымадык. Ул, тезләре Пәйгамбәр галәйһиссәләмнекенә тиеп торырлык итеп, аның каршына утырды, кулларын үз тезләренә куйды һәм: «Әй Мөхәммәт, миңа Ислам турында сөйлә!» – диде. «Ислам – «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк, Мөхәммәт – Аның Илчесе» дип әйтү, намаз уку, зәкәт түләү, Рамазанда ураза тоту, булдыра алсаң, Йортка хаҗ кылу ул», – дип җавап бирде Мөхәммәт галәйһиссәләм. Әлеге кеше: «Син дөрес әйттең», – диде. Без аның Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә сорау бирүенә һәм үзе аның сүзләрен раславына аптырадык. Аннары ул: «Хәзер миңа иман турында сөйлә!» – дип әйтте. Аллаһының Илчесе галәйһиссәләм: «Иман – Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның язуларына, Аның пәйгамбәрләренә, соңгы Көнгә, яхшының да, начарның да алдан билгеләнүенә ышануың ул», – диде. Теге кеше тагын: «Син дөрес әйттең», – диде. Аннары: «Миңа ихсан турында сөйлә!» – диде. Аллаһның Илчесе галәйһиссәләм: «Ихсан – Аллаһны күрмәсәң дә, Аны күргән кебек гыйбадәт кылу ул. Син Аны күрмәсәң дә, Ул һичшиксез сине күрә», – дип җавап бирде. Шуннан соң ул: «Хәзер миңа кыямәт көне кайчан буласы турында сөйлә!» – диде. Аллаһның Илчесе: «Ул турыда соралучы кеше сораучыдан күбрәк белми», – дип әйтте. Кеше: «Алайса миңа аның галәмәтләрен сөйлә», – диде. Аллаһының Илчесе: «Кыямәт якынаюның галәмәтләре – кол хатынның үз хуҗабикәсен тудыруы; яланаяк, ялангач, ярлы көтүчеләрнең биек өй төзүдә бер-берсе белән ярышулары», – дип җавап бирде. Әлеге кеше китеп күпмедер вакыт үткәч, Пәйгамбәр ﷺ : «Әй Гомәр, миңа кем сорау биргәнлеге сиңа мәгълүмме?» – дип сорады. Мин: «Аллаһ һәм Аның Илчесе бу турыда яхшырак беләләр», – дидем. Ул: «Чынлыкта, бу – Җәбраил, сезне динегезгә өйрәтергә килгән!» – дип әйтте» (Мөслим).

Бу хәдис Ислам, Иман һәм Ихсан әркәннәренә дәлил булып тора.

Пәйгамбәребезнең ﷺ: «Ул турыда соралучы кеше сораучыдан күбрәк белми», - дигән сүзе Кыямәт көненең кайчан булачагын бер Аллаһ кына белүенә дәлил булып тора.

**Пәйгамбәребезнең ﷺ : «кол хатынның үз хуҗабикәсен тудыруы» сүзе:**

- Итагатьсезлек артачак
- Коллык артачак
- Халәт үзгәрәчәк
- Дәүләт башлыгы кол хатынга өйләнәчәк һәм ул аңа малай алып кайтачак, ә этисе үлгәннән соң ул барлык кешеләр белән идарә итәчәк дигәнне аңлата.

*Яланаяк, ялангач* – ягъни фәкыйрьләр.

*Ярлы көтүчеләрнең биек өй төзүдә бер-берсе белән ярышулары* - кешенең халәте үзгәрәчәк, ягъни алар фәкыйрьләрдән бозык байларга әвереләчәкләр дигән сүз бу.

## Җәбраил (гәләйһи сәләм) хакындагы хәдистән нинди файдалар алабыз?

1. Гыйлем алучының алты хакы һәм бурычы бар: үзенә, укытучысына карата, укыган урынына, дусларына, китабына, өйрәнә торган гыйлеменә карата.

*Үзеңә карата булган хак һәм бурычлар*: гыйлем ул – гыйбадәт (аның ихласлык һәм сөннәткә муафыйк булуы кирәк), һәм гыйлем алуда сәхәбәләр, табигыйннәр юлында булырга тырыш. Аллаһтан куркып, Ул сине һәрвакыт күреп торуын сизеп яшә, тыйнак бул, тәкәбберләрдән булма.

Шулай ук булганына канәгать бул, заһитлык кылып, гыйлемнең матурлыгы белән үзеңне бизә. Ир-атлык сыйфатын үзеңдә булдырырга тырыш. Байлыкка кызыкма, файдасыз мәҗлесләрдән ерак бул. Үзеңдә йомшаклык сыйфатын булдыр, ә диндә исә нык бул.

Гыйлемгә бик каты омтылу, аны ятлау, язып бару, гыйлем эзләп сәфәргә чыгу, гыйлемнең асылын һәм тармакларын аңлау, Аллаһтан ярдәм сорау, һәрвакытта да дөресен генә сөйләү, сиңа тапшырылган гыйлемне саклау – гыйлемнең хакларыннан булып тора.

Гыйлем алучының калканы – *“мин белмим”* дип әйтүе. Вакытны саклау, аңа кагылмаган нәрсәләргә вакытны әрәм итмәү – аның бурычы. Аның хәтта ялы да үз өстендә эшләү, уку, үз хаталарын, калебен төзәтү, ятлау булырга тиеш.

Дөрес итеп сорау бирә бел, тыңлый бел, аңлап гамәл кыла бел, гыйлемне гел кабатлап тор, Коръән белән Сөннәт арасында бул, алар белән бәйле фәннәрне өйрән.

Дан-шөһрәткә омтылудан, дөньяны яратудан ерак тор.

Кешеләр турында яхшы фикердә булырга, ә үзеңә карата, киресенчә, тәнкыйть күзлегеннән карарга кирәк.

Гыйлемнең зәкәте: хаклыкка буйсыну, яхшылыкка өндәү, начарлыктан тыю, начарлык белән яхшылыкны аера белү, үзеңне кызганмыйча, гыйлем һәм файда китерүне ярату, хаклыкны  һәм яхшылыкны яклап, мөселманнарга шәфәгать кылу.

Үзеңне галим итеп куюдан, кешеләргә ярарга тырышудан һәм ялагайланудан ерак тор, гыйлемне якла.

Шикле булган нәрсәләрдән ерак бул, нигезсез бүленүләрдән саклан, нигезсез булган яратудан һәм бер-береңне күрә алмаудан саклан.

*Укытучыңның хаклары шулар:* бу мәсьәләдә кешеләр өч төркемгә бүленделәр. Берләре – чиктән аштылар, җир йөзендә иң беренче ширек тә шул сәбәпле булды, чиктән ашучылар кешеләрне изгеләштереп, аларга гыйбадәт кыла башладылар. Икенчеләре, киресенчә, укытучы хакына салкын карадылар. Өченчеләре исә – урталыкта, һәм без дә, чиктән тыш арттырмыйча һәм салкын карамыйча, нәкъ менә урталыкта булырга тиешбез.

- Укый торган урыныңның да сиңа хакы бар.

- Кардәшләреңнең дә сиңа карата хаклары бар. Аллаһ Тәгалә әйтә: “Дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз” (3:110), һәм Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: “*Үзегезгә теләгәнне кардәшегезгә теләми торып, берегез дә иман китермәс”*.

- Китапларның сиңа карата бурыч һәм хаклары – аларны уку, өйрәнү, ятлау. Аллаһ Тәгалә безне китаплар белән нигъмәтләндергән, без дә аларны ятларга, укырга, өйрәнергә тиешбез.

- Гыйлемнең хакы исә аны ятлау, һәрвакыт аны кабатлап тору, аның белән гамәл кылу. Өйрәнгән гыйлемең белән гамәл кылу, аннан соң дәгъват кылу, гыйлемгә чакыру, аңлату – безнең өстебездә зур бер бурыч булып тора. Бу бик зур нигъмәт, моның өчен без Аллаһ Раббыбызга шөкер итәргә тиешбез.

2. Сорау бирүнең әдәпләре шулар: беренче чиратта җавапларыннан күп файда һәм хәерлелек булачак сорауларга өстенлек бирергә кирәк.

3. Гыйлем алучы үзен һәрвакытта да күркәм, матур халәттә тотарга тиеш.

4. Пәйгамбәребез ﷺ вафатыннан соң “Аллаһ һәм Аның Рәсүле белүче”, - дип әйтелми, ә: “Аллаһ белүче (“Аллаһу әгъләм”)”, - дип әйтелә.

**Өченче асыл:**
Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ тормыш юлын өйрәнү.
Аның исеме - Мөхәммәд ибн Габдуллаһ ибн Габделмотталиб ибн Һәшим. Һәшим Корәеш нәселеннән була. Корәешләр - гарәпләр, ә гарәпләр Исмәгыйль ибн Ибраһим әл-Хәлил пәйгамбәр нәселеннән булалар. Пәйгамбәребез 63 ел яши. Пәйгамбәр булганчы ул кырык ел, пәйгамбәр, рәсүл булгач, егерме өч ел яши. Аллаһ аны "Укы!" аятен иңдереп пәйгамбәр, ә "Ий, бөркенүче!" аятен иңдереп рәсүл итә. Пәйгамбәр Мәккәдә туа, ә аннары Мәдинәгә һиҗрәт кыла (күченә).

Бу бүлек Пәйгамбәребезнең ﷺ, кыскача тормыш юлы турында, аның исеме, нәселе, ничә ел гомер иткәне һәм дәгъват кылуы хакында.

**Пәйгамбәребез турында без белергә тиешле нәрсәләр:**

| Исеме һәм нәселе | Яше |
|---|---|
| Ул Мөхәммәд ибн Габдуллаһ ибн Габделмотталиб ибн Һәшим. Һәшим Корәеш нәселеннән була. Корәешләр - гарәпләр, ә гарәпләр Исмәгыйль ибн Ибраһим әл-Хәлил пәйгамбәр нәселеннән булалар عليه السلام. | 63 яшенә хәтле яшәгән, шуның 40 яше Пәйгамбәрлеккә кадәрге гомере, ә калган 23 яше Пәйгамбәрлек тормышында үткән. |

**Пәйгамбәребез ﷺ тормышы ике чорга бүленә:**

| Мәккә чоры | Мәдинә чоры |
|---|---|
| 13 ел дәвам итә | 10 ел дәвам итә |

Ул ﷺ Пәйгамбәрме яки Рәсүлме?

Ул ﷺ - Пәйгамбәр дә, Рәсүл дә. Ул ﷺ, "Укы!" аяте иңеп, пәйгамбәр, ә, "Ий, бөркенүче!" аяте иңеп, рәсүл була.

## Пәйгамбәребезнең ﷺ тормышыннан өземтә

Мәккә дәверендә төп эш тәүхидкә юнәлгән була. Пәйгамбәребез ширектән тыя һәм ихластан Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыра һәм бу 13 ел дәвам итә.

Аннан соң аңа ﷺ Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылырга әмер ителә, анда да тәүхидкә чакыру дәвам итә, моңа шәригать хөкемнәре дә кушыла, гыйбадәт кылу тәртипләре, мөгамәләт һәм бу дөньяга бәйле мәсьәләләр иңдерелә.

Пәйгамбәребезнең тормышына һәм дәгъватына күз салсак, аның тәүхидкә чакыруы бу дөньядан бакыйлыкка күчкәнчегә хәтле дәвам итүен күрербез. Бу үз чиратында тәүхидне өйрәнүгә әһәмият бирмәүчеләргә яки, тәүхидне вакытлыча өйрәнсәк, шул да җитә, диючеләргә катгый дәлил булып тора.

Аллаһ аны ширектән (Аллаһка тиңдәшләр китерүдән) кисәтү һәм тәүхидкә чакыру өчен җибәрә. Аллаһ Тәгалә әйтә: «Ий, мүдәссир (бөркәнүче)! Тор һәм үгетлә! Һәм Раббыңны олыла. Киемеңне чистарт. Нәҗес, пычрактан (потлардан) ваз кич! Күбрәккә ирешү өчен яхшылык кылма. Һәм Раббың өчен сабыр бул!» (72:1-7).

«Тор һәм үгетлә» сүзенең мәгънәсе - "Ширектән кисәт һәм тәүхидкә чакыр". «Раббыңны олыла» сүзе - "Аны тәүхид аша олыла", ә «Киемеңне чистарт» сүзе - "Эшләреңне ширектән чистарт" дигәнне аңлата. «Нәҗес, пычрактан ваз кич!» аятендә "нәҗес, пычрак" сүзләре потларны күздә тота, ә алардан ваз кичү - ул потларны һәм пот әһелләрен калдыру, алардан ерак тору. Пәйгамбәр галәйһиссәләм ун ел дәвамында моны үти һәм тәүхидкә чакыра. Шуннан соң ул күккә мигъраҗ кыла һәм аңа анда биш вакыт намаз боерыла. Киләсе өч ел дәвамында ул Мәккәдә намаз укый, шуннан аңа Мәдинәгә һиҗрәт кылырга (күченергә) әмер ителә.

Авторның ***«күккә мигъраҗ кыла»*** дигән сүзләреннән чыккан файдалар:

1. Пәйгәмбәребезнең ﷺ яшерен гыйлемнәрдән сөйләгән сүзләренә карата без: ышандык, инандык һәм буйсындык, дибез.

2. Фарыз булган намазларның әһәмияте, Аллаһ Тәгалә бу гыйбадәтне безгә күктә фарыз кылган.

Һиҗрәт - ул кәфер иленнән ислам иленә күченеп китү. Кәфер иленнән Ислам иленә һиҗрәт кылу бу өммәткә фарыз һәм ул кыямәт көненә хәтле калачак. Моңа Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил:

"Дин өчен һиҗрәт итү лязем булып та, һиҗрәт итмичә, үзләренә золым кылган кешеләрнең рухларын алучы фәрештәләр әйтерләр: «Ни булды сезгә?», — дип. Ул кешеләр әйтерләр: «Без җирдә зәгыйфь булдык», — дип. Фәрештәләр әйтте: «Һиҗрәт кылырга Аллаһ җире сезгә киң иде түгелме? Ул кешеләрнең урыны җәһәннәм, ул җәһәннәм нинди яман урындыр. Мәгәр күчәргә көче җитмәгән зәгыйфь ирләргә, хатыннарга һәм балаларга күчмәгән өчен җәһәннәм газабы булмас, алар торган җайларында кәфер кулыннан котылырга хәйлә тапмасалар яки күчеп китәргә ничек тә көчләре җитмәсә. Бу гозерле кешеләрне Аллаһның гафу итүе бик өметледер, Аллаһ гафу итүче, ярлыкаучы булды" (4:97-99) . һәм тагын: "Ий, мөэмин бәндәләрем, тәхкыйк, Минем җирем киңдер, кайда гына булсагыз да, Миңа гыйбадәт кылыгыз" (29:56). Әл-Багауи (Аллаһ рәхимле булсын аңа) әйтә: "Бу аятьләрнең иңүенең сәбәпләре Мәккәдән күченмичә (һиҗрәт кылмыйча) калган мөселманнар белән бәйле. Әмма Аллаһ Тәгалә аларга "Иман китерүчеләр" дип мөрәҗәгать итә.

Һиҗрәтнең кирәклеге турында Сөннәттән дәлил булып Пәйгамбәребезнең сүзләре тора:

"Тәүбә кабул ителүдән туктаганчы һиҗрәт кылу бетмәячәк, ә тәүбә исә кояш көнбатыштан чыкканчыга кадәр кабул ителүдән тукталмаячак ".

## Һиҗрәт (калдыру) өч өлешкә бүленә:

| Кәфер дәүләтеннән Ислам дәүләтенә һиҗрәт кылу. | Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылу. | Аллаһ Тәгалә калдырырга кушкан нәрсәләрне (гамәлләрне, кешеләрне, какытны, урынны) һиҗрәт кылу (калдыру) . |
|---|---|---|
| Вәҗиб хөкемендә | Мәккә шәһәре ачылу белән бу гамәл тукталды. | |

***Гамәлләрдән***: Аллаһ Тәгалә хәрам кылган барлык нәрсәләрне калдыру, ә аларның иң зурысы – Ширек.

***Кешеләрдән***: кәферләрдән һәм монафыйклардан ерак булу.

***Вакыт***: Кәферләр үз бәйрәмнәрен үткәрә торган вакыттан ерак булу.

***Урын***: Кәферләр үз бәйрәмнәрен уздыра торган урыннардан ерак булу.

Ике нәрсә житү белән тәүбә кабул ителүдән туктаячак:

1- Кояш көнбатыштан чыккач.

2- Үлем вакыты житкәч: {Үлем галәмәтләре күренә башлагач кына тәүбә итүчеләрнең һәм кәфер хәлдә үлгән кешеләрнең тәүбәләре һич кабул түгел} **(4:18)**.

Пәйгамбәребезнең ﷺ: "(Мәккәне) ачканнан соң һиҗрәт юк" сүзләре Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт юк дигәнне аңлата. Бу сүзләр Мәккәнең башкача кәфер дәүләте булмаячагын раслый.

Пәйгамбәребез ﷺ Мәдинә шәһәрендә урнашкач, Ислам диненең калган шәригать әмерләре боерыла. Мисал өчен Зәкәт(1), Ураза, Хаҗ, Җиһад, Азан, яхшыллыкка өндәү, начарлыктан тыю һәм Ислам диненең башка хөкемнәре.

Пәйгамбәребезнең ﷺ шушы чакыруы ун ел дәвам итте, аннан соң ул бу дөньядан китте. (2).

Әмма аның дине калды һәм бу аның дине. Аның үз өммәтенә күрсәтми калдырган хәерлелеге юктыр һәм кисәтеп калдырмаган начарлыгы да юктыр. Ул өндәгән хәерлелек – Тәүхид һәм Аллаһ Тәгалә риза һәм яраткан барлык гамәлләр. Ул тыйган начарлык исә – ширек һәм Аллаһ Тәгалә яратмаган, Аның ачуын чыгара торган барлык гамәлләр (3).

(1) Гусеймин исемле шейх (Аллаh аңа рәхимле булсын) әйтә: «Зәкәт иң беренче Мәккәдә фарыз булган, ләкин аның микъдары нәрсәдән ничек биреләсе билгеле булмаган, ә Мәдинәдә аның күләме нәрсәдән ничек биреләсе билгеле булды».

(2) Пәйгамбәребез ﷺ hиҗрәттән соң унынчы елда үлә һәм Гайшә (Аллаh аңа рәхимле булсын) бүлмәсендә күмелә.

(3) *“Аның үз өммәтенә күрсәтми калдырган хәерлелеге юктыр һәм кисәтеп калдырмаган начарлыгы да юктыр”.* Пәйгамбәребез ﷺ үзенә тапшырылган әмәнәтне тулысынча безгә ирештергән, өммәтен нәсихәтләгән, Аллаh ризалыгы өчен хак көрәшү белән көрәшкән дип, без шәhәдәт бирергә тиешбез. Һәм ул безгә көн кебек ачык юлны калдырган, кем бу юлдан тайпыла, ул hәләкәткә юлыга.

## Иң каты тыелган гөнаhлар

- Зур ширек (Исламнан чыгара)
- Кече ширек (Исламнан чыгармый)
- Зур гөнаһлар Кәбәир (һәрбер гөнаһка үзенә хас булган җәза билгеләнгән)
- Кече гөнаһлар (тыелган, әмма үзенә хас җәза билгеләнмәгән гөнаһлар)

Аллаһ Тәгалә аны барлык кешеләр дөньясына җибәрде, кешеләргә һәм җеннәргә аңа буйсынырга боерды, моңа Аллаһның сүзләре дәлил: {Әйт: «Ий, кешеләр! Мин барчагызга — бөтен дөнья кешеләренә Аллаһтан җибәрелгән рәсүлмен»} **(7:158)** (1).

Аллаһ Тәгалә динне тулысынча ирештерде, моңа Аллаһ Тәгаләнең ошбу аяте дәлил булып тора: {Менә бүген динегезне тулы кылдым, бирәсе нигъмәтләремне дә ислам дине белән бергә биреп бетердем һәм ислам диненнән риза булдым.} **(5:3)** (2).

Пәйгамбәребезнең ﷺ вафатына Аллаһның әлеге сүзләре дәлил:
{дөреслектә, син дә үлүче, алар да үлүчеләрдер, үлемгә хәзерләнегез.
Соңрак кыямәт көнендә Раббыгыз хозурында дөньядагы золымнарыгыз өчен низагълашырсыз} **(39:30-31).**

(1) Пәйгамбәребез ﷺ барлык кешеләр дөньясына җибәрелде һәм моңарчы булган шәригать хөкемнәре гамәлдән чыгарылды. Пәйгамбәребез ﷺ заманындагы һәм хәзерге вакыттагы йәһүдләргә һәм насараларга, хәтта алар Муса һәм Гәйсә عليهم السلام шәригатьләрендә булсалар да, дәгъват ирешеп, алар Исламны кабул итмәсәләр һәм шушы дингә кермәсәләр, алар имансызлар хөкемендә булалар, һәм моңа дәлил:

1- Аллаһ Тәгаләнең сүзләре: {Әйт: «Ий, китаб әһелләре, безнең һәм сезнең өчен бер тигез хак булган Коръәндәге Аллаһ сүзләренә килегез! Ул сүзләр Аллаһтан башкага гыйбадәт кылмавыбыз һәм Аллаһка һичкемне тиңдәш кылмавыбыз, һәм дә Аллаһдан башка бер-беребезне Иләһ урнына тотмавыбыздыр»}. (3:64)

2- Аллаһ Тәгаләнең әлеге аяте: {Аллаһка һәм ахирәт көненә иман китермәгән кешеләр белән көрәшегез һәм Аллаһ һәм Аның рәсүле хәрам кылган нәрсәләрнең хәрамлыгына ышанмаган һәм хак дин — исламны дин итеп алмаган кешеләр белән көрәшегез!} (9:29).

3- Пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләре: **Минем җаным Кемнең кул астында, шуның белән ант итәм: кайсы йәһүди яки насара минем турыда ишетеп, миңа иман китермичә үлсә, ахыргы урыны җәһәннәм булачак.**

(2) Әлеге аять дингә яңалык кертүчеләргә каршы җавап.

# Бишенче: Йомгак өлеш.

(1) Һичшиксез, һәрбер кеше үлем ачысын татыячак, аннан соң, кыямәт көне житкәч, яңадан кубарылачак, һәм шуннан соң кылган гамәлләренә хисаб кылыначак.

(2) Кем дә кем яңадан терелүне инкяр итсә, ул имансыз хөкемендә була, чөнки яңадан терелүгә ышану иманның бер әркәне булып тора.

(3) Нух عليه السلام иң беренче Рәсүл. Аллаh Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил: {Сиңа вәхий кылдык, Нух пәйгамбәргә һәм аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхий кылган кебек} **(4:163).**

Әмма иң беренче Пәйгамбәр – Адәм عليه السلام. Һәм моңа дәлил шул: “**Адәм** عليه السلام . **Пәйгамбәрме?” – дип Пәйгамбәребездән** ﷺ **соралгач, ул: “Әйе, Пәйгамбәр”, - дип җавап биргән.**

Иң соңгы Рәсүл һәм Пәйгамбәр – Мөхәммәд ﷺ . Моңа Аллаh Тәгаләнең сүзләре дәлил: {Мөхәммәд – ирләрегезнең берсенең дә атасы булмады, ләкин ул Аллаһның рәсүле һәм пәйгамбәрләрнең ахыргысыдыр}. (33:40)

Кем дә кем үзен Пәйгамбәр яки Рәсүл дип саный һәм шуңа чакыра икән, бу кеше ялганчы һәм имансыз була. Кем дә кем шушы чакыручының сүзләренә инанса, ул да имансыз хөкемендә була.

Кешеләр үлгәннән соң яңадан тереләчәкләр. Аллаhның ошбу сүзләре моңа дәлил:
{Без сезне җирдән яраттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз, кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарабыз} (20:55) .
Шулай ук Аллаhның бу сүзләре дә дәлил:
{Аллаһ сезне җирдән яратты, ягъни Адәм җирдән халык ителде. Соңрак сезне шул җиргә кайтарыр, вә сезне тергезеп җирдән чыгарыр} (71:17-18) .
Кешеләр терелгәннән соң, аларның кылган гамәлләренә хисаб кылыначак, Аллаhның сүзләре моны дәлилли:
{Җирдәге һәм күкләрдәге барча нәрсә Аллаһ мөлкедер, Аллаһ аларны дөньяда имансыз, динсез явызларга газаб бирмәк өчен һәм иманлы динле булып, изге гамәлләрне, яхшы эшләрне кылган хак мөэминнәргә изге җәза, ягъни җәннәт ниґъмәтләрен бирмәк өчен төзеде} **(53:31)**(1).
Кем киредән терелүне инкяр итә, ул имансызлардан була, Аллаhның сүзләре моңа дәлил:
“Кәферләр үлгәннән соң терелү булмый» дип уйлыйлар, Син аларга әйт: «Әлбәттә, терелерсез, Раббымның исеме илә ант итеп әйтәмен, әлбәттә, терелеп каберләрегездән кубарылып чыгачаксыз, соңрак кылган эшләрегездән үзегезгә хәбәр бирелмеш булырсыз. Бу эш Аллаһка бик җиңелдер” (64:7).
(2).
Аллаh Тәгалә барлык Расүлләрне дә кешеләрне чакыру һәм кисәтү өчен җибәрде:
{Аллаһ Тәгалә Расүлләрне Аллаһка итагать итүче хак мөэминнәрне җәннәт белән шатландыручы һәм Аллаһка итагать итмәүчеләргә җәһәннәм газабы булачагы белән хәбәр бирүче илчеләр итеп җибәрде}(4:165).
Иң беренче рәсүл Нух عليه السلام , ә соңгысы Мөхәммәд ﷺ. Ул шулай ук иң соңгы Пәйгамбәр дә булып тора.
Иң беренче рәсүлнең Нух عليه السلام булуына дәлил:
{Сиңа вәхий кылдык, Нух пәйгамбәргә һәм аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхий кылган кебек} **(4:163)** (3).

Аллаһ Тәгалә үз колларының барчасына да тагутка ышанмаска, ә Аллаһка иман китерергә фарыз кылды. Ибн Каийм (Аллаһ аңа рәхимле булсын) әйтә:
“Тагут - ул колның үзенә карата куелган гыйбадәттәге, иярүдәге яки буйсынудагы чикләрдән узуы”.
Аллаһ Тәгалә Нухтан алып Мөхәммәдкә ﷺ кадәрге һәрбер өммәткә Рәсүлләр җибәрде, алар Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылырга чакырдылар һәм тагутка гыйбадәт кылудан тыйдылар. Аллаһның ошбу сүзләре моңа дәлил булып тора: **{без һәрбер өммәткә Рәсүлләр җибәрдек, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, тагуттан ерак булыгыз}**.
Тагутлар күптөрле була, төп тагутлар исә бишәү: Аллаһ тарафыннан ләгънәт кылынган иблис; Кешеләр аңарга гыйбадәт кыла торган һәм үзе шуннан риза булган зат; Үзенә гыйбадәт кылырга чакырган кеше; Башкаларга яшерен гыйлемнәрне белүе хакында белдергән зат; Аллаһ Тәгалә иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәүче.
Аллаһ Тәгаләнең әлеге сүзләре моңа дәлил: “Дингә көчләү юк, ялган белән хаклык ачык аерылды. Берәү Аллаһдан башканы Иләһ тотуны (тагутны) инкяр итеп, Аллаһка иман китерсә, ул һич тә өзелми-сынмый торган тоткага ябышты”.
Һәм бу “лә иләһә иллә Аллаһ” кәлимәсенең мәгънәсе.
Хәдистә дә әйтелгән: «**Диннең башы ислам (буйсыну), аның торагы – намаз, иң югары ноктасы (түбәсе) – Аллаһ юлында көрәшү (тырышлык кую).**

Аллаһ Тәгалә Рәсүлләрне һәм Пәйгамбәрләрне сөендерүче һәм кисәтүче итеп җибәргән. Алар барысы да тәүхидкә чакырганнар һәм ширеккә, башка нәрсәләргә табынучыларга каршы көрәшкәннәр. **{Без һәрбер өммәткә Рәсүлләр җибәрдек},** ягъни һәрбер халыкка, ди Аллаһ. **{"Аллаһка гыйбадәт кылыгыз"}**, ягъни бер Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, **{Тагуттан ерак булыгыз}**, ягъни алар (Тагутлар) бер тарафта калсын, сез икенче тарафта булыгыз дип кисәтә безне Раббыбыз, бу исә ераклашуның иң бөек дәрәҗәседер. Бу гамәл ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булуыңны раслаучы гамәл.

Аллаһ Тәгалә үз колларының барчасына да тагутка ышанмаска, ә Аллаһка иман китерергә фарыз кылды. Беренче чиратта, тагутка ышанмаска, аннан ерак булырга, ә аннан соң Аллаһка иман китерергә кирәк: **{Кем Тагутка ышанмый, ә Аллаһка иман китерә}**.
**Тагут** - *ул колның үзенә карата куелган гыйбадәттәге (мисал өчен ташларга яки агачларга гыйбадәт кылу), иярүдәге (мәсәлән, адашкан галимнәргә) яки буйсынудагы (әйтик, Аллах итагатеннән чыгучы ил башлыкларына) чикләрдән узуы.*
Тагутлар күптөрле була, төп тагутлар исә бишәү: Аллаһ тарафыннан ләгънәт кылынган иблис; Кешеләр аңарга гыйбадәт кыла торган һәм үзе шуннан риза булган зат; Үзенә гыйбадәт кылырга чакырган кеше; Башкаларга яшерен гыйлемнәрне белүе хакында белдергән зат; Аллаһ Тәгалә иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәүче.

## Аллаһ индермәгән хөкемнәр белән хөкем итмәүгә кагылышлы карарлар:

**Зур көферлек**

Әгәр кеше уйлап чыгарган хөкемнәр Аллаһ хөкемнәре кебек үк яки тагын да яхшырак дип уйласак һәм шуңа инансак, бу зур көферлек була.

**Кече көферлек**

Кеше уйлап чыгарган хөкемнәр ялган булуына (дөрес булмаганлыгына) ышансак, әмма бу хөкемнәрне нәфесебезгә бирелеп яки җитәкчелекне яратып үтәсәк, бу кече көферлек була.

## Йомгаклау:

Һәр акыл иясе әлеге китапка нык әһәмият бирергә тиеш, чөнки биредә динебезнең асыллары тупланган. Тагын шунысын да онытмыйк: һәр кеше, каберенә кергәч, бу асылларга чиксез мохтаҗ булачак.

<table>
<tr><td>Аллаh турында, аның Рәсүле ﷺ хакында һәм Ислам динен дәлилләр (ягъни өч асыл) нигезендә белү.</td><td>Гыйлем</td><td rowspan="6">Дүрт мәсьәлә һәм дәлилләре (әл-Гаср сүрәсе)</td><td rowspan="8">Кабердә бирелечәк өч сорау һәм аның дәлилләре: ни өчен без тәүхидне, өч асылны өйрәнәбез? Аларны өйрәнүдән нинди файдалар алабыз?</td></tr>
<tr><td>“Гыйлем гамәлне чакыра (гамәл кылырга чакыра), гамәл кылмасаң, гыйлем китә (алган гыйлемең онытылачак). “Үзенең гыйлеме белән гамәл кылмаучы гыйлем иясе кеше, потларга табынучыларга караганда да беренчерәк газапланылачак”.</td><td>Гамәл кылу (шушы гыйлем нигезендә).</td></tr>
<tr><td>Дәгъватның шартлары: ихласлык, дини гыйлем, хикмәт белән чакыру, сабыр булу, дәгъват кылына торган кешенең хәленә керә белү.</td><td rowspan="2">Дәгъват кылу (чакыру).</td></tr>
<tr><td>Иң беренче тәүхидкә чакыралар, чөнки бу Пәйгамбәрләрнең һәм Рәсүлләрнең дәгъваты. Тәүхидкә чакыру, ширектән тыю – дәгъватның иң югары дәрәҗәсе.</td></tr>
<tr><td>Аллаhка итагать итүдә сабыр булу. (Мәсәлән, Намаз укуда). Аллаhның тыйганнарыннан ерак булуда сабыр итү (мәсәлән, рибадан тыелу). Аллаhның тәкьдиренә (Аллаhтан килгән төрле сынауларга) сабыр булу (мәсәлән, фәкыйрьлеккә).</td><td rowspan="2">Сабырлык</td></tr>
<tr><td>Гыйлем алуга, аннан соң гамәл кылуга, аннан соң дәгъват кылуга сабыр итәргә кирәк.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тәүхид әр-Рубубийәh (Аллаhны Раббылыкта таныгач, Аны бер хакыйки илаh дип танырга кирәк ), Тәүхид әл-Әсмәә вә әс-Сыйфат</td><td rowspan="2">Өч мәсьәлә</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тәүхид әл-Үлүhиййәh (Ихласлык). Аллаh гыйбадәттә Үзенә кемне дә булса (Аңа якын фәрештәме ул яки җибәрелгән Пәйгамбәрме) тиңдәшлек (ширек) кылганнарына hич риза түгел.</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| Ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булырга кирәк: калеб белән (кәферләрне яратмау), тел белән “Мин сез гыйбадәт итә торган сыннарыгыздан бизүчемен” (43:26), тән әгъзәлары белән (аларга ошамас өчен бәйрәмнәрендә, күңел ачуларында катнашмау, ерак булу). | | |

**Кабердә бирелечәк өч сорау һәм аның дәлилләре: ни өчен без тәүхидне, өч асылны өйрәнәбез? Аларны өйрәнүдән нинди файдалар алабыз?**

**Тәүхид фәнен өйрәнүнең сәбәпләре**

**Әл-Хәнифийя**: диндә ихлас булып, ширек кылмыйча, Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу.

**Тел ягыннан**: “үәххәдә” тамырыннан алына, “бердәнбер”, “бер итү”, “бер генә” дигәнне аңлата.

**Шәригать ягыннан**: Аллаһны Үзенә генә хас булган Раббылыкта, иләһлектә һәм исем-сыйфатларында бер итү.

Һәм ул өч төргә бүленә :

**Тәүхид әр-Рубубийәһ**:Аллаһның гамәлләрендә бер итү, икенче төрле әйткәндә, Аллаһ кына бу дөнья белән идарә итә, Ул гына барлыкка китерүче, бу дөньяның Патшасы.

**Тәүхид әл-Үлүһийййәһ:** Аллаһны гыйбадәттә бер итү.

**Тәүхид әл-Әсмәә вә әс-Сыйфат:** Аллаһны, Үзенең Китабында Үзен-Үзе тасвирлаган һәм Аның Рәсүле ﷺ Аны тасвирлаган исемнәр һәм сыйфатлар белән, бу барлык сыйфатларны раслап һәм аларга капма-каршы булган барча нәрсәне инкяр итеп, кире какмыйча, “Ничек?” дигән сорау бирмичә, нәрсәгә дә булса охшатмыйча тасвирлау.

**Ширек ул** – Аллаһ Тәгаләдән башка бүтән иләһкә гыйбадәт кылу. Һәм дөнья йөзендә бу иң зур гөнаһларның берсе.

**Өч асыл**

Аллаһ Тәгаләне танып белү: Раббың кем? Раббыңны ничек танып белдең? Раббы - ул гыйбадәт кылына торган зат, гыйбадәтнең төрләре, Аллаһтан башка бүтән нәрсәләргә гыйбадәт төрләрен сарыф итүченең хөкеме дәлилләре белән.

Ислам динен дәлилләр белән өйрәнү, Исламның билгеләмәсе, Диннең баскычлары, Исламның эркәннәре, шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсе, Иманның эркәннәре, Иманның тармаклары, Ихсан, Диннең баскычларына дәлил, кыямәт көненең галәмәтләре.

Пәйгамбәребез ﷺ турында, аның нәселе, туган вакыты хакында белү. Яшен, Пәйгамбәр һәм Рәсүл булуын, ватанын, бу дөньяга җибәрелүенең хикмәтен, тәүхидкә чакырган вакытын, исра һәм миграҗны, кайда һәм кайчан намаз фарыз булганлыгын, һиҗрәт кылу хөкемен һәм вакытын, калган дин хөкемнәре кайчан иңгән булуын, дәгъватның дәвамлылыгын, вафат булуын, диндә нәрсә белән килүен, гомумән, кешеләр һәм җеннәр дөньясына килүен, диннең камиллеге һәм нигъмәтнең тулысынча ирешүе хакында белү.

## Кабердә биреләчәк өч сорау һәм аның дәлилләре: ни өчен без тәүхидне, өч асылны өйрәнәбез? Аларны өйрәнүдән нинди файдалар алабыз?

## Йомгаклау

Кешеләр үлгәннән соң яңадан тереләчәкләр, кешеләр терелгәннән соң аларның кылган гамәлләренә хисаб кылыначак. Киредән терелүне инкяр иткән кеше имансызлардан була. Рәсүлләрнең вазифалары, иң беренче һәм иң соңгы Рәсүл, тәүхиднен әркәне – тагутларга ышанмау (ялганага чыгару) һәм Аллаһка иман китерү, тагутның билгеләмәсе, тагутның төрләре, тагутка ышанмауның сыйфатлары, “Лә иләһә” кәлимәсенең мәгънәсе, диннең башы – ислам (буйсыну), диннең терәге – намаз, иң югары ноктасы (түбәсе) – Аллаһ юлында көрәшү (тырышлык кую).

**Тагут**

*ул колның үзенә карата куелган гыйбадәттәге (мисал өчен ташларга яки агачларга гыйбадәт кылу), иярүдәге (мәсәлән, адашкан галимнәргә) яки буйсынудагы (әйтик, Аллах итагатеннән чыгучы ил башлыкларына) чикләрдән узуы.* Тагутлар күптөрле була, төп тагутлар исә бишәү: Аллаһ тарафыннан ләгънәт кылынган иблис; Кешеләр аңарга гыйбадәт кыла торган һәм үзе шуннан риза булган зат; Үзенә гыйбадәт кылырга чакырган кеше; Башкаларга яшерен гыйлемнәрне белүе хакында белдергән зат; Аллаһ Тәгалә иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәүче.

Аллаһ белүче, Пәйгамбәребезгә ﷺ һәм аның йорт әһелләренә, сәхәбәләренә һәм Кыяматкә кадәр аңа ияргән барча кешеләргә салават һәм сәламнәребез булсын!

# Өч асыл буенча имтихан сораулары

**Җәя эчендәге дөрес җавапны сайлап ал (яки астына сыз):**

**1-** Өч асыл, кыскача әйткәндә, кабердә бирeләчәк сораулар (Дөрес – Хата).

**2-** Шушы китапта автор укучыга дога кылган (ике җирдә – өч җирдә).

**3-** Бу китап нәрсәсе белән аерылып тора? (җиңел эчтәлеге белән – кыскача әйтелү, аннан соң тирәнрәк аңлатылу белән – Коръәннән һәм сөннәтән дәлилләр китерелүе белән – укучыга дога кылу белән – хәзерге вакытта таралган шөһбәле фикерләргә җаваплар белән – башта сорау, аннан соң җавап килү белән – Аллаһ Тәгалә бу китапка өммәт тарафыннан кабул ителү биргән – барлык вариантлар да дөрес)

**4-** Өч асыл китабы ... бүлектән тора. (5 яки 6)

**5-** Тәүхидне өйрәнү ... (һәрбер кешегә фарыз, өммәткә фарыз).

**6-** Дүрт мәсьәләгә дәлил булып торган сүрә ("әл-Ихлас" сүрәсе, "әл-Гаср" сүрәсе).

**7-** Укып, гыйлем алып, алган гыйлеме нигезендә гамәл кылмаса, ул ... ошаган була (нәсараларга, йәһүдләргә, икесенә дә).

**8-** Сабырлык ... бүленә (ике төргә, өч төргә).

**9-** Ни өчен без Тәүхидне өйрәнәбез? (Аллаһ Тагәлә Тәүхидтән башка бер гамәлне дә кабул итми, Аллаһ Тагәлә безне Тәүхид өчен барлыкка китергән, Тәүхид тынычлыкка сәбәп була, бөтен вариантлар да дөрес)

**10-** Имам әш-Шәфигый “әл-Гәср” сүрәсе турында нәрсә әйткән? (кешеләргә дәлил буларак җитә, бүтән сүрәләрсез дә җитә).

**11-** Әгәр кеше Тәүхиднең бер төренә ышанып, калган төрләренә ышанмаса, ул тәүхид ияләреннән була (Дөрес, хата).

**12-** Ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булырга тиешбез: (тел, калеб, һәм тән әгъзәлары белән; ширекне кылучылардан, гамәлнең үзеннән, барысы да дөрес).

**13-** Аллаһның “...мәчетләр Аллаһка гыйбадәт кылу өчендер” дигән аятендәге мәчет дигән сүз – ул ... аңлата (Аллаһка гыйбадәт кылу өчен төзелгән бина; Кешенең сәҗдә кыла торган әгъзалары; Җир; барысы да дөрес).

**14-** Сәләфләребезнең юлы (башта дәлил, аннары игътикад – башта игътикад аннары дәлил).

**15-** Адашкан галимнәр ... ошаганнар (Йәһүдләргә – Нәсараларга).

**16-** Адашкан гыйбадәт кылучылар ... ошаганнар (Йәһүдләргә – Нәсараларга).

**17-** «Өч мәсьәлә” - ул “Өч асыл”. (Дөрес - Хата).

**18-** Дога бүленә: (сорау догасы һәм гыйбадәт догасы – гамәлләр аша кылынган дога, сүзләр аша кылынган дога).

**19-** Сорау догасы бүленә: (Ике төркемгә – дүрт төркемгә).

**20-** Сәбәпләргә карата кешеләр бүленделәр (ике тарафка – һәм урталыкта – зур ширек, кече ширек, рөхсәт ителгән).

**21-** Кешеләрдән  Истигасә (авыр чакта ярдәм сорау) рөхсәт ителгән: (нинди генә вакытта булса да – ул булдыра алган нәрсәдә генә – дүрт шарт үтәлеп, ул булдыра алган вакытта гына).

**22-** Лә иләһә илләЛлаһ кәлимәсенең мәгънәсе  (Барлыкка китерә алучы зат – Аллаһтан башка иләһ юк – Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы иләһ юк, барлык вариантлар да).

**23-** Диннәрне якынайту  (рөхсәт ителгән – зур гөнаһ, көферлек).

**24-** Гомумән, Аллаһның барлыгына дәлилләр (күп  – дүртәү).

**25-** Фәрештәләрнең калебләре бармы? (Әйе - юк).

**26-** Тәүхид белән Иманның бәйләнеше шул: Иман гомуми билгеләмәсе, ә тәүхид шуның бер өлеше  (әйе - юк).

**27-** Иманның әркәннәре саны (5,6,8).

**28-** Мөшрикләр дә Аллаһка табындылар (әйе – юк).

**29-** Аллаһтан башка берәр затка гыйбадәт кылсалар һәм ул зат шуннан риза булмаса (тагут  -  тагут түгел).

**30-** Аллаһның бу дөнья белән идарә итеп, яңгырлар яудыруында бер итү -  ул тәүхид ... (үлүһия - рубубия – исем һәм сыйфатлары).

**31-** Тәүхидне юкка чыгара (зур ширек – кече ширек – бидгать гамәлләр).

**32-** Иң беренче бурычыбыз Әти-Әнигә изгелек кылу (дөрес– хата).

**33-** Иң зур гөнаһлардан булып тора: зина, хаксыз кеше үтерү,  (дөрес – хата)

**34-** Миграҗ ул Пәйгамбәребезнең ﷺ  Мәккәдән Иерусалимга сәфәр кылуы  (дөрес – хата)

**35-** Пәйгамбәребез ﷺ җибәрелгән: (билгеле бер халыкка – кешеләргә һәм җеннәргә)

**36-** Пәйгамбәребез ﷺ (вафат – Пәйгамбәрләр үлмиләр).

**37-** Үлгәннән соң терелүне инкяр иткән кеше нинди көферлек кылган була? (зур көферлек– кечкенә көферлек).

**38-** Пәйгамбәрләрнең дине (бер – һәрбер Пайгәмбәрнең үз дине).

**39-** Һиҗрәт кылу (Мәккә ачылу белән бетте – кыямәт көненә хәтле булачак).

**40-** Һиҗрәт кылу ул - (кәфер иленнән ислам иленә күченеп китү – Аллаһ хәрам кылган нәрсәләрне калдыру).

**41-** Ислам дине камил дин, әмма хәерле кешеләрнең төшләре ярдәмендә тагын да камилләшә (дөрес – хата).

**42-** Аллаһтан башка бүтән нәрсәләргә гыйбадәтне багышлау кайсы ширек төренә керә? (зур ширек – кече ширек).

**43-** Гамәлнең хөкеме белән эшләүченең хөкемен аера белергә кирәк (дөрес - хата).

**44-** Иң беренче Пәйгамбәр (Нух عليه السلام, Адәм عليه السلام)

**45-** Пәйгамбәребез ﷺ ул (Пәйгамбәр – Рәсүл).

**А баганасында бирелгән гыйбарәләргә Б багансыннан туры килгән дөрес җавапны сайлап ал.**

| А | # | # | Б |
|---|---|---|---|
| Тәүхид тел ягыннан | | 1 | Имам Әхмәднең сүзләре: “Имансызны күрсәм, Аллаhның дошманын күрермен дип куркып, күзләремне кысам” . |
| Тәүхид шәригать ягыннан | | 2 | Үлгәннән соң була торган вакыйгаларга без иман китерергә тиешбез. |
| Тәүхид әл-Үлүhиййәh | | 3 | Тел белән әйтү, калеб белән ышану, тән әгъзалары белән гамәл кылу. Аллаhка итагать арткан саен иман арта hәм гөнаh кылган саен иман зәгыйфьләнә. |
| Тәүхид әр-Рубубийәh | | 4 | Ислам, Иман, Ихсан. |
| Тәүхид әл-Әсмәә уә әс-Сыйфат | | 5 | Аллаh өчен hәм Аллаhтан башкага |
| Әл-Хәнифийя | | 6 | Фарыз, рөхсәт ителгән, хәрам. |
| Коръәндәге иң беренче чакыру hәм иң беренче | | 7 | Шәригать hәм хисси |

| | | | |
|---|---|---|---|
| әмер | | | |
| Тиңләү | | 8 | Кабердә бирeләчәк сораулар |
| Хашия (курку) | | 9 | Гыйлем, гамәл, дәгъват, сабыр итү |
| Тәвәккәл | | 10 | Ихласлык һәм ияру |
| Гыйбадәт кабул булуының ике шарты | | 11 | (Кеше) Ихластан Аллаһка ышанып, Аңа таяна һәм рөхсәт ителгән сәбәпләрне кыла. |
| Кыскача дүрт мәсьәлә | | 12 | Гыйлемгә нигезләнгән курку – Аллаһның олугълыгын, көч-кодрәтен белеп курку |
| Кыскача өч мәсьәлә | | 13 | Охшаш, бертигез, аңа охшаган булган. |
| Кыскача өч асыл | | 14 | “Әл-Бакара” сүрәсендә |
| Сәбәпләр бүленә | | 15 | Ширектән ерагаеп, ихластан тәүхидкә, иманга омтылу |
| Нәзер әйтү бүленә | | 16 | Аллаһны, Үзенең Китабында Үзен-Үзе тасвирлаган һәм Аның Расүле ﷺ Аны тасвирлаган исемнәр һәм сыйфатлар белән, бу барлык сыйфатларны раслап һәм аларга капма-каршы булган барча нәрсәне инкяр итеп, кире какмыйча, “Ничек?” дигән сорау бирмичә, нәрсәгә дә булса охшатмыйча тасвирлау. |
| Корбан чалу бүленә | | 17 | Аллаһның бер үзенә генә гыйбадәт кылу. |
| Курку бүленә | | 18 | Аллаһның гамәлләрендә бер итү, икенче төрле әйткәндә, Аллаһ кына бу дөнья белән идарә итә, Ул гына барлыкка китерүче, бу дөньяның Патшасы. |
| Ислам | | 19 | Аллаһны үзенә генә хас булган нәрсәләрдә бер итү |
| Диннең баскычлары | | 20 | “үәххәдә” тамырыннан алына бердәнбер, бер итү, бер генә дигәнне аңлата |
| Иман | | 21 | Кояш көнбатыштан чыккач, үлем вакыты җиткәч |
| Кыямәт көненә иман китерү үз эченә ала | | 22 | ул колның үзенә карата куелган гыйбадәттәге, ияртүдәге яки буйсынудагы чикләрдән узуы. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ширектән ерак булу ул | | 23 | Тәүхид әр-Рубубийәһ, Тәүхид әл-Үлүһийййәһ, Тәүхид әл-Әсмәә уә әс-Сыйфат, ширектән һәм аның әһелләреннән ерак булу. |
| Тәүбә кылуның вакыты бетә | | 24 | ул Аллаһ Тәгаләгә бирелү, Аңа гына буйсыну, итагать итү, Аңа ширек кылудан һәм Аңа ширек кылучы әһелләрдән ерак булу. |
| Тагут | | 25 | Аллаһтан башка бүтәнгә, билгеле бер сүрәткә табыну. |

## Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| 1 | Кереш өлеш | 3-6 |
| 2 | Дүрт мәсьәлә | 7-10 |
| 3 | Өч мәсьәлә | 11-14 |
| 4 | Тәүхидне өйрәнүнең әһәмияте | 15 |
| 5 | Өч асыл | 16-42 |
| 6 | Йомгак өлеш | 43-45 |
| 7 | Китап буенча кыскача конспект | 46-49 |
| 8 | Өч асыл буенча имтихан сораулары | 50-53 |
| 9 | Таблица рәвешендәге имтихан сораулары | 54 |

# “Дүрт кагыйдә” китабы аңлатмасы

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Шәфкатьле һәм Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән**

Аллаһ Тәгаләгә барлык мактаулар булсын, Аннан гына ярдәм һәм гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз. Үзебезнең яманлыкларыбыздан һәм гамәлләребезнең начарлыгыннан Аллаһка сыенабыз. Аллаһ Тәгалә туры юлга күндергән кешене беркем дә туры юлдан яздыра алмас, Аллаһ юлдан яздырган кешене исә беркем дә туры юлга күндерә алмас. Бердәнбер, тиңе булмаган Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һичбер башка илаһ юклыгына һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм Аның колы һәм пәйгамбәре икәнлегенә шаһитлык бирәм.

# Кереш сүз

“Дүрт кагыйдә” - гыйлем алучы кеше өйрәнергә тиешле икенче китап. Моңа берничә сәбәп бар:

- Элеккеге буын галимнәренә ияреп, алардан үрнәк алып
- Бу китапны өйрәнергә кирәклеген галимнәр киңәш итте
- Бу китапта безнең заман мөшрикләренең шик-шөбһәләрен кире кагучы исбатлау язылган
- “Шикләрне бетерү” китабының кыскача аңлатмасы

Биредә китерелгән шикләр гыйлем алучының күңеленә үтеп кермәсен өчен, “Шикләрне бетерү” китабына кадәр әлеге китапны өйрәнү хәерле.

**“Дүрт кагыйдә” китабының эчтәлеге.**
**Бу китап өч өлештән тора:**

1. Кереш өлеш (бәхет билгеләре)

2. Тәүхидне өйрәнүнең әһәмияте

3.Кагыйдәләр

## Беренче: кереш өлеш (бәхет билгеләре)

(1) Юмарт Аллаһтан Бөек Гәршнең Раббысыннан бу дөньяда һәм ахирәттә сине яклаучы булуын сорыйм (2), һәм кая гына булсаң да сине мөбарәк итсә иде (3).

**(1) Авторның “Бисмилләһ” белән башлавының сәбәпләре шулар:**

1. Аллаһның Китабына һәм Пәйгамбәрләргә ияреп (алардан үрнәк алып)

2. Алдагы буын галимнәргә ияреп. Гадәттә, алар китапларын “Бисмилләһ” белән башлый торган булганнар.

3. Аллаһның исеме белән башланган эш бәрәкәтле булачак

(2) Галим, Аллаһ Тәгалә аның гөнаһларын кичерсен, гадәте буенча бәсмәләдән соң (“Бисмилләһ”) гыйлем алучыга дога кылу белән башлый. Һәм бу аның гыйлем алучыны яратуына һәм Аллаһ Тәгаләдән ана хәерлелек соравына дәлил булып тора.

(3) Аллаһның дуслары – алар иман белән тәкъвалыкны бергә берләштергән кешеләр.

Бер галим әйткән رَحِمَهُ ٱللَّهُ: “ Кем иман китереп, тәкъва булса, менә шул кеше Аллаһның дусларыннан була”. Моңа дәлил Аллаһның сүзләре:

***“Аллаһ дусларына һич куркыныч юк һәм алар хәсрәттә калмаячаклар, алар - иман китереп , тәкъвалыкка ирешкән кешеләр”***

***(10:62).***

Бәрәкәт (мөбарәк) : ул арту, күбәю, дигән сүз.
*Тәбәррүк* : бәрәкәт сорау, дигәнне аңлата.
Мөбарәк : кайда гына булмасын, һәр җирдә файда китерүче кеше.

*Тәбәррук* ике өлешкә бүленә:

Тыелган *Тәбәррук*. Шәригатьтә расланмаган һәм физик тойгы белән дә сизелми торган гамәлләрдән булса, мондый тәбәррук тыелган һәм ул кече ширк була.

Рөхсәт ителгән *Тәбәррук*

Шәригать ягыннан:

мәсәлән, хәрам мәчетендә яки пәйгамбәребез мәчетендә намаз уку

Физик тойгы:

мәсәлән, гыйлем, дога. Кеше үзенең гыйлеме аша һәм яхшылыкка өндәү сәбәпле бәрәкәткә ия була. Чөнки кешеләр бу гыйлемнән файда, бик күп хәерлелек ала. Галимнәрнең китапларына карасак та, Аллаһ Тәгалә аларның китапларына һәм гыйлемнәренә бәрәкәт биргән, бүгенге көндә дә кешеләр аларның гыйлемнәреннән иситкеч күп файда ала.

Һәм сине биргән нигъмәтләре нә шөкер итүчеләрдән кылса иде(1)

Аллаһның безгә биргән нигъмәтләре, безнең өчен сынау булып (1) тора, моңа дәлилләр бик күп: ***{ без сезне яманлык һәм яхшылык белән сыныйбыз, боларны сезгә фетнә кылып сынау йөзеннән}(21:35). "...Бу тәхетнең шулай тиз килүе Раббымның фазлыннандыр, шөкер итәрме яки көферлек кылырмы дип мине сынар өчендер. Берәү шөкер итсә, үзе өчен шөкер итәдер, һәм берәү нигъмәткә көферлек итсә, тәхкыйк Раббым байдыр, аның шөкер итүенә мохтаҗ түгелдер" (27:40). "Әмма адәм баласы, Раббысы аны дөнья байлыгы белән сынап караса һәм дөнья эшләрендә кешеләр арасында хөрмәтле итсә, ул мине Аллаһ хөрмәтләде дияр " (89:15***).

Һәм хәдистән дәлил: Аллаһ Тәгалә Бәни Исраил кавемендәге өч кешене сынап карый...

**Тәүхид үлүһия һәм тәүхид рубубия белән бәйле нигъмәтләр. Бу нигъмәтләргә шөкер итү ике өлешкә бүленә:**

Нигъмәт килгәннән соң шөкер итү:

Калеб белән

Тел белән

Тән әгъзалары белән

Барлык нигъмәтләр Аллаһ Тагәләдән генә, Ул гына ризык биреп торучы икәнлегенә, Ул гына нигъмәтләр биреп торуына бер шиксез ышану

Аллаһның нигъмәтләре турында сөйләү, Аны мактау, хәмед-сәнәләр әйтү һәм шөкер итү. Аллаһ Тәгалә әйтә: ***“Раббыңның нигъмәтләре турында сөйлә”*** (93:11).

Аллаһ биргән нигъмәтләрне Ул риза булган һәм Аңа итагать итүдә Аңа якынайта торган юлларда куллану. Һәм гөнаһлы гамәлләрдән ерак булып, Аның кушканнарын үтәүдән гыйбарәт

Нигъмәт килгәнче кешенең Аллаһ белән бәйләнеше

Бу төр бәйләнеш кешедән нигъмәт бирүче ул Аллаһ Тәгалә генә дип бер шиксез ышануны һәм калебен Аллаһтан башка бер кем белән дә бәйләмәүне, бер кемнән дә хәерлелек сорамауы таләп итә.

Аллаһ Тәгаләдән безне Җәннәткә кертүен сораган кебек (чөнки Ул гына җәннәт хуҗасы), шулай ук ризыкны да без Аллаһтан башка бирәүдән дә сорарга тиеш түгелбез.

***{ һәрвакыт тере, һич үлми торган Раббыңа тәвәккәл ит }*****(25:58).**

***{ Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган сыннарыгыз сезгә ризык бирә алмыйлар, һәм ризыкны Аллаһтан сорагыз, һәм Аңа гына гыйбадәт кылыгыз, һәм Аңа шөкер итегез }*** **(29:17).**

(1)Бөтен галимнәрнең дә фикере буенча сабыр итү – фарыз.

Әгәр дә бәла-каза килсә, сабыр итә(1). Һәм гөнаһ кылса, истигъфар кыла (Аллаһ Тәгаләдән гафу сорый). Дөреслектә, шушы өч сыйфат бәхетнең билгеләре булып тора.

**Бәла-каза килгән вакытта кешеләр дүрт төргә бүленә:**

- Шөкер итүче
- Риза булучы
- Сабыр итүче
- Риза булмаучы

1.Риза булмау – хәрам булып тора һәм ул иң зур гөнаһлардан санала. Ул менә нәрсәләрдә чагылыш таба:

- Калебтә
- Телдә
- Гамәлләрдә

- Калеб белән ризасызлык белдерү: Ибн Каийм әл-Джәузия әйткән: кайбер кешеләрнең тел белән ризасызлык белдерергә кыюлыклары җитми, әмма калебе белән, үзенең уй-фикерләрендә Раббысы турында начар уйлый ул: Раббым миңа золымлык кылды, Раббым мине мәхрүм кылды һ.б. Хәзер инде үзеңә кара: сиңа да авырлык килгән вакытта шундый ук уй-фикерләр килмиме?

- Тел белән ризасызлык белдерү: кеше кычкыра, каргый башлый, ризасызлыгын сүзләр белән белдерә.
- Ризасызлыкның кешенең гамәлләрендә чагылышы: кеше яңакларына суга башлый, кесәләрен ерта, чәчләрен йолкый башлый.

2. Сабырлык: галимнәрнең бердәм фикере буеча бәла-каза килгәндә сабыр итүнең хөкеме вәҗиб (мәҗбүри) булып тора. Без калебебез белән, телебез белән, тән әгъзаларыбыз белән сабыр итәргә тиешбез. Имам Әхмәд әйтә: “Сабырлык Коръәндә туксаннан артык җирдә зикер ителә, һәм ул, галимнәрнең бердәм фикере буенча, вәҗиб булып тора. Ул Иманның яртысы, дөреслектә Иман ике өлештән тора, беренче өлеше сабырлык, икенче өлеше шөкер итү”. (“Мәдәриҗү сәликин” китабыннан)

3. Риза булу: ул сабырлыктан өстенрәк дәрәҗәдә, аның хөкеме мөстәхәб (мәслихәт) булып тора.

4. Шөкер итү: ул иң фазыйләтлесе, иң бөек дәрәҗәлесе, хөкеме шулай ук мөстәхәб булып тора.

# Икенче: дүрт кагыйдә

Бел! Аллаһ сине Үзенә итагатъ итә торган туры юлга күндерсен. Дөреслектә, Әл-Хәнифийя – ул Ибраһим (гәләйһи сәләм) юлы. Диндә ихлас булып, Аллаһның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу юлы. Аллаһ Тәгалә барлык кешеләргә дә шуны әмер иткән һәм аларны бары шуның өчен генә барлыкка китергән. Аллаһ Тәгалә әйтә: **{Мин кешеләрне һәм җеннәрне Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен барлыкка китердем}(51:56).**(1)

Әгәр Аллаһ сине Үзенә гыйбадәт кылыр өчен генә барлыкка китерүен аңласаң, шуны да бел: намаз тәһарәтсез була алмаган кебек, гыйбадәт тә тәүхидсез була алмый. Әгәр гыйбадәткә ширек керсә, нәҗес тәһарәтне бозган кебек, ул да гыйбадәтне нәкъ шулай боза. Ширек гыйбадәтне боза. Гыйбадәт ширек белән кушылса, мондый гамәл файдасызга әверелә һәм бу гамәлне кылучыны мәңгелек җәһәннәм көтә. Димәк, бу хакта өйрәнү безнең иң мөһим бурычыбыз булып тора. Бәлки шул вакытта Аллаһ безне ширк дип аталучы афәтнең ятьмәсеннән коткарыр. Аллаһ Коръәндә шул хакта әйтә: **{Аллаһ үзенә тиңдәшлек (ширек) кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр}(4:48).**

Моның өчен син Раббыбыз Аллаһ Үзенең Китабында телгә алган дүрт кагыйдәне белергә тиешсең.

**Беренче кагыйдә**: Син шул хакта белергә тиешсең: Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) көрәшкән мөшрикләр дә Аллаһны Раббы итеп, Ризык бирүче, Терелтүче, Үтерүче, галәмдәге барча эшләр белән Идарә итүче итеп таныдылар. Әмма бу танулары аларны Исламга кертмәде. Моңа Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил:

**{Әйт: "күктән һәм җирдән кем ризыкландыра? Яки хуҗа булып сезгә күз һәм колакларны кем бирә? Кем үлене терелтә, ә терене кем үтерә? һәм бөтен эшләр белән кем җитәкчелек итә?». Әлбәттә, Аллаһ диярләр. Әйт: «Ә Аллаһтан курыкмыйсыз мени?» (10 :31)** (2) **.**

(1) Автор, Аллаһ аңа рәхимле булсын, тәүхидне өйрәнүебезнең сәбәбен аңлатып китә.

(2) Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) расүл итеп җибәрелгән имансызлар да Аллаһны Раббылыкта бер итеп таныдылар, әмма шуңа да карамастан, Аллаһның расүле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) алар белән көрәште. Чөнки алар Аллаһны гыйбадәт кылуда бер итеп танымадылар. Аллаһка гына багышлыйсы гыйбадәтләрне башка иләһләргә табынган һәрбер кеше имансыз мөшрик була.

**<u>Икенче кагыйдә:</u>** Мөшрикләр әйттеләр: «Без сыннарга бары тик алар безне Аллаһка якынайтсын һәм Аллаһ каршында безне якласын өчен генә ялварабыз һәм мөрәҗәгать итәбез. Без бит аларның яклавы аша һәм алар аркылы Аллаһка якынаеп, ихтыяҗларыбызны Аллаһ канәгатьләндерүен телибез".

Аларның бу сүзләренә дәлил булып Аллаһның сүзләре килә: **{Аллаһдан башка сынымнарны дус тоткан мөшрикләр әйтерләр: «Без аларга гыйбадәт кылмыйбыз, мәгәр безне Аллаһка якын кылсыннар өчен генә аларга гыйбадәт кылабыз», - дип. Аллаһ аларның хыйлафлык кылган сүзләре һәм гамәлләре белән кыямәт көнне аларны хөкем итәр. Дөреслектә, Аллаһ Исламга көферлек итүчене һәм ялганчыны туры юлга күндермәс}** (39:3) (1).

Аларның *«Әш-шәфә'ә»* - шәфәгать хакындагы сүзләренә карата дәлил булып Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре тора:

**{Мөшрикләр Аллаһтан башка файда да һәм зарар да ирештерә алмый торган сынымнарга гыйбадәт кылалар. Мөшрикләр әйттеләр: «ул сынымнар безнең шәфәгатьчеләребез", — дип»} (10:18).**

Шәфәгать ике төргә бүленә: тыелган һәм рөхсәт ителгән шәфәгать. (2)

Тыелган шәфәгать — Аллаһның гына кодрәте җиткән шәфәгатьне Аллаһтан башка заттан сорау. Аллаһның сүзе моңа дәлил: **{Ий мөэминнәр! Без сезгә биргән байлыктан Аллаһ юлына һәм мохтаҗларга садака бирегез, кыямәт көне килмәс борын, сатып алу сәүдәсе булмас һәм ул көндә дуслык һәм шәфәгать итү эшләре булмас. Әмма Коръән белән гамәл кылмыйча кәфер булган кешеләр алар җәһәннәмгә утын булдылар} (2:254)**.

Рөхсәт ителгән шәфәгать — Аллаһның гына кодрәте җиткән шәфәгатьне бары Аллаһтан гына сорау. Шулай ук Аның каршында бары тик Ул яклаучылык хокукын биргән зат кына яклаучы була ала, һәм бары тик гамәлләре һәм сүзләре белән Аллаһ разый булган кешене генә Аллаһның рөхсәте белән яклыйлар. Аллаһның ошбу сүзләре моңа дәлил: **{Ахирәттә Аллаһ хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, һичкем үз теләге белән һичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһ рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр}(2:255).**

(1) Мөшрикләр үзләренең төрле потларга, сыннарга мөрәҗәгать итеп ялваруларын бары тик алар аркылы Аллаһка якынаерга теләүләре һәм Аллаһ каршында ул потлардан шәфәгать сораулары белән үзләрен аклыйлар. Әлеге гамәлләре өчен Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аларны имансызлыкта гаепләде һәм аларга каршы булды.

(2) *«Әш-шәфә'ә»* - шәфәгать сүзенең телдәге мәгънәсе – "ялгау", "бернең икегә әверелүе".

*Шәригатьтәге мәгънәсе* – икенче берәүгә файда китерү яки зыянны кире кайтару максаты белән арадашчы сыйфатында чыгыш ясау.

# ШӘФӘГАТЬНЕҢ ТӨРЛӘРЕ

## Тыелган шәфәгать

Ул Коръән тарафыннан тыелган. Аллаһның гына кодрәте житкән нәрсәләрдә шәфәгатьне Аллаһтан башка заттан сорау. Мондый шәфәгать зур ширк була.

## Кешенең мөмкинлекләре чикләрендә булган әйберләрдә шәфәгатьчелек

Кешенең мөмкинлекләре чикләрендә булган әйберләрдә шәфәгатьчелек. Ул шушы дүрт шарт үтәлгәндә дөрес булачак:

1. Шәфәгать кылучы, яклаучы кеше исән булырга тиеш;
2. Ул бирedә, синең янда булырга тиеш;
3. Әлеге кешенең сине яклау, сиңа шәфәгать кылу мөмкинчелеге булырга тиеш;
4. Синдә әлеге кешенең бары тик сәбәп кенә булуына инану булырга тиеш.

## Рөхсәт ителгән шәфәгать

Рөхсәт ителгән шәфәгать – әлеге шәфәгатьне бары тик Аллаһтан гына сорыйлар һәм аның түбәндәге шартлары бар:

1. Аллаһның рөхсәте.
2. Шәфәгать кылган кешедән Аның риза булуы.
3. Шәфәгать кылынучы кешедән Аның риза булуы.

### *Гомуми шәфәгатьчелек*

*Гомуми шәфәгатьчелек,* ул пәйгамбәрләр, фәрештәләр, иманлылар, әти-әниләреннән алдарак вафат булган кечкенә балалар тарафыннан башкарылачак.

- Җәннәттә иманлыларның дәрәҗәсен арттыру хакында
- Иманлыларның җәһәннәм утына керүдән (кылган гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә лаек булганнарын) коткару хакында
- Кылган гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә кергән иманлыларны аннан чыгару хакында

### *Бары тик Пәйгамбәребезгә генә хас шәфәгатьчелек*

*Бары тик Пәйгамбәребезгә генә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) хас шәфәгатьчелек.*

- Бөек шәфәгатьчелек
- Абыйсы Әбу Талиб өчен, аның җәһәннәмдәге газапларын җиңеләйтү өчен
- Җәннәт капкаларын ачу хакындагы үтенеч

**<u>Өченче кагыйдә</u>** (1): Дөреслектә, Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе вә рәхмәте булсын) гыйбадәтләре аерылып торган кавемгә килде. Бу кавем кешеләре арасында кояш һәм айга, фәрештәләргә, пәйгамбәрләргә һәм изгеләргә, таш һәм агачларга гыйбадәт кылучылары бар иде. Пәйгамбәребез (Аллахның аңа сәламе вә рәхмәте булсын), аларның барысына каршы, һич нинди аерымлык күрсәтмичә, бердәй көрәште (хаклыкка өндәде) Аллаһ Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил: **{ Алар белән көрәшегез (хаклыкка өндәгез), хәтта фетнә беткәнче һәм диннең барчасы Аллаһ дине генә булганчы} (2:193)**.

Кояш һәм айга табынучы мөшрикләрнең барлыгына Аллаһ Тәгаләнең шушы сүзләре дәлил: **{ Төннең һәм көннең яратылышы, кояш һәм айның төзелеше һәм хәрәкәтләре Аллаһның кодрәтенә һәм берлегенә дәлил итә торган галәмәтләреннәндер, ий кешеләр, кояшка һәм айга сәждә кылмагыз, чөнки алар да сезнең кебек мәхлукләрдер, бәлки барча нәрсәне барлыкка китерүче Аллаһка сәждә кылыгыз, әгәр сез Аллаһка гына гыйбадәт итә торган булсагыз? }(41:37)**.

Фәрештәләргә табынучы мөшрикләрнең барлыгына Аллаһ Тәгаләнең шушы сүзләре дәлил: **{ Ул пәйгамбәр сезгә фәрештәләрне һәм пәйгамбәрләрне Илаһ итеп алыгыз димәс }(3:80)**.

(1) Әлеге кагыйдәдә ширк потларга табынган очракта гына була ала, дип раслаган кешеләргә ачык дәлил булып тора. Ә шәригать дәлилләре ул вакытта булган потларга табыну турында да, башка табыну объектлары хакында да сөйли. Һәм Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аларны аерып карамаган, киресенчә, боларның барысын да “тагутка” гыйбадәт дип санаган һәм динебез тулаем Аллаһка багышлансын өчен Аллаһка табынмаганнарның барысына да каршы, һичнинди искәрмәләрсез, көрәш (хаклыкка өндәү эшен) алып барган.

Пәйгамбәрләргә табынучы мөшрикләрнең барлыгына Аллаһ Тәгаләнең шушы сүзләре дәлил: **{ "Ий Мәрьям угълы Гыйса! Син кешеләргә әйттеңме, мине һәм анамны Аллаһдан башка Иләһ тотыгыз", – дип. Гыйса әйтте: "Ий Раббым! Син һәрбер кимчелектән пакьсең, синең хакта миңа муафикъ түгел сүзне әйтмәү лаек түгелдер, әгәр андый сүзләрне әйткән булсам, әлбәттә, син аны беләсең. Ий Раббым, син минем күңелемдә булган нәрсәне, әлбәттә, беләсең әмма мин синдә булган нәрсәне белмимен. Әлбәттә, Син яшерен нәрсәләрне бик яхшы белүчесең.}(5:116)**.

Изгеләргә табынучы мөшрикләрнең барлыгына Аллаһ Тәгаләнең шушы сүзләре дәлил: **{Мөшрикләр Аллаһ дип белеп гыйбадәт кылган затлар, ягъни Гыйса вә Гозәерләр үзләре Аллаһка гыйбадәт кылып һәм итагать итеп Аңа ярарга, якын булырга тырышалар һәм рәхәтен өмет итеп, ґәзабыннан куркалар иде. Әлбәттә, Раббыңның гәзабы бик каты булу сәбәпле саклану тиеш булган ґәзабтыр.}(17:57)**.

Агач һәм ташларга табынучы мөшрикләрнең барлыгына Аллаһ Тәгаләнең шушы сүзләре дәлил: **{ Лут, Гүзза исемле сынымнарны күрдегезме һәм алардан башка өченче Мәнат исемле сынымны күрәсезме?} (53:19-20).**
Һәм шулай ук агачларга табынучы кешеләр барлыгына Әбу Вакида әл-Ләйсидән килгән хәдис тә дәлил булып тора: “*Пәйгамбәребез* (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) *белән без Хунәйнгә юл тоттык. Ул вакытта без әле яңа гына имансызлыктан ваз кичеп, мөселманнар булган идек. Ә мөшрикләрнең “Зат Әнват” исемле агачлары булып, шунда кораллар элелә иде, мөшрикләр, үзләренең йолаларын башкау өчен әлеге агач янына җыйналалар иде. Әлеге агач яныннан үткәндә, без дә әйттек: “Әй, Аллаһның расуле, безгә дә аларныкы кебек “Зат Әнват” агачын яса”, - дидек”...”* (хәдистән өзек.)

**<u>Дүртенче кагыйдә:</u>** Чынлыкта, безнең заман мөшрикләренең ширкләре борынгы мөшрикләрнекенә караганда куркынычрак. Чөнки элеккеге мөшрикләр иминлектә булганда Аллаһка тиңдәш тоттылар, ә авыр хәлләрдә исә алар ихласлык белән Аллаһка мөрәҗәгать итәләр иде. Безнең заман мөшрикләренә килсәк, аларның Аллаһка ширк китерүләре иминлектә дә, авыр хәлләрдә дә тукталмый. Аллаһның сүзләре моңа дәлил булып тора: **{Имансызлар көймәгә утырсалар, диндә ихлас кешеләр кебек Аллаһка ялваралар, әгәр Аллаһ аларны диңгездә сәламәт йөртеп, кораблары белән корыга кайтарса, алар яңадан мөшрик булалар.}(29:65).**
Аллаһ яхшырак белә һәм Мөхәммәдкә, аның нәселенә, сәхәбәләренә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!

(1) Әлеге кагыйдәдә автор хәзерге заман мөшрикләре кылган ширкнең ни дәрәҗәдә куркыныч булуын аңлатты. Бүгенге мөшрикләрнең ширкләре үткән заманнар мөшрикләрнекенә караганда күпкә куркынычрак. Чөнки хәзерге заман мөшрикләре ширкне иминлектә дә, авыр хәлләрдә дә кылалар. Ә элеккеге мөшрикләр бары тик имин вакытларында гына Аллаһка тиңдәш тотып, авыр хәлләрдә исә Аллаһның Берлеген таныганнар.

Әгәр пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) җибәрелгән элеккеге мөшрикләрнең ширкләре җиңелрәк булып саналса, һәрвакыт: авырлыкта да, иминлектә дә Аллаһка ширк кылучы хәзерге заман мөшрикләре хакында ни әйтергә?! Мондый кешеләр имансыз дип аталуга күбрәк лаек.

**«Дүрт кагыйдә» - ул «Шикләрне бетерү» («Кашф әш-шубухат») китабының кыскача эчтәлеге.**

**Кереш өлештә бәхет билгеләре телгә алына**

| Бәхет билгеләре | | | |
|---|---|---|---|
| Нигъмәт бирелгәндә рәхмәтле була | Бирелгән нигъмәтләр өчен рәхмәтле булу. Нигъмәт – ул сынау { Без сезне сырхау, ачлык кебек яманлык һәм сәламәтлек, байлык кебек яхшылык белән сыныйбыз, яки саваб белән гөнаһ арасында сезне сыныйбыз, боларны сезгә фетнә кылып сынау йөзеннән }(21:35). | Аллаһны Раббылыкта бер иту белән бәйле | Җәннәтне бары тик Аллаһтан гына сорарга ярый, чөнки җәннәтнең Хуҗасы бары Аллаһ. Нәкъ шулай ук байлыкны да бары Аллаһтан гына сорарга ярый. Аллаһтан башка бүтән затка түгел, ә бәлки Аллаһка бәйләнергә кирәк . |
| Нигъмәт бирелгәндә рәхмәтле була | Бирелгән нигъмәтләр өчен рәхмәтле булу. Нигъмәт – ул сынау | Аллаһны гыйбадәттә бер иту белән бәйле | Йөрәк белән рәхмәтле булу. Ул бөтен нигъмәт һәм фазыйләтләрнең башка заттан түгел, ә Алаһтан булуын йөрәк белән танудан гыйбарәт. |
| Нигъмәт бирелгәндә рәхмәтле була | Бирелгән нигъмәтләр өчен рәхмәтле булу. Нигъмәт – ул сынау | Аллаһны гыйбадәттә бер иту белән бәйле | Тел белән рәхмәт әйтү : { Мине сынар өчен Раббым шул нигъмәтне бирде, әллә шөкер итүчеләрдән булмыйммы? }(27:40). |
| Нигъмәт бирелгәндә рәхмәтле була | Бирелгән нигъмәтләр өчен рәхмәтле булу. Нигъмәт – ул сынау | Аллаһны гыйбадәттә бер иту белән бәйле | Әгъзалар белән рәхмәт әйтү. Ул Аллаһ биргән нигъмәтләрне Аллаһка рәхмәт өчен куллanudan гыйбарәт. Әмма һәр нигъмәт тиешенчә файдаланырга тиеш. Мәсәлән, материаль байлык Аллаһ риза булган максатларда кулланыла; гыйлем өчен рәхмәт гыйлемне сорап килүчеләргә бирү сыйфатында чагыла. |
| Сынау килгәндә сабыр итә | Кайгы-хәсрәт килгәндә кешеләр үз-үзләрен тотышлары буенча дүрт төркемгә бүленәләр | | Үзләренең йөрәкләре, телләре һәм әгъзалары белән ризасызлык һәм канәгатьсезлек белдерүчеләр. Мондый гамәл зур гөнаһ, хәтта кече ширк дәрәҗәсенә дә җитәргә мөмкин. |
| Сынау килгәндә сабыр итә | Кайгы-хәсрәт килгәндә кешеләр үз-үзләрен тотышлары буенча дүрт төркемгә бүленәләр | | Сабырлык күрсәтүчеләр. Ислам дине белгечләренең бердәм фикере буенча, бу гамәл мәҗбүри (вәҗиб).Сабырлыкның тәме әче, әмма аның нәтиҗәсе татлы. |
| Сынау килгәндә сабыр итә | Кайгы-хәсрәт килгәндә кешеләр үз-үзләрен тотышлары буенча дүрт төркемгә бүленәләр | | Ризалык белдерүчеләр.Мондый гамәл кирәк, мәслихәт булып тора. Аның тулаем чагылышы безнең белән булган барлык нәрсәләр дә Аллаһтан һәм ул биргән һәрбер нәрсә нигъмәт икәнлегенә инану. |
| Сынау килгәндә сабыр итә | Кайгы-хәсрәт килгәндә кешеләр үз-үзләрен тотышлары буенча дүрт төркемгә бүленәләр | | Шөкер итүчеләр. Бу иң бөек дәрәҗә һәм ул Аллаһның шөкер итүче колларына хас. |
| Гөнаһ эшләсә, истигъфар сорый | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «*Әл-Хәнифиййя*» - Ибраһим дине, ул Бер Аллаһка табынудан гыйбарәт; Аллаһ сине шуның өчен яралткан. Тәүхидтән башка гыйбадәт – гыйбадәт түгел. Ширк гыйбадәтне боза, әгәр гыйбадәткә ширк кушылса, гамәлләр бозыла, һәм шуны кылучыны мәңгелек утка дучар итә, шуңа күрә әлеге мәсьәләне өйрәнү синең иң мөһим вазифаң булып тора. | Тәүхидне өйрәнүнең сәбәбе һәм ширкнең хәтәрлеге | | |
| Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) вакытындагы имансызлар Аллаһны Раббылыкта бердәнбер итеп таныйлар иде (тәүхид әр-рубубиййя), әмма мөселман булмадылар, чөнки алар Аллаһны гыйбадәткә лаеклы бердәнбер зат икәнлеген инкарь иттеләр (тәүхид әл-улюхиййя). | | Дүрт кагыйдә | |
| Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) вакытындагы имансызлар потларга Аллаһка якынаю өчен, ул сыннар Аллаһ каршында шәфәгатьче булсыннар, дип табындылар. | | | |
| Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) төрле объектларга табынучы кешеләргә расүл булып килде, әмма ул ширкнең бөтен формалары белән дә, аларның берсен дә аермыйча, көрәште. | | | |
| Хәзерге заман мөшрикләренең ширкләре элеккеге мөшрикләрнең ширкләренә караганда куркынычрак. | | | |

# ИМТИХАН СОРАУЛАРЫ

Исем ............................ «Дүрт кагыйдә» китабын яттан өйрәндеңме?
…………..……………………….…………….

| Сораулар | Коръән һәм Сөннәттән дәлил |
|---|---|
| **Бирелгән нигъмәт - сынау** | |
| **Имансызлар Аллаһны Раббылыкта бер итеп таныйлар иде** | |
| **Аллаһка Аллаһтан башка затларга табыну аркылы якынаерга тырышу** | |
| **Тыелган шәфәгатьчелек** | |
| **Мөшрикләрнең бер өлеше кояш һәм айга табынуларына дәлил** | |
| **Мөшрикләрнең бер өлеше фәрештәләргә табынуларына дәлил** | |
| **Мөшрикләрнең бер өлеше пәйгамбәрләргә табынуларына дәлил** | |
| **Мөшрикләрнең бер өлеше изгеләргә табынуларына дәлил** | |
| **Мөшрикләрнең бер өлеше ташларга һәм агачларга табынуларына дәлил** | |
| **Мөшрикләр кайгы килгәндә ихластан Аллаһка табыналар, ә иминлек булганда ширк кылалар иде** | |
| **Ширк турында дәлил** | |

**Түбәндәге сорауларга җавап бир:**

| | |
|---|---|
| **Ни өчен без Тәүхидне өйрәнәбез?** | -2 -1<br>-4 -3 |
| | -8 -7 -6 -5<br>-9 |
| **Ни өчен без “Дүрт кагыйдә”не өйрәнәбез?** | -1<br>-2 |
| | -4 -3 |
| **“Дүрт кагыйдә” китабы ошбу өлешләргә бүленә:** | -2 -1<br>-3 |
| **“Дүрт кагыйдә” китабы ... китабының кыскача эчтәлеге:** | |
| **Ни өчен без «Шикләрне бетерү» китабын өйрәнмибез?** | |
| **Бәхет билгеләре** | -2 -1<br>-3 |
| ***Әл- хәнифиййә – ул ...*** | |

| | |
|---|---|
| **“Дүрт кагыйдә” китабын өйрәнүнең җимешләре** | |
| **Аллаһның дуслары - ул ...** | Бер галим әйтте: |
| **Моңа дәлил** | |
| **Бирелгән нигъмәтләргә рәхмәт … (мисаллар белән)** | -1 |
| | -2 |
| | -3 |
| **Колның Аллаһ белән бәйләнеше нинди булырга тиеш?** | |
| **Кайгы килгәндә кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары һәм мондый гамәлләргә ислам диненең карашы** | -1 |
| | -2 |
| -4 | -3 |
| **«Әш -шәфә’ә» шәфәгать сүзенең телдәге мәгънәсе:** | **«Әш -шәфә’ә» шәфәгать сүзенең шәригатьтәге мәгънәсе:** |
| **«Әш -шәфә’ә» ничәгә бүленә?** | -2 -1 |
| **Расланган шәфәгатьнең шартлары** | -3 -2 -1 |
| **Расланган шәфәгать бүленә:** | |
| | **-** 1 ул үз чиратында бүленә: |
| | -2 ул үз чиратында бүленә |
| **Беренче кагыйдә** | |
| | |
| **Икенче кагыйдә** | |
| | |
| **Өченче кагыйдә** | |
| | |
| **Дүртенче кагыйдә** | |
| | |
| **Ширк кушылган гыйбадәт хакында фикер** | Моңа дәлил: |

# Эчтәлек


| Дүрт кагыйдә | | |
|---|---|---|
| 1 | Кереш өлеш һәм бәхет билгеләре | 1 |
| 2 | Беренче кагыйдә | 7 |
| 3 | Икенче кагыйдә | 8 |
| 4 | Өченче кагыйдә | 10 |
| 5 | Дүртенче кагыйдә | 12 |
| 6 | Кушымта (китапның кыскача таблица рәвешендә күрсәтү) | 13 |
| 7 | Имтихан сораулары | 15 |
| 8 | Эчтәлек | 17 |



# «Динебезне бозучы гамәлләр» китабына аңлатма

# Динебезне бозучы гамәлләр

**Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән!**
**Бел: динебезне бозучы гамәлләр унау:**

***Беренчесе:*** Гыйбадәттә Аллаһка тиңдәшлек кылу (ширк). Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Аллаһ үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр»**. Шулай ук Ул әйтте: **«Берәү Аллаһка тиңдәшлек кылса, Аллаһ ул кешегә җәннәтне хәрам кылды һәм аның кайтачак урыны җәһәннәмдер, аларны җәһәннәмнән коткарырга ярдәмче булмас»**. Корбанны Аллаһка түгел, ә җенгә яки кабергә, дип чалу моның мисалы булып тора.

***Икенчесе:*** галимнәрнең бердәм фикере буенча, Аллаһ белән үзе арасында арадашчы булдырган һәм шуларга ялварган, шәфәгать сораган, өмет баглаган кеше көферлеккә төшә.

***Өченчесе:*** мөшрикләрне кәфер итеп санамаган, яки аларның көферлегендә шикләнгән, яки аларның юлын дөрескә санаган кеше – имансыз була.

***Дүртенчесе:*** башка затның җитәкчелеге пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) җитәкчелегенә караганда камилрәк яки башка хөкемнәр Аллаһның расуленекенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) караганда яхшырак, дип инанган, тагут хөкемнәрен Аллаһның расуле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) хөкемнәренә караганда өстенрәк күреп, гамәл кылган кеше – имансыз була.

***Бишенчесе:*** пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) нәрсә белән килде, шуларны дошман күргән кеше, хәтта алар нигезендә гамәл кылса да, имансыз була.

***Алтынчысы:*** Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) алып килгән диннең нәрсәсен булса да, яки Аллаһ Тәгаләнең әҗер-савап бирүеннән, яки Аның җәзасыннан көлгән, мыскыллаган кеше көферлеккә төшә. Моңа Аллаһның ошбу сүзләре дәлил: **«Әйт: "Әй сез Аллаһ тарафыннан Аның аятьләрен вә Аның расүлен мәсхәрә итәсезме? ". Акланмагыз! Иман китергәннән соң кәфер булган кешеләр, Коръән белән гамәл кылмыйча көферлекләрен арттырдылар ...».**

***Җиденчесе:*** сихерчелек, моңарга сихер чыгару да, сөйдергечләр ясау да керә. Кем дә кем аны башкарса яки шул эштән канәгатьлек алса, ул кеше көферлеккә төшә. Моңа Аллаһның ошбу сүзләре дәлил: **«Бу ике фәрештә сихерне һичкемгә өйрәтмәделәр, һәм әйттеләр: "Дәреслектә без сезгә фетнәбез, Аллаһ безне сезне сихер белән сынар өчен җибәрде, әгәр сихер белән шөгыльләнсәгез кәфер булырсыз."».**

***Сигезенчесе:*** мөселманнарга каршы мөшрикләргә ярдәм һәм булышлык күрсәтү. Аллаһның сүзләре моңа дәлил: **«Әгәр Сезләрдән берәү динсез кардәшләрен дус тотса, ул кеше алардан булды. Аллаһ, әлбәттә, Коръән белән гамәл кылмаучы залимнәрне туры юлга күндермәс».**

***Тугызынчысы:*** Хозыр Муса (галәйһиссәләм)шәригате чикләреннән чыккан кебек, кайбер кешеләр Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шәригате чикләреннән чыга ала, дип инанган кеше имансыз була.

***Унынчысы:*** Аллаһның диненнән, аны өйрәнүдән, аның нигезендә гамәл кылудан баш тарту. Моңарга Аллаһның ошбу сүзләре дәлил булып тора: **«Раббысының аятьләре белән вәгазьләнеп, ул вәгазьләрдән баш тарткан кешедән дә залимрәк кеше булырмы? Без, әлбәттә, залимнәрдән үч алучыбыз».**

Әлеге гамәлләр, эшләнергә мәҗбүр ителгәннәреннән тыш, уйнап, мәзәк итеп, чынлап яки куркудан эшләнәме – алар арасында һичнинди дә аерма юк. Һәм бу гамәлләрнең барысы да еш кылына торган, иң куркыныч һәм хәтәр гамәллләрдән санала. Шуңа күрә мөселман кешесе алардан читтә торырга, аларга якын бармаска һәм аларны кылмасам ярар иде дип, үзе өчен куркырга тиеш. Аллаһтан Аның ачуына һәм газаплы җәзаларга китерә торган нәрсәләрдән яклау сорыйбыз. Аллаһның кешеләр арасындагы иң күркәм заты булган Мөхәммәдкә, аның сәхәбәләренә һәм дәвамчыларына Аллаһның сәламе һәм рәхмәтләре булсын.

# АҢЛАТМА

## Авторның кереш сүзе

**Шәфкатьле һәм Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән!**
**Бел: динебезне бозучы гамәлләр унау.**

Ни өчен галимнәр үз хезмәтләрен бәсмәләдән («Бисмилләһ») башлыйлар?

- Аллаһның Китабына һәм Пәйгамбәрләргә ияреп (алардан үрнәк алып).
- Алдагы буын галимнәргә ияреп.
- Әлеге сүзләр аша Аллаһ Тәгаләдән фатиха һәм бәрәкәт сорап.
- «**Аллаһның исеме белән башланмаган мөһим эшләр...**», дигән хәдискә ияреп, әмма ул дөрес хәдис түгел.

Корьәндә һәм сөннәттә гамәлләр билгеле бер сан белән чикләнгәнме?

- Әгәр Корьәннең һәм сөннәтнең башка урыннарында әлеге саннан үзгә сан килсә (ягъни әлеге санны тулыландырып килгән гамәлләр булса), бу очракта әлеге гамәлләр баштагы сан белән генә чикләнмәячәк. Мисал өчен пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) бер хәдисен алыйк: *«Һәлакәткә китерә торган җиде гөнаһтан сакланыгыз...»*
- Әгәр Корьәннең һәм сөннәтнең башка урыннарында әлеге саннан үзгә сан килмәсә (ягъни әлеге санны тулыландырып килгән гамәлләр булмаса), бу очракта әлеге гамәлләрнең саны шуның белән чикләнәчәк. Мәсәлән, Джәбрәил хәдисендәге Ислам һәм Иман әркәннәре.

**Ни өчен кайвакыт гамәлләр шуның белән генә чикләнмәгән сан телгә алына?**

Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) үзенең сәхәбәләрен иң яхшы рәвештә өйрәтү осталыгы шуннан гыйбарәт. Әлеге саннарны телгә алу сәхәбәләргә аларны яттан өйрәнергә һәм вакыт үткәч искә төшерергә мөмкинчелек биргән, нәкъ пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сүзләрендәгечә: *«Мин сезгә өч нәрсә белән ант итәрмен һәм сезгә нәрсәдер әйтермен, ә сез аны истә калдырырсыз! Сәдака колның мөлкәтен киметми ...»*. Әлеге китап авторы да шул рәвешле эшли.

**Ни өчен без Ислам динен бозучы гамәлләрне өйрәнәбез?**

Алардан саклану һәм аларны кылмау өчен, шуңа күрә әлеге гамәлләрне өйрәнүнең файдасы бик зур, алай гына да түгел, аның файдасы иң әһәмиятлеләрнең берсе. Тәһәрәтнең бозылу-бозылмавын белү өчен без аны бозучы гамәлләрне өйрәнәбез; намазыбыз дөрес булсын өчен дә аны бозучы гамәлләрне белү зарур. Хүзейфә, Аллаһ аннан разый булсын, әйтә иде: «Кешеләр пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) яхшылык хакында сорыйлар иде, ә мин, андый гамәлне кыла күрмим тагын дип, аннан һәрчак начарлык турында сорадым».

**Нәрсә ул «динне бозучы гамәлләр»?**

Ул Ислам динен бозучы, кешене Исламнан зур көферлеккә чыгаручы нәрсәләр. Ә **Ислам** ул – тәүһид аша үзеңне Аллаһка багышлау, ширктән һәм мөшрикләрдән ваз кичү аркылы Аңа буйсыну.

**Аның мәгънәсе:**

Мөселманны Исламнан зур көферлеккә чыгаручы гамәлләр.

Аллаһ безне имин кылсын.

**Галимнәрнең әлеге гамәлләргә карата фикере бердәмме?**

Әйе.

**Ни өчен галимнәр кайвакыт «Исламны бозучы гамәлләр...», ә кайвакыт «Исламны гамәлдән чыгаручы эшләр...» диләр?**

Алар бу гыйбарәләрнең икесен дә бертөрлелек туйдырмасын өчен кулланалар, аларның мәгънәләре бер үк.

**Бу гамәлләр сан белән чикләнгәнме?**

Юк.

**Ни өчен соң автор аларны унау диде?**

Ул бу гамәлләрнең иң хәтәрләрен күрсәтергә теләде; шулай ук истә калдырырга җиңел булсын дип, аларның санын күрсәтте.

Исламнан чыгаручы гамәлләрне билгеле бер төрләргә бүлеп буламы?

Сүз

Мәсәлән, Аллаһны, аның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) яки динне мыскыллау - шундый гамәлләрдән.

Гамәл

Мәсәлән, сихерчелек.

Инану

Мәсәлән, Аллаһтан башка бүтән зат файда китерә ала, дип инану.

Шик

Мәсәлән, Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) хаклыкка чакыруы ирешеп тә иманга килмәүчеләрнең көферлегендә шикләнү.

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) бу ун гамәлне телгә алдымы? Һәм моңа дәлил нинди?
Әйе, расулебез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) алар хакында әйтә иде. Алай гына да түгел, һәр гамәлгә Коръәннән һәм сөннәттән дәлил бар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әнә шулай аятьләребезне кешеләргә ачык итеп бәян кылабыз, азгыннарның адашу юлы ачык беленсен өчен».**

***<u>Әлеге гамәлләрне кылган кешенең көферлеге хакында һәркем карар чыгара аламы?</u>***
***<u>Юк, киресенчә, билгеле бер кешенең көферлеге хакында карар чыгарганда, иманлы галимнәргә, шәригать хөкемнәренә мөрәҗәгать итү зарур. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: «Үзенең кардәшенә: "Әй, кәфер!", - дигән кеше үзе имансызлардан булыр».</u>***

Исламнан чыгаручы гамәлләр хакындагы хезмәтләрне кем язган?
Фикх буенча хезмәтләр язган барча авторлар да бу гамәлләрне китапларының көферлек хакындагы бүлекләрендә искә алалар иде. Әмма әлеге китапның авторы бу гамәлләргә багышланган аерым хезмәтне язучы беренче кеше булды.

***<u>Гамәл белән ул гамәлне кылучы арасында аерма бармы?</u>***
***<u>Әйе, һәм аларны аерып карау зарур. Чөнки мондый гамәлне кылган һәркем көферлеккә төшкән дигән сүз түгел әле. Билгеле бер затны көферлектә гаепләү өчен аңа дәлилне җиткерү һәм шөбһәләрне бетерү тиешле. Авторның, Аллаһ аңа рәхимле булсын, максаты да билгеле бер кешеләрне көферлектә гаепләү түгел иде. Аның максаты – кешеләрне Исламнан чыгаручы гамәлләрдән кисәтү. һәм өммәт өчен вәгазь-нәсихәт тә шуннан гыйбарәт.</u>***

Бу гамәлләр хакында белгән мөселманның вазифасы нинди?

Мөселман кешесе бу гамәлләрдән ерак торырга, аларны кылудан куркырга, сакланырга, шулай ук башкаларны да алардан кисәтергә тиеш. Ә билгеле бер кешеләрнең көферлеге хакындагы фикерләргә килсәк, бу мәсьәләдә олугъ галимнәргә һәм шәригать хөкемнәренә мөрәҗәгать итү кирәк.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһка карышуыгыз аңар авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер. Шуның соңында да иманнан баш тартсалар, син аларга әйт: «Миңа Аллаһ җитә, бит Аллаһдан башка гыйбадәткә лаеклы Илаһи зат юк, мәгәр Ул гына, Аңарга гына тәвәккәл кыламын һәм Ул олугъ Гәрешнең Раббысы».**

**(9:128-129)**

## Беренче гамәл

Гыйбадәттә Аллаһка тиңдәшлек кылу (ширк). Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Аллаһ үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр»(4:116).** Шулай ук Ул әйтте: **«Берәү Аллаһка тиңдәшлек кылса, Аллаһ ул кешегә җәннәтне хәрам кылды һәм аның кайтачак урыны җәһәннәмдер, аларны җәһәннәмнән коткарырга ярдәмче булмас».(5:72)** Аллаһка түгел, ә каберләргә һәм җеннәргә корбан китерү кебек гамәлләр – моның мисалы була ала.

### Ширкнең төрләре

| Зур ширк – автор ширкнең нәкъ менә шушы төрен күздә тотты | Кече ширк |
|---|---|
| Аның асылы Аллаһтан башка бүтән затның галәм белән яшерен идарә итә алуына яки кешеләргә файда китерү һәм зыянны булдырмый калу аның кулында, дип инанудан гыйбарәт. | Аның асылы Аллаһ сәбәп итеп яралтмаган нәрсәләрне сәбәп итеп санаудан гыйбарәт. Һәм зур ширккә илтә торган нәрсәләрнең барысы да кече ширк була. |
| • Кешене диннән чыгара;<br>• Барлык гамәлләрне дә юкка чыгара;<br>• Кешене мәңгелеккә җәһәннәмгә кертә;<br>• Шәригать текстларында «зур» дип атала ала;<br>• Әгәр шәригатьтә «ширк» яки «көферлек» сүзләре килеп, ул сүзләр «әл» билгелелек артикле белән бергә торса. | • Кешене диннән чыгармый;<br>• Үзе кушылган гамәлне юкка чыгара;<br>• Кешене мәңгелеккә җәһәннәмгә кертми;<br>• Шәригать текстларында «кече» дип атала ала;<br>• Әгәр шәригатьтә «ширк» яки «көферлек» сүзләре килеп, ул сүзләр «әл» билгелелек артикле белән бергә тормаса. |

### Зур ширк Аллаһ тарафыннан гафу ителәме?

Аллаһ Тәгаләнең сүзләре шуны дәлилли – әгәр кеше ширки гамәлне үтәп вафат булса, әлеге гамәл гафу ителми: **«Аллаһ үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр»**. Әгәр кеше исән вакытында тәүбә итсә, ул гафу ителәчәк, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Минем мөэмин бәндәләремә әйт: "Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә иткәндә Аллаһ барлык гөнаһларны ярлыкаучыдыр". Аллаһ гафу итүче вә рәхмәт кылучы булды "»(39:53)**. Әмма тәүбә итүнең дә шарты бар: ул кояш көнбатыштан чыкканчыга кадәр кылынырга тиеш. Моңа пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сүзләре дәлил: *«Хиджрә тәүбә вакыты бетмичә, ә тәүбә кояш көнбатыштан чыкмыйча туктамас»*. Шулай ук тәүбә кылу жаның бугазыңа терәлгәнче булырга тиеш, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Үлем галәмәтләре күренә башлагач кына тәүбә итүчеләрнең һәм кәфер хәлдә үлгән кешеләрнең тәүбәләре һич кабул түгел. (4:18)**

## Тыелган гамәлләрнең төрләре

### Кечкенә гөнаһлар

Аларның барысын да Аллаһ Тәгалә тыйды, әмма алар өчен билгеле бер җәза билгеләмәде.

### Зур гөнаһлар

Бу – аны кылган өчен билгеле бер җәза (мәсәлән, ләгънәт кылыну яки бу гөнаһны кылучыга катышмау кебек) вәгъдә ителгән теләсә-кайсы гамәл. Җәза шулай ук гөнаһ кылучыны кәфер яки мөшрик итеп тасвирлау яки иң әшәке хайванга тиңләү рәвешендә дә булырга мөмкин.

### Кече ширк

Зур ширккә караганда гөнаһысы азрак, ә зур гөнаһларга караганда гөнаһысы күбрәк

### Зур ширк

Иң каты тыю белән тыелган

#### Зур гөнаһларның хөкеме

Тәүбә итү мәҗбүри, чөнки Аллаһның расуле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: *«Үлемене чаклы тәүбә кылмаган елаучы хатын...»*, шулай ук икенче хәдистә: *«...әгәр зур гөнаһлардан сакланса ...»*

#### Аларның дәрәҗәләре бармы?

Әйе, алар бер-берсеннән дәрәҗәләре белән аерылалар. Пәйгамбәребез әйтте: *«Зур гөнаһларның олугълары...»*

#### Зур гөнаһлар кылучының хөкеме

- Ул иманы кимчелекле булган кеше. Ягъни үзенең иманы дәрәҗәсендә иманлы, үзенең гөнаһысы дәрәҗәсендә имансыз;
- Аны иманына нисбәтле рәвештә яратырга һәм гөнаһысына нисбәтле рәвештә яратмаска кирәк;
- Кеше зур гөнаһ кылганда, аның белән булырга ярамый.

#### Зур гөнаһларның саны:

Сан белән чикләнмәгән, әмма югарыда телгә алынган тасвирлау белән чикләнгән.

**Мал чалу төрләре**

**Аллаһ ризалыгы өчен**

Мондый хайван чалу канунлаштырылган. Әл-хадий, әл-удхия, шулай ук малны итен сәдака итеп өләшү өчен чалу төрләре бар.

**Аллаһтан башка бүтән затның ризалыгы өчен, ул затны яратып һәм олугълап (автор нәкъ менә шушы төрне күздә тотты)**

Бу гамәл зур ширк була. Моңа мисал: җенгә яки кабергә корбан чалу.

**Рөхсәт ителгән, хәләл**

Мәсәлән, ашау, яки кунак сыйлау, яки итен сату өчен сарык чалу.

## Икенче гамәл

Галимнәрнең бердәм фикере буенча, Аллаһ белән үзе арасында арадашчы булдырган һәм шуларга ялварган, шәфәгать сораган, өмет баглаган кеше көферлеккә төшә.

### Шәфәгать төрләре

**Аллаһтан башка һичкем булдыра алмаган (көч-куәте житмәгән) шәфәгать.**

**Тыелган шәфәгать (автор әлеге төрне күздә тотты)**

Ул Коръән тарафыннан тыелган. Аллаһның гына кодрәте житкән нәрсәләрдә шәфәгатьне Аллаһтан башка заттан сорау. Мондый шәфәгать зур ширк була.

**Рөхсәт ителгән шәфәгать**

Әлеге шәфәгатьне бары тик Аллаһтан гына сорыйлар һәм аның түбәндәге шартлары бар:

1. Аллаһның рөхсәте.
2. Шәфәгать кылган кешедән Аның риза булуы.
3. Шәфәгать кылынучы кешедән Аның риза булуы.

**Шәфәгать кылырга булдыра алган (көч-куәте житкән) затлардан шәфәгать сорау**

Ул шушы дүрт шарт үтәлгәндә дөрес булачак:

1. Шәфәгать кылучы, яклаучы кеше исән булырга тиеш;
2. Ул биредә, синең янда булырга тиеш;
3. Әлеге кешенең сине яклау, сиңа шәфәгать кылу мөмкинчелеге булырга тиеш;
4. Синең калебеңдә әлеге кешенең бары тик сәбәп кенә булуына инану булырга тиеш.

**Гомуми шәфәгать, ул пәйгамбәрләргә, фәрештәләргә, иманлыларга хас**

- Җәннәттә иманлыларның дәрәҗәсен арттыру хакында;
- Иманлыларның җәһәннәм утына керүдән (кылган гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә лаек булганнарын) коткару хакында;
- Кылган гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә кергән иманлыларны аннан чыгару хакында.

**Хосусый, бары тик пәйгамбәребезгә генә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) хас шәфәгать.**

- Бөек шәфәгатьчелек;
- Абыйсы Әбу Талиб өчен, аның җәһәннәмдәге газапларын җиңеләйтү өчен;
- Җәннәт капкаларын ачу хакындагы үтенеч.

**Кардәшеңә: «Минем өчен дога кыл», - дип әйтү рөхсәт ителгәнме?**
Әгәр дә аның әлеге үтенечендә бу кешегә карата мохтаҗлыгы чагылса, бу кече ширкнең бер төре була. Әгәр ул бу хакта исән, янында булган, дога кылырга сәләтле булган кешедән сораса һәм ул кешенең бары тик сәбәп кенә булуында инанса, бу рөхсәт ителә. Әмма моны эшләмәү яхшырак.

**Тәвәккәл кылу**
Кешенең Аллаһка ышаныч, хаклык белән, рөхсәт ителгән, канунлаштырылган сәбәпләрне кулланып, Аңа таянуы.

**Рөхсәт ителгән төре**
Исән кешегә, аңарда мохтаҗлык кичермичә генә, үзең эшләргә вәкаләт биргән әйберләрдә генә таяну. Мисал өчен, кемгәдер нәрсәдер сатарга вәкаләт бирү.

**Тәвәккәл кылуда кече ширк**
Исән кешегә, аңарда мохтаҗлык һәм ихтыяҗ кичереп, таяну. Мисал өчен: икенче кешегә язмыш мәсьәләсендә, аңа сәбәп буларак кына түгел, ә аны зуррак дәрәҗәгә куеп таяну.

**Тәвәккәл кылуның, әгәр аны Аллаһка багышламасаң, зур ширк булган төре (автор нәкъ менә шушы төрне күздә тотты)**
Бу тәвәккәлнең мәгънәсе – табыну һәм буйсыну. Кешенең үзе тәвәккәл иткән затына, файда китерү дә, зыяннан саклау да аның кулында, дип инанган халәттә, берсүзсез таянуы. Мисал өчен, вафат булганнарга таяну.

**«Мин шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» яки «Мин Аллаһка тәвәккәл иттем, аннан соң шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» дип әйтергә ярыймы? Әлеге мәсьәләдә хакыйкать нидә?**
«Мин шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» дип тә, «Мин Аллаһка тәвәккәл иттем, аннан соң шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» дип тә әйтергә ярамый, чөнки тәвәккәл кылу – Аллаһтан башка бүтән затка багышларга ярамый торган калеб гамәле. Әмма: «Мин шуны-шуны вәкаләтле иттем», ягъни нидер эшләргә тапшырдым, дияргә ярый. Пәйгамбәребез дә бит (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) үзенең кайбер сәхәбәләренә кайсыбер шәхси яки җәмәгать эшләрен куша торган булган.

## Өченче гамәл

**Мөшрикләрне кәфер итеп санамаган, яки аларның имансызлыгында шикләнгән, яки аларның юлын дөрескә санаган кеше – имансыз була.**

### Ислам динендә мөшрикләрнең урыны

Аллаһның илчесенең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) хаклыкка өндәвен ишетеп тә иманга килмәгән һәркем имансыз була. Аллаһ Тәгалә әйтте: **« Берәү ислам диненнән башка дингә иярсә, аның дине һәм гамәле һич кабул булмый, ул ахирәттә хәсрәтләнүче һәм һәлак булучыдыр » (3:85).**

### «Китап әһелләре» мөшрикләр рәтенә керәме?

Әйе, Аллаһның расуленә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) иман китермәгән Китап әһелләре мөшрик була, Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләре моңа дәлил: **«Аллаһка һәм ахирәт көненә иман китермәгән кешеләр белән көрәшегез һәм Аллаһ һәм Аның рәсүле хәрам кылган нәрсәләрнең хәрамлыгына ышанмаган һәм хак дин — исламны дин итеп алмаган кешеләр белән көрәшегез! » (9:29).** Шулай ук пәйгамбәребез дә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: *«Мөхәммәднең җаны кулында булган зат белән ант итәм, бу өммәттән булган яһүд яки насара минем турында ишетеп, минем аша җибәрелгән дингә иман китермичә үлеп китсә, ахыргы урыны җәһәннәм булачак».*

### Бу хөкем алар белән булган килешүләребезгә тугъры булмаска тиеш дигәнне аңлатамы?

Юк, Аллаһның мәхәббәтенә ирешү өчен без имансызлардан булган кеше белән килешүебезгә тугъры булырга тиешбез, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Алар сезнең белән сүзләрендә торсалар, сез дә сүзегездә торыгыз! Аллаһ, әлбәттә, килешүләрне бозудан саклануучыларны сөя»(9:7)**. Имансызлар белән булган мөнәсәбәтләрдә кешеләр берничә төркемгә бүленә:

- Мөселман булмаган халыклар белән аларның бәйрәмнәрендә, тантаналарында, йолаларында катнашучы кешеләр.
- Мөселман булмаган халыкларга карата аларны үтерү, талау, алдалау һ.б.ш. аша чикләрне бозучы кешеләр.
- Урталыкта торучы сөннәт әһелләре. Бу аларның бәйрәм һәм йолаларында катнашмаудан, әмма шул ук вакытта алар белән булган мөнәсәбәтләрдә чикләрне узмаудан һәм булган килешүләрне саклаудан гыйбарәт. Шулай ук безгә алар белән сәүдә эшләрендә хезмәттәшлек итәргә дә рөхсәт. Һәм аларны тәүһидкә чакырырга кирәк.

## Дүртенче гамәл

Башка затның җитәкчелеге пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) җитәкчелегенә караганда камилрәк яки башка хөкемнәр Аллаһның расуленекенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) караганда яхшырак, дип инанган, тагут хөкемнәрен Аллаһның расуле (Аллаһның аңа сәламе һәс рәхмәте булсын) хөкемнәренә караганда өстенрәк күреп, гамәл кылган кеше – имансыз була.

### Аллаһ иңдергән буенча булмаган хөкем төрләре

Тагут хөкемнәрен һәм уйлап чыгарылган кануннарны Аллаһ хөкемнәре һәм кануннарына караганда өстенрәк күреп, Аллаһ хөкемнәрен һәм кануннарын яраксыз, дип инанган кеше зур көферлек кыла, бу көферлеге аны Ислам диненнән чыгара. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Алар Аллаһны ташлап үзләренең галимнәрен яки Заһидләрен Раббылары итеп алдылар»(9:31).**

Әгәр кеше Аллаһның хөкемнәрен һәм кануннарын гамәлгә ашыру кирәк һәм әлеге кануннар Аллаһның коллары өчен яхшырак дип инанган булса, әмма үзенең нәфесенә ияреп яки үзенең идарә итү вазифасында калырга теләп, тагут канунарын өстен күрсә, бу кече көферлек була. Әгәр кеше әлеге кануннарга нигезләнеп, мөселман кешесенең хак һәм хокукларын бозган икән, ул залимнәрдән була. Мондый кеше Ислам диненнән чыгаручы зур көферлек чигендә тора.

## Бишенче гамәл

**Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) алып килгән нәрсәләргә нәфрәтле булса, хәтта алар нигезендә гамәл кылса да, имансыз була.**

### Әлеге гамәлнең Ислам диненнән чыгаруы хакындагы дәлил

Аллаһ Тәгалә әйтте: **« Бу хөкем аларга Аллаһ иңдергән Коръәнне мәкъруһ күргәннәре өчендер, гамәлләрен батыл кылды. »(47:9)**, Ул шулай ук әйтте: **« Раббың исеме белән ант итеп әйтәм, мөселманнар үзара бәхәсләшкән эшләре турысында: «Ий, Мөхәммәд! Синнән хөкем иттермичә чын иманлы була алмаслар, алар синең хөкемеңә күңелләрендә шик калдырмаслар һәм синең хөкемеңә чын күңелдән риза булып мөселман булырлар, әнә шул эшне эшләгәнгә чаклы камил мөэмин булмаслар». (4:65),** һәм шулай ук: **«Аллаһ Тәгалә, бер кешене һидәяткә — диндә туры юлга күндерергә теләсә, ислам дине өчен аның күкрәген ачып куяр, янә Аллаһ, бер кешене хак диннән адаштырырга теләсә, ул кешенең күкрәген тар, күңелен хактан шикләнүче кылыр, шуннан соң бу кеше, күкрәге тар булу сәбәпле, хаклыктан тыгызланып — Аллаһ хөкемнәрен яратмыйча, гүя күккә чыгардай булыр. Әнә шулай Аллаһ Тәгалә, Коръән аятьләренә ышанмаган яки ышанып та аның белән гамәл кылмаган кешеләрнең күңелләренә көферлек, мөшриклек яки монафикълык нәҗесен салыр» (6:125)**, - диде.

### Аллаһ ризалыгы өчен булган мәхәббәт һәм нәфрәт

Аллаһ ризалыгы өчен булган мәхәббәт һәм нәфрәт мәҗбүри гамәлләр, алай гына да түгел, алар – иманның иң нык булган бер өлеше.

### Аллаһ ризалыгы өчен нәрсәләрне һәм кемнәрне яратырга кирәк?

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аллаһ Тәгалә риза булган гамәлләрне. Боларга шәригатьтә килгән бар нәрсә дә керә, мисал өчен, тәүһид. | Әлеге гамәлләрне кылучы затларны. Мәсәлән: пәйгамбәрләрне, расулләрне, фәрештәләрне, сәхәбәләрне һәм барлык тәүһид ияләрен. | Аллаһ сөйгән билгеле бер вакытларны, мәсәлән, Кадер кичен яки төннең өченче өлешен. | Аллаһ сөйгән билгеле бер урыннарны, мәсәлән, Мәккә, Мәдинә шәһәрләрен... |

Аллаһ ризалыгы өчен нәрсәләргә һәм кемнәргә нәфрәтләнергә кирәк?

| Аллаһ Тәгалә риза булмаган һәм Аның ачуын китергән гамәлләргә. Боларга шәригатьтә тыелган бар нәрсә дә керә, мәсәлән, ширк. | Әлеге гамәлләрне кылучы затларга. Мәсәлән: мөшрикләр, монафыйкълар һәм шайтаннар. | Аллаһ нәфрәтләнгән билгеле бер вакытларга, мисал өчен, кояшка гыйбадәт кылган вакыт. | Аллаһ нәфрәтләнгән билгеле бер урыннарга. Мәсәлән, ширк кылына торган урыннар. |
|---|---|---|---|

Хатын-кыз, күпхатынлылыкны күралмау сәбәпле, имансызлыкка төшә аламы?

Дөреслектә, хатын-кыз шәригатьнең күпхатынлылык хакындагы карарын кире какмый икән, әмма ул, хәләл җефетенә карата мәхәббәте яки көнләшү сәбәпле, аның башка хатын-кызга өйләнүен теләмәсә, бу гамәле өчен аны шелтәләргә ярамый.

## Алтынчы гамәл

Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) алып килгән диннең нәрсәсен булса да, яки Аллаһ Тәгаләнең әҗер-савап бирүеннән, яки Аның җәзасыннан көлгән, мәсхәрәләгән, мыскыллаган кеше имансызлыкка төшә. Моңа Аллаһның ошбу сүзләре дәлил: **«Әйт: "Әй сез Аллаһ тарафыннан Аның аятьләрен вә Аның расүлен мәсхәрә итәсезме?" Акланмагыз! Иман китергәннән соң кәфер булган кешеләр, Корьән белән гамәл кылмыйча көферлекләрен арттырдылар ...» (9:65-66).**

### Мыскыллау (көлү, шаяру)

#### Аның мәгънәсе һәм мыскыл итүченең хөкеме

Бу очракта мыскыллауның мәгънәсе – мәсхәрәләү, көлү. Ислам диненең нәрсәсен дә булса мыскыл итүче яки мәсхәрәләүче кеше имансыз була, Ислам диненә каршы көрәшүне үз эченә алган зур көферлеккә төшә һәм бу гамәле аны Ислам диненнән чыгара. Мондый кеше җәһәннәм әһеле, җәһәннәмдә ул мәңге калачак. Мондый халәткә төшермәсен дип, Аллаһтан яклау сорыйбыз.

Ә Ислам диненең нәрсәсен дә булса мыскыл итүне ишеткән кешегә әлеге мыскыллауга каршы шелтә белдерү һәм әлеге урыннан китү вәҗиб. Бу хөкемгә әлеге мыскыллауны күзәткән кеше һәм аның хакында шелтәләмичә сөйләгән кеше дә керә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Кәферләрнең Корьән аятьләрен инкарь итүләрен яки мәсхәрә кылып көлүләрен ишетсәгез, алар арасында утырмагыз, ягъни аларның бу кабахәт эшләре кайда булса да һич тә риза булып тормагыз, Корьән сүзләренә кагылмый торган сүзгә күчкәннәренә чаклы. Әгәр аларның Корьәнгә каршы булган сүзләренә һәм эшләренә риза булып торсагыз, ул вакытта алар җөмләсеннән булырсыз. Шиксез, Аллаһ монафикълар белән көферләрне бер җәһәннәмгә җыячак» (4:140) .**

#### Мыскыл итүченең тәүбәсе ошбу шартлар үтәлгәндә кабул ителә:

- Әлеге кеше Аллаһның Бөеклегенә хас рәвештә Аны мактарга тиеш;
- Мыскыллау вакытында әйткән сүзләреннән ваз кичәргә тиеш;
- Анда тәүбә итү билгеләре күренергә һәм без аның тәүбәсенең дөреслеген күрергә тиешбез.

Аллаһның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) хурлаган кешегә килгәндә, әгәр аның сүзләре хак булса, аның тәүбәсен Аллаһ кабул итә, әмма аңа катгый җәза каралган.

#### Әгәр сүзләрендә мыскыл итү мәгънәсе (ягъни каршылыклы мәгънә) яшеренгән булса, бу кеше көферлеккә төшәме?

Мондый кешегә әлеге сүзләрнең харамлыгын белгертергә һәм аңлатырга кирәк. Әгәр ул тәүбә итсә, аның гөнаһысы булмый. Әгәр тәүбәгә килмәсә, бу очракта казыйларга һәм олугъ галимнәргә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

## Җиденче гамәл

Сихерчелек, шушында ук сихер чыгару да, сөйдергечләр ясау да керә. Кем дә кем аны башкарса яки канәгатьлек алса, ул кеше имансызлыкка төшә. Моңа Аллаһның ошбу сүзләре дәлил: **«Бу ике фәрештә сихерне һичкемгә өйрәтмәделәр, һәм әйттеләр: "Дөреслектә без сезгә фетнәбез, Аллаһ безне сезне сихер белән сынар өчен җибәрде, әгәр сихер белән шөгыльләнсәгез кәфер булырсыз."» (2:102).**

### Сихер

#### Сихерчеләрнең билгеләре:

- Өшкерүдә (рукъя) шәригать рөхсәт иткән шартларны боза, ягъни капма-каршы гамәл кыла;
- Аерым хәрефләр яза һәм аңлаешсыз сүзләр сөйли;
- Астрология белән шөгыльләнә, уч төбеннән яки кәһвә куесыннан "укый";
- Төкерә-төкерә төеннәр бәйли;
- Сихер чыгара һәм сөйдергечләр ясый;
- Авыру кешегә шәригать хөкемнәренә капма-каршы булган гамәлләр кылырга куша, мәсәлән: тыелганны эшләргә, намазны калдырырга, малны чалганда Аллаһның исемен телгә алмаска;
- Авыру кешенең әнисенең исемен сорый;
- Үзен яшерен гыйлемне белүчеләр рәтенә кертә…

#### Сихерчелекнең хөкеме

Сихерчелек – зур көферлек, моңа Аллаһ Тәгаләнең сүзләре дәлил: **«Бу ике фәрештә сихерне һичкемгә өйрәтмәделәр, һәм әйттеләр: "Дөреслектә без сезгә фетнәбез, Аллаһ безне сезне сихер белән сынар өчен җибәрде, әгәр сихер белән шөгыльләнсәгез кәфер булырсыз."» (2:102).**

#### Сихерчеләргә барган кешенең хөкеме

Биредә аның белән бергә утырган, аңа кемнедер җибәргән яки хәбәр юллаган, йолдызнамәләр, уч төбеннән яки кәһвә куесыннан багулар һ.б.ш. хакында булган телетапшырулар, сайтлар, журналлар караган кешеләр күздә тотыла.

Мондый кешенең хөкеме шул: кырык көн буе аның укыган намазы кабул булмаячак. Бу хакта хәдистә килә. Сихерченең әйткәненә ышанган кеше хакында исә Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын): *«Кем дә кем сихерчегә барса һәм аңа ышанса, ул кеше Мөхәммәдкә килгән нәрсәләргә карата көферлек кылды»*, - дигән. Әгәр белеме җиткән кеше сихерчегә кисәтү ясау, шелтә белдерү өчен барса, мондый очрак бу хөкемгә керми.

**Нушра**
Сихерләнгән кешедән бозымны чыгару, ул ике төргә бүленә:

**Канунлаштырылган (рөхсәт ителгән)**

Ул бозымны шәригатьтә рөхсәт ителгән рукъялар, дарулар һәм дога ярдәмендә чыгару.

**Тыелган**
Әгәр бозымны чыгаруда сихерчелек кулланылса, бу тыелган нушра була. Аның хакында Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: *«Чынлыкта, ул – шайтанның бер гамәле».*

**Бозымны сихер ярдәмендә чыгаруга рөхсәтне кире кагу**

- Бозымны сихер ярдәмендә чыгару Коръәнгә, Сөннәткә, шулай ук сәхәбәләр һәм бу өммәтнең әлгәрләре юлына каршы килә;
- Бу ысулда сөннәттә килгән Коръән белән шифа табуны калдыру да бар;
- Нушраның бу төрен кулланып, сихернең мөселманнар арасында таралуына сихерчеләргә ярдәм иткән буласың;
- Шулай ук Коръән һәм сөннәттән килгән дога белән дәвалау кебек анык билгеле булган нәрсәне сихер ярдәмендә дәвалау кебек шикле нәрсәләр файдасына калдыру;
- Бозымны сихер ярдәмендә чыгарганда, бозым чыгаручының да, чыгартучы кешенең дә, сихер китсен өчен шайтан ярата торган гамәл кылып, аңа якынаюы кирәк;
- Әгәр сихерләнгән кеше сабырлык күрсәтсә, ул Җәннәт белән бүләкләнер. Бу хакта безгә пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте;
- Бозымны сихер ярдәмендә чыгару сихерләнгән кешенең бозымын арттыра гына;
- Аллаһның расуле дә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сихерләнгән иде, әмма ул әлеге бозымны сихер ярдәмендә түгел, ә киресенчә, шәригатьтә рөхсәт ителгән рукъялар ярдәмендә чыгарды.

## Сигезенче гамәл

Мөселманнарга каршы мөшрикләргә ярдәм һәм булышлык күрсәтү. Аллаһның сүзләре моңа дәлил: **«Әгәр Сезләрдән берәү динсез кардәшләрен дус тотса, ул кеше алардан булды. Аллаһ, әлбәттә, Коръән белән гамәл кылмаучы залимнәрне туры юлга күндермәс» (5:51).**

### Мөселманнарга каршы мөшрикләргә ярдәм:

Мөселман кешесе мөшрикләрнең диннәренә һәм мөшрикләрнең үзләренә ышанмавын һәм аларга катнашмавын күрсәтергә һәм тәүһид әһелләренең диненә мәхәббәт күрсәтеп, алар белән дустанә мөнәсәбәтләрдә булырга тиеш. Көферлекне яраткан, яки аның белән канәгатьләнгән, яки аңа һәм мөшрикләргә ярдәм иткән кеше имансыз була, Ислам диненнән чыгаручы көферлеккә төшкән була.

Мөшрикләргә ярдәм ике төрле була:

#### Ышанмаучылык һәм диннән язу, мөртәтлек

Мөшрикләргә карата мәхәббәт, ә мөселманнарга каршы нәфрәт күрсәтеп, мөшрикләрнең җиңүен теләп, мөселманнарга каршы мөшрикләргә ярдәм итү.

#### Диннән чыгаручы көферлек булып саналмый

Әгәр бу ярдәм мөшрикләргә мәхәббәт, ә мөселманнарга нәфрәт сәбәпле түгел, ә дөньяви файда алу өчен булган булса.

## Тугызынчы гамәл

Хозыр Муса (галәйһиссәләм) шәригате чикләреннән чыккан кебек, кайбер кешеләр Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шәригате чикләреннән чыга ала, дип инанган кеше имансыз була.

### Кайбер кешеләр Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шәригате һәм дине чикләреннән чыга ала, дип инанган кешеләр

Гыйлем ияләренең бердәм фикере буенча, шулай дип инанганнар кешене Ислам диненнән чыгара торган зур көферлеккә төшкән имансыз бәндәләр булалар. Мондый кешене, дәлилләр хакында аңлатып, тәүбәгә чакырырга кирәк. Әгәр ул тәүбәгә килмәсә, аңа катгый җәза каралган. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Ий, кешеләр! Дөреслектә мин барчагызга — бөтен дөнья кешеләренә Аллаһдан җибәрелгән рәсүлмен» (7:158)**, һәм Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын)әйтте: *«Әгәр минем кардәшем Муса исән булса, ул миңа иярүдән башканы кылмас иде».*

Бу хөкем Исламга чакыру барып ирешкән Китап әһелләренә дә кагыла, чөнки алар, элгәре язылганча, мөшрикләр.

Хозыр Муса (галәйһиссәләм) шәригате чикләреннән үттеме? Моңа ишарә итүче бер генә ышанычлы чыганак та юк. Булган очракта да, Хозыр – Муса өммәтеннән булмады, чөнки элгәре һәр пәйгамбәр аерым бер халыкка җибәрелә иде. Ә безең пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) барлык кешеләргә дә җибәрелде һәм аның шәригате чикләреннән үтәргә һичкемнең дә хакы юк.

## Унынчы гамәл

Аллаһның диненнән, аны өйрәнүдән, аның нигезендә гамәл кылудан баш тарту. Моңарга Аллаһның ошбу сүзләре дәлил булып тора: **«Раббысының аятьләре белән вәгазьләнеп, ул вәгазьләрдән баш тарткан кешедән дә залимрәк кеше булырмы? Без, әлбәттә, залимнәрдән үч алучыбыз» (32:22).**

### Аллаһ Тәгаләнең диненнән баш тарту:

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: *«Аллаһ кемгә хәерлелек тели, шуңа динне аңлауны бирә»*. Ә Аллаһ кемгә хәерлелек теләми, аны ул динне өйрәнүдән читкә бора. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Раббысының аятьләре белән вәгазьләнеп, ул вәгазьләрдән баш тарткан кешедән дә залимрәк кеше булырмы? Без, әлбәттә, залимнәрдән үч алучыбыз»**, ә гөнаһлы бәндәләр – җәһәннәм әһелләре, Аллаһ безне сакласын.

### Диннән баш тарткан кешенең хөкеме

Әгәр кеше Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын), иман китермәсә, аны яратмыйча, ул алып килгән нәрсәләргә катгый рәвештә ышнмыйча үзенең ишетүен һәм калебен аннан читкә борса – мондый кеше диннән чыгаручы зур көферлеккә төшкән була.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр дә аларга әйтелсә: «Аллаһ иңдергән Корьәнгә һәм рәсүл г-мнең хөкемнәренә килегез», — дип, шул вакытта күрерсең, алар синнән ныклап баш тарту белән баш тартырлар »(4:61)**, шулай ук Ул: **«Берәү Аллаһ вәгазе булган Корьәннән йөз чөерсә, аның белән гамәл кылудан баш тартса, Аллаһ ул кешене каты мәшәкатьле газабка дучар итәр» (72:17)**, - диде.

## Авторның йомгаклау сүзе

Әлеге гамәлләр, эшләнергә мәҗбүр ителгәннәреннән тыш, уйнап, мәзәк итеп, чынлап яки куркудан эшләнәме – алар арасында һичнинди дә аерма юк. Һәм бу гамәлләрнең барысы да еш кылына торган, иң куркыныч һәм хәтәр гамәллләрдән санала. Шуңа күрә мөселман кешесе алардан читтә торырга, аларга якын бармаска һәм аларны кылмасам ярар иде дип, үзе өчен куркырга тиеш. Аллаһтан Аның ачуына һәм газаплы җәзаларга китерә торган нәрсәләрдән яклау сорыйбыз. Аллаһның кешеләр арасындагы иң күркәм заты булган Мөхәммәдкә, аның сәхәбәләренә һәм дәвамчыларына Аллаһның сәламе һәм рәхмәтләре булсын.

Бу гамәлләрне кылганда түбәндәге халәтләр арасында һичнинди аерма юк:

**Курку**

Ягъни кем дә кем әлеге гамәлләрне малымны, дәрәҗәмне югалтудан куркып кылдым, дип ялганлап әйтсә, ләкин бу гамәлләрне эшләргә ул мәҗбүр ителмәсә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Кешеләрдән шундый кешеләр дә бардыр, әгәр алар Аллаһ юлында аз гына авырлык күрсәләр, кешеләрдән ирешкән рәнҗетелүне ахирәттәге Аллаһ газабы кебек зур газабтан санарлар, әгәр мөэминнәргә Аллаһ ярдәме белән табыш малы килсә, әлбәттә, алар әйтәләр, шиксез, без дә сезнең белән бергә, дип. Әллә Аллаһ барча дөнья кешеләренең күңелләрендә иман йә монафикълык яки мөшриклек сырхавы бар икәнне белмәсме?” (29:10)**

**Җитди**

Әгәр кеше ният белән бу гамәлләрнең берәрсен кылса, әмма акланыр сәбәбе булмаса.

**Мәзәк итеп, уйнап**

Әгәр кеше бу гамәлләрнең берсен кылып, соңыннан ул гамәлнең мәзәк итеп, уйнап кына кылынуы белән акланса.

### Мәҗбүр итү, ирексезләү:

Исламнан чыгаручы гамәлләрнең берәрсен кылырга мәҗбүр ителгән кеше көферлеккә төшми. Әмма түбәндәге шартлар үтәлгәндә генә кеше мәҗбүр итүне, ирексезләүне сәбәп итеп аклана ала:

- Ул чынан да бу гамәлләрне кылырга мәҗбүр ителгән булырга тиеш. Шуңа күрә мәҗбүр ителгән кешедән кала беркем дә, курыккан яки әлеге гамәлләрне ихтирамлылык билгесе итеп кылган кебекләр аклауга һич лаек түгел;
- Бу гамәл зарурлык чикләреннән үтмәскә тиеш. Мәсәлән, әгәр кешене кемнедер мыскыл итәргә (мыскыллау көферлек булган очракта) бер тапкыр мәҗбүр итсәләр, ә ул бердән артык тапкыр мыскыл итсә, бу көферлек була, чөнки ул мыскыл итәргә бары тик бер генә тапкыр мәҗбүр ителгән иде;
- Бу кеше, үз мөмкинлекләренә карап, ачыктан-ачык көфер сүзләр әйтүдән качарга тырышырга тиеш;
- Бу кешенең калебендә ныклы иман булырга тиеш, ягъни ул көфер сүзләрне теле белән әйтсә дә, аның калебендә иман нык булырга тиеш;
- Ул мәҗбүр ителгән гамәл башкаларга зарар салырга һәм кешеләрнең адашуына сәбәп булырга тиеш түгел.

## Мөһим искәрмәләр

Беренчедән: бу китапны язган вакытта автор өммәтне көферлектә гаепләүне максат итеп куймады. Аның максаты – әлеге гамәлләрне өйрәнеп, аларны кылудан курыксыннар һәм саклансыннар дип, кешеләрне укыту. Һәм әгәр алар саклансалар, иманнары дөрес булыр һәм Аллаһның каты җәзасыннан котылырлар. Шулай ук мөселманнарның әлеге гамәлләрне башкарудан башкаларны кисәтүе дә зарур, чөнки бу гамәлләр шактый ук хәтәр, шуңа күрә алар хакында белергә һәм сакланырга кирәк;

Икенчедән: Ширектән тиешле дәрәҗәдә саклану өчен мөселман кешесе дини гыйлем алырга тиеш. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әтте: *«Аллаһ кемгә хәерлелек тели, шуңа динне аңлауны бирә»*, ә динне аңлау – мөһим һәм бөек бурычларның берсе, чөнки динне аңлау аркылы кеше үзен ширктән, бидгатьтән һәм гөнаһлардан саклый. Үзенең Раббысын күбрәк танып белгән саен, гамәл кылганда һәм төрле халәтләрдә кешенең Аллаһ Тәгалә аның артыннан күзәтә дигән хис-тойгысы (муракаба) арта. Кешенең гыйлем дәрәҗәсе никадәр күбрәк булган саен, Аллаһ каршында ул әчкерсезрәк була һәм аның иманы да камилрәк һәм сыйфатлырак була. Гыйлемгә ия кайберәүләр әйтте: «Без гыйлемне Аллаһ ризалыгы өчен алмадык, ә ул, Аллаһ ризалыгы өчен алынган гыйлемнән тыш, безгә бирелмәде»;

Өченчедән: Билегеле бер кешенең көферлеге хакындагы карар бары тик аның Исламнан чыгаручы гамәл кылуы исбатлангач кына һәм аңа дәлилләр җиткерелеп, әлеге карарны кабул итүгә комачау иткән киртәләрне бетергәч кенә кабул ителә. Әлеге карарны кабул итәргә хакы булган кеше – мөселманнар арасында куәте булган, шулай ук аларны алыштыручы шундый дәрәҗәләргә ирешкән хакимнәр. Гадәти мөселманнарга килсәк, әлеге мәсьәләләрне тикшерү белән алар шөгыльләнергә тиеш түгел;

Дүртенчедән: автор үзенең хезмәтен: «Аллаһтан Аның ачуына һәм газаплы җәзаларга китерә торган нәрсәләрдән яклау сорыйбыз», - дигән сүзләр белән тәмамлый. Бу аның укучыга карата ниятенең изге булуын һәм аңа бары яхшылык кына теләвенә ишарәли. Һәм бу авторның, Аллаһ аны ярлыкасын һәм чиксез әҗерен бирсен, барлык хезмәтләрендә дә шулай.

## Үзеңне тикшер

**Сорауларга җавап бир, җавапларны махсус билгеләнгән урыннарга яз**

**1. Ни өчен авторлар үз хезмәтләрен «бәсмәлә»дән башлыйлар?**

1) ..........................................................................................................................................
2) ..........................................................................................................................................
3) ..........................................................................................................................................
4) ..........................................................................................................................................

**2. «Ислам диненнән чыгаручы гамәлләр» дигән гыйбарә нәрсәне аңлата?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**3. Ни өчен галимнәр кайвакыт «Исламны бозучы гамәлләр...», ә кайвакыт «Исламны гамәлдән чыгаручы эшләр...» диләр?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**4. Әлеге гамәлләргә карата галимнәрең фикере бердәмме?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**5. Бу гамәлләр сан ягыннан чикләнгәнме?**
- чикләнгән
- чикләнмәгән
- билгеле бер сан белән чикләнмәгән, әмма, гомумән, билгеле бер төрләргә бүленәләр

**6. Ни өчен автор аларны унау диде?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**7. Әгәр Коръән һәм Сөннәттә гамәлләр билгеле бер сан белән күрсәтелгән булса, бу гамәлләр бу сан белән генә чикләнәме яисә ул күбрәк булырга мөмкинме?**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**8. Ни өчен кайвакыт гамәлләр саны аның белән генә чикләнмәгән сан күрсәтелә?**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**9. Сан ягыннан чикләнгән гамәлгә мисал китер.**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**10. Саны чикләнмәгән гамәлгә мисал китер.**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**11. Автор Исламнан чыгаручы гамәлләрнең саны уннан артык, дип саныймы?**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**12. Авторның кайсы сүзләреннән мондый нәтиҗә ясап була?**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**13. Бу гамәлләрне ничек булса да сан ягыннан чикләп буламы?**

........................................................................................................................................

........................................................................................................................................

**14. Әлеге гамәлләрне, гомумән, нинди төрләргә бүлеп була?**

1) ..........................................................................................................................................
2) ..........................................................................................................................................
3) ..........................................................................................................................................
4) ..........................................................................................................................................

**15. Ни өчен без «Исламнан чыгаручы гамәлләр»не өйрәнәбез?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**16. Автордан башка тагын берәрсе бу темага багышланган хезмәтләр язганмы?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**17. Без гамәл һәм гамәл кылучы арасындагы аерманы билгеләргә тиешбезме?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**18. Болай аеруның сәбәбе нидә?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**19. Авторның максаты өммәтне көферлектә гаепләү идеме?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**20. Бу гамәлләр хакында белгән мөселманның бурычы нинди?**

..........................................................................................................................................
..........................................................................................................................................

**21. Әлеге хезмәттә автор ширкнең кайсы төрен күздә тотты?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**22. Зур ширк һәм кече ширк арасында аерма нинди?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**23. Зур ширк кылган кешенең тәүбәсе кабул ителәме? Һәм кайчан кабул ителми?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**24. Кайсысы гөнаһлырак: кече ширкме яки зур гөнаһмы?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**25. Билгеле бер гамәлнең зур гөнаһ булуына нинди билгеләр ишарә итә?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**26. Зур гөнаһлар билгеле бер сан белән чикләнгәнме?**

.................................................................................................................................................
.................................................................................................................................................

**27. Зур гөнаһ кылган кешенең хөкеме нинди? Аны яратырга яки дошман күрергә кирәкме?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**28. Зур гөнаһлар эшләүче кеше янәшәсендә булырга ярыймы?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**29. Зур гөнаһларның дәрәҗәләре бармы? Дәлиле нинди?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**30. Изге гамәлләр кылу зур гөнаһларны ярлыкауга сәбәп була аламы, яки алар ярлыкансын өчен тәүбә итү кирәкме?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**31. Тыелган гамәлләрнең ничә төре бар?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**32. Мал чалу төрләрен сана.**

1) ……………………………………………………………………………………………………………………
2) ……………………………………………………………………………………………………………………
3) ……………………………………………………………………………………………………………………

**33. Нинди очракта мал чалу зур ширк булачак?**

……………………………………………………………………………………………………………………
……………………………………………………………………………………………………………………

**34. Шәфәгать төрләрен сана.**

1) ..............................................................................................................................
2) ..............................................................................................................................
3) ..............................................................................................................................

**35. Нәрсә ул тәвәккәл кылу?**

..............................................................................................................................
..............................................................................................................................

**36. Тәвәккәл кылуның төрләрен сана.**

1) ..............................................................................................................................
2) ..............................................................................................................................
3) ..............................................................................................................................

**37. «Мин шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» яки «Мин Аллаһка тәвәккәл иттем, аннан соң шуңа-шуңа тәвәккәл иттем» дип әйтергә ярыймы?**

- ярый
- ярамый

**38. Алайса, ничек дип әйтү рөхсәт ителгән?**

..............................................................................................................................
..............................................................................................................................

**39. Мөшрикләрнең көферлекләренә күрсәтүче дәлилләрне китер. Ә Китап әһелләре алар рәтенә керәме?**

..............................................................................................................................
..............................................................................................................................

**40. Бу хөкем алар белән булган килешүләребезгә тугъры булмаска тиеш дигәнне аңлатамы?**

..............................................................................................................................
..............................................................................................................................

**41. Имансызлар белән булган мөнәсәбәтләрдә кешеләр өч төркемгә бүленә:**

1) ..................................................................................................................................................
2) ..................................................................................................................................................
3) ..................................................................................................................................................

**42. Аллаһ иңдергән буенча булмаган хөкем төрләре нинди?**

..................................................................................................................................................
..................................................................................................................................................

**43. Аллаһ ризалыгы өчен нәрсәләрне һәм кемнәрне яратырга кирәк?**

..................................................................................................................................................
..................................................................................................................................................

**44. Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәтнең хөкеме нинди?**

..................................................................................................................................................
..................................................................................................................................................

**45. Ислам диненең нәрсәсен дә булса мыскыл итүченең яки мәсхәрәләүче кешенең көферлеге нинди төргә карый?**

..................................................................................................................................................
..................................................................................................................................................

**46. Мыскыл итүченең тәүбәсе кабул ителәме? Кабул ителсә, моңа нинди шартлар үтәлүе кирәк?**

1) ..................................................................................................................................................
2) ..................................................................................................................................................
3) ..................................................................................................................................................

**47. Аллаһның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) хурлаган кешенең хөкеме нинди?**

..................................................................................................................................................
..................................................................................................................................................

**48. Мондый мыскыллаулар ишеткән кешенең хәләте нинди?**

………………………………………………………………………………………………………………………
………………………………………………………………………………………………………………………

**49. Сихерчеләрнең көферлегенә күрсәтүче дәлил нинди?**

………………………………………………………………………………………………………………………
………………………………………………………………………………………………………………………

**50. Сихерченең билгеләре нинди?**

………………………………………………………………………………………………………………………
………………………………………………………………………………………………………………………

**51. Сихерчегә барган кешенең хәләте нинди?**

………………………………………………………………………………………………………………………
………………………………………………………………………………………………………………………

**52. «Сихерчегә бару»га тагын нәрсәләр керә?**

………………………………………………………………………………………………………………………
………………………………………………………………………………………………………………………

**53. Нушраның (сихерне/бозымны чыгару) нинди төрләре бар?**

1) ………………………………………………………………………………………………………………………
2) ………………………………………………………………………………………………………………………

**54. Бозымны сихер ярдәмендә чыгаруга рөхсәт бирүне ничек кире кагарга?**

1) ………………………………………………………………………………………………………………………
2) ………………………………………………………………………………………………………………………
3) ………………………………………………………………………………………………………………………
4) ………………………………………………………………………………………………………………………
5) ………………………………………………………………………………………………………………………
6) ………………………………………………………………………………………………………………………
7) ………………………………………………………………………………………………………………………
8) ………………………………………………………………………………………………………………………

**55. Мөшрикләргә ярдәм итүнең хөкеме нинди?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**56. Кем дә булса Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шәригате чикләреннән чыга аламы?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**57. Хозыр Муса (галәйхиссәләм) шәригате чикләреннән чыкканмы?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**58. Диннән баш тартуның хөкеме нинди?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**59. «Куркудан» дигән сүздә автор нәрсәне күз алдында тота. Кеше мәҗбүр ителгән дигәнне аңлатамы бу сүз?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**60. Кеше нинди шартларда мәҗбүр итүне, ирексезләүне сәбәп итеп аклана ала?**

1) …………………………………………………………………………………………………………………………………
2) …………………………………………………………………………………………………………………………………
3) …………………………………………………………………………………………………………………………………
4) …………………………………………………………………………………………………………………………………
5) …………………………………………………………………………………………………………………………………

**61. Ни өчен автор үзенең хезмәтен дога белән тәмамлый?**

…………………………………………………………………………………………………………………………………

…………………………………………………………………………………………………………………………………

**62. Мөселман ширктән ничек сакланырга тиеш?**

……………………………………………………………………………………………………………………………

……………………………………………………………………………………………………………………………

**СЫЛТАМАЛАР**

- attasseel-alelmi.com –шейх Хәйсәм Сәрхан җитәкчелегендәге "التأصيل العلمي" сайты (гарәп телендә);
- attasseel-alelmi.com/ru – шейх Хәйсәм Сәрхан җитәкчелегендәге "Белем ачкычлары" сайты (рус телендә);
- facebook.com/hsarhanrusi – «Facebook» челтәрендәге рус телендәге берләшмә;
- vk.com/haytham_sarhan – «ВКонтакте» челтәрендәге рус телендәге берләшмә;
- telegram.me/hsarhan_ru – «Telegram»дагы рус телендәге канал.

Хаталар табылган очракта, аларны күрсәтеп, безнең электрон адреска юллый аласыз:

tawfiq.abu.muhammad@gmail.com